Вакыйф Нуриев

# ҖИДЕНЧЕ ПАЛАТА

повестьлар, хикәяләр

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2007

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Н81

**Нуриев В.В.**

Җиденче палата: повестьлар, хикәяләр / Вакыйф Нуриев. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 287 б. — 2000 д. — ISBN 978-5-298-01598-1

Китапта җәмгыятебездәге кайбер авыру якларны савыктыруда игелеклелек, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек кебек әхлакый төшенчәләрнең әһәмияте хакында сөйләнә. Балачакның кызыклы һәм якты хатирәләре бәян ителә.

ISBN 978-5-298-01598-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2007

© Нуриев В.В., 2007

**ПОВЕСТЬЛАР**

# Җаннарны чайкыйсы бар

## Әбиемә — әфлисун

Әй диңгез, диңгез!.. Кара диңгез. Синең турыда күп ишеттем. Укыганым булды. Үзеңне күрү теләге күңелемдә бәрәкәтле хыял булып бөреләнә башласа да, тиздән, бик тиздән күрешәчәгебез ике ятып бер төшемә дә кермәде. Менә хикмәти Хода, 4–5 көн элек кенә мин, аягыма — олтанлы киез итек, башыма — ялтырап торган күн бүрек, өстемә алагаем зур драп пәлтә (безнең авылда бала-чагага киемне бер-ике размерга запас белән алалар) кигән, ак юрган астында рәхәткә талып яткан кышкы авыл урамнарында бил тиңентен кар ерып, текә тауларда чаңгы шуып, ак кыяларны ишеп-җимереп, өйгә кайткач абзар-кура арасында мәш килеп йөргән 12 яшьлек малай, Кафтау итәгендә диңгезгә карап басып торам. Кояшка күзләремне кысам. Көньякның җылы тыгыз һавасын рәхәтләнеп сулыйм. И, рәхмәт инде сиңа, «Яшь ленинчы»! Хәл кадәри хезмәтемне, газетага җибәргән рәсем-мәкаләләремне шулай бәһаләгән өчен.

Редакция биргән зур бүләкне — Бөтенроссия пионерлагере «Орленок»ка юлламаны — миңа озын тәнәфестән соң, мәктәпнең барлык укучыларын линейкага тезеп, тантаналы төстә тапшырдылар. Беркөнне дә озын тәнәфестән соң тезделәр. Укытучылар безне биш минут элек кенә кар атып ватылган тәрәзә өчен бастырган булып чыктылар. Гаеплене «кайнар эздән» тотмакчылар. Кемнең кулы юеш — шул ваткан була. Тикшереп карасалар, коры куллы малай табылмады диярлек. Бу юлы да «Тезелергә!» дигән әмер яңгырауга, барыбыз да кулларны, юешме-юеш түгелме, чалбарларга ышкый башладык. Мин дә ышкыйм. Файдасы гына юк. Уч төбеннән салкынча тир бәреп тора. Директор кулыннан путевканы алганда, кулым юпь-юеш иде.

Иртәгесен иртүк юлга кузгалдык. Әни мине «срочно» комсомол обкомына илтеп тапшырырга тиеш.

Мәктәп, классташлар, әти, әни, мине тукранбаш түшәлгән чанада стансыга илткән күндәм Буян, ак авылымның пакь таңы — барысы да еракта калдылар. Еракка, кышлар булмый, карлар яумый торган якларга китәсемне белгәч, хәлсезләнеп түшәгенә ауган, озатканда сагышлы күзләрен «Һай, улым, җир читләренә китәсең бит... Планлаштырмаган эш булды әле бу» дип кайгырып, мине баккан әбием калды. Калды. Һәм... ярты йөрәгемне алып калды. Кинәт авырып китте ул. Без юлга кузгалганда, урын өстендә ятып калды.

И әби, әби...

Гел күз алдында. Озын буй, эре сөякле гәүдә. Башын бераз гына арткарак ташлап, ияген алгарак чыгарып торган мәһабәт сын, сабыр вә горуранә килеш-килбәт. Йөзендәге бихисап җыерчык-сырлар да килешеп кенә тора үзенә. Кулларындагы бүртеп, тармакланып торган зәңгәрсу-соры тамырлар исә география картасындагы эреле-ваклы елгаларны хәтерләтәләр.

*** * ***

Кая инде ул диңгез-таулар күрү, әбинең район үзәге Арчага да барганы юк. Безнең Сеҗегә Югары Утар авылыннан килен булып төшкән ул. Ике авыл арасы — 17 чакрым. Бу — әбинең үз гомерендә узган иң озын юлы. Арчага йомышы төшмәгән, чөнки район үзәге булып күрше Яңа Чүриле авылы саналган. Тугызынчы дистәсенең яртысын сүтеп килүче әбием, авылыбыздан беркая чыкмыйча, тыйнак кына, сабыр гына, барына мәмнүн булып гомер кичергән. Юк, ялгышам. Счетоводлыкка укучы өлкән улы Фәһметдин абыйны мунча кертү өчен бездән 70 чакрым ераклыктагы Олы Әтнәгә кем барган? Әбием! Кышкы зәмһәрир суыкта бер-ике кочак утын салган бәсле чанасын өстери-өстери, салкында, борын очын әле пәлтә якасына, әле кәшемир шәленә яшерә-яшерә, 70 чакрымны җәяүләп кем узган? Әбием!

И ул еллар... Бабай җигүле атта горур гына кайтып керә торган булган. Капкадан керә-керешкә дилбегәне вәкарь белән һавага чөеп җибәргән. Ирен каршы алырга чыккан әби ул дилбегәне җиргә төшеп барган шәпкә тотып алган, атны тугарган, абзарга кертеп печәнгә, суга кушкан, сбруйларны җыйган, киптергән. Ә иртәгесен бабайның өйдән чыгышына ишегалдында җигүле шәп кара-туры — Барса торган.

Тормышта күпне күрә минем әби. Вакытсыз үлеп киткән иреннән биш бала белән кала. Һай ул балалар... Мәетне өйдән алып чыкканда, мич башында, әти үлгәч акча бирәләр икән дип, сәдакага сөенешеп калган бичара сабыйлар. Йөрәге ничек түзгәндер газиз әбекәйнең?!

Кайгы-хәсрәт ялгыз йөрми, диләр бит.

Җәй. Коры җәй. Хәтәр җәй. Кайнар сулышыңнан да бөтен җиһан дөрт итеп кабынып китәр кебек. Авылның азмы-күпме хәл-җегәре булган һәр кешесе уракта. Кинәт кыр өстен һушыңны алырлык хәбәр кисеп үтә:

— Пожар! Сеҗе яна!!!

Күтәрелеп карасалар — авыл өстендә кара-кучкыл тыгыз төтен болыты. Халык, басуны ярып, дәррәү авылга йөгерә. Әби дә чаба. Тыны кысыла, эченә кату чыга, йөрәгенең хәле китә. Башта бер генә уй: «Кемнәр яна?» Отыры төтен болыты тагын да биегәя, тагын да җәелә.

И әби... Өеңнең, каралты-кураңның чиркандыргыч кара күмерләре, утлы кисәүләре өстенә кайтып кергәндә, итәк тулы бичара ач балаларың белән августның салкынча төнендә котсыз-нурсыз, өйсез — күрше-күлән дә янып бетә — урамда төн кунганда, ничек түзде икән синең йөрәк?!

Төпчек улың күрше малае белән абзар артында бәрәңге пешермәкче булган бит. Аны тотып тукмадыңмы соң? Хәер, үзең әйтмешли, ул сабыйны тукмап ни файда. Күрәчәгең булгандыр инде.

Балалар күрсәтәчәк кайгы-хәсрәтләрнең башы гына икән әле бу. Әбинең уллары-кызлары үсә төшеп, кул арасына керә башлагач кына, сугыш чыга.

Счетовод булып эшли башлаган, әнисенә ара-тирә такта чәен, шикәрен юнәтеп торган улы — игелекле, мәрхәмәтле җан Фәһметдин абый — Сталинград сугышында башын сала. Уртанчы улы Вәкилне (минем әти була инде) — атка камыт киертергә дә буе җитмәгән бот буе малайны — урман чыгарырга алалар. Шунда аның үшән биясен агач басып үтерә. Заман кырыс. Син — тол хатын, дүрт балаң бар, улың сугышта үлде дип тормыйлар — атны түләтәләр. «Ул вакытта ат түләүнең ни икәнен башына төшкән кеше генә белә», — ди әбием. Инде бурыч калмады, котылдым дип күңеле үсеп йөргән көннәрнең берсендә әбигә тагын киләләр:

— Хәерниса түти, бүген урман чыгарганда...

Тагын ат!

Тагын түләргә!

Бар икән күрәселәр! Ат хәсрәте үзенең дә йөрәгенә чөй булып кадалган әти нишләсен инде. Бер читтә җилкәләрен салындырып, башын иеп, борын тартып, шул мәлдә үзе дә үләргә әзер булып басып тора.

«И улым, улым. Шунда атың урынына үзең агач астында калып үлсәң, миңа җиңелрәк булыр иде, дидем. — Әби бу сүзләрне әйткәндә көрсенеп, авыр сулап куя. — Күргән нужалар, михнәт-газаплар йөрәгемә төшкәнгә күрә әйткәнмендер инде. Ул бичара баламның үзенең дә эче янмаганмыни инде ул чакта. Атларын да әйтер идем инде. Ат димәсәң, хәтере калыр, үзләре шыр сөяк, үзләре хәлсез. Түләдем инде, монысын да түләдем. Кая барасың?..»

Их син кайгы-хәсрәт җиле! Күпме кагарга була тол хатынның капкасын?! Күпме өзгәләргә була аның кан сауган йөрәген?!

Абзар артында бәрәңге пешергән төпчек улының үсеп җиткәч читкә чыгып китеп озак еллар хәбәр-хәтерсез йөрүе, бер кызының җиде ел үлем түшәгендә ятуы... Болар өчен әби кара кайгыга батмаганмы?! Алар өчен җаны сызланмаганмы?! Әле сугыш барганда армиягә алынган һәм җиде ел десантник булып хезмәт иткән улы, ягъни минем әти өчен ут йотып тормаганмы?! Әле ярый авыру кызын килене (әбиемнең оныгы Сәлим абыйның хатыны була) Нәкыя апа бик әйбәтләп караган. Әби аңа көн саен рәхмәт укый.

Әбиемнең башына төшкән кайгы-хәсрәт, нужаларның төпсез тобадай тирәнлеген әйтепләр бетерерлек түгел. Әмма әби сынмаган-сыгылмаган. Авызында кан булса да, төкермәгән. Иң авыр елларда да әби берәүгә дә кул сузып бармаган. Киресенчә, кәтилүк тотып, аның үзенә килгәннәр.

* * *

...Тукта әле, мин — күпме хикәя-легендаларга кергән мәгърур Кафтауга килеп җиткән малай бит әле. Монда пәлтәне суга манчып алдылармыни, авырайды, кирәкмәс бер йөккә әйләнде. Тизрәк саклык камерасына ыргытып котылырга иде.

Киемнәрне тапшыргач, мунча кердек. Мәскәүләр дә яңа гына килеп төшкәннәр, күрәсең. Алар белән бергә юындык. Мунчадан чыккач, безне лагерь киемнәре — юылган, үтүкләнгән штормовкалар, буденовкалар көтеп тора иде. Шулай итеп, күзне камаштырырлык чуарлык — кара, сары, яшел, зәңгәр, кызыл, кызгылт, шәмәхә, тагын әллә нинди төсләр бер сәгатьтә юкка чыкты. Гүя мунчада юып төшердек үзләрен. Барыбыз да яшелгә төрендек.

Без, малайлар, әзер. Тик кызлар гына озак юына, озак киенә. Үзләрен көтә-көтә күз күгәреп бетте. Ниһаять, чыга башладылар. Алар да штормовкалардан, буденовкалардан. Чү, миңа ни булды? Баш әйләнеп китте. Таулар биешергә тотынды. Тән эсселе-суыклы. Каршымдагы таныш булмаган бер кызның миңа төбәлгән мөлдерәмә кара күзләре, ирен читенә кунган сизелер-сизелмәс елмаюы нишләтеп ташлады бит, ә! Ул арада мунчадан дәррәү чыга башладылар. Теге кыз «толпа» арасында эреде, юкка чыкты.

Мунчадан соң безне отрядларга тараттылар. Өч тәүлек буена юлда бер-беребез белән танышып, хәтта дуслашып өлгергән якташлар тегендә-монда чәчелеп бетте. Минем үземә Куйбышев районы Яңа Рәҗәп авылы малае Рифкать Хуҗиәхмәтовтан аерылу бик авыр булды. «Яшь ленинчы» аша танышып, хатлар язышып тордык без. Ходайның рәхмәте, күрешергә дә насыйп булды. Рифкать — сәләтле малай. Рәсемнәрне коеп куя. Хикәяләре дә шәп, гади, мәгънәле. Каян темасын, каян сүзен таба, каһәр?!

Мин «Стремительная» дружинасының җиденче отрядына эләктем. Отрядыбызның яртысы диярлек Мәскәү балалары. Аларны аермаганнар. Хәер, үзләре дә күп бугай. Тагын Мурманск, Киров, Хабаровск малайлары, Свердловск, Ленинград кызлары, бер якут, Биробиджаннан яһүдләр бар. Бәй, Казан кызы Рая (йә Рәшидә, йә Рәйханадыр инде ул) Хәмидуллина да безнең отрядта икән бит. И сөенештек тә инде. Иңнәренә агып төшкән кара чәчле, кыйгачланып килгән кара кашлы, моңсу карашлы бик матур кыз. Отрядта иң матуры — ул! Үзе ярдәмчел, үзе ихлас. Самимилегенә бераз гына беркатлылыгы да кушылып китә. Мине иң сөендергәне — Раяның татарча белүе.

Әй «Бөркеткәй», «Бөркеткәй»... Менә син нинди икән! Тау итәгендә ике озын бина тәрәзәләрен чекерәйтеп диңгезгә карап тора. Берсендә — безнең «Стремительная», икенчесендә «Звездная» дружиналары. Ә диңгезгә терәлеп торган ташпулатта «Штормовая» пионерлары яши. Уртада — зур стадион. Бер читтә — мәктәп. Ишегалдында — самолетлар. Безнең авыл өстеннән гел очалар иде алар. Каршыдагы тауга таба очканда җиргә төшкән кебек булалар. Без, ахмак беркатлылар, ышанып чабабыз. Әлсерәп, телне асылындырып тауга менәбез. Анда исә самолет та юк, черт та юк. Ниһаять, күрдем үзләрен. Хәер, самолет кынамы соң... Монда килгәндә Мәскәүдә бер поездан икенчесенә күчеп утырдык. Шунда вакыт табып, безне озатучы журналист Мәҗит Вәлиуллин — күпертеп артка таралган озын калын чәчле, аз сөйләшә торган ипле, җайлы абый — Мәскәүне күрсәтте, космос музеена алып керде. Безнең ише космос дип ах иткән малайлар өчен гаҗәеп кызыклы музей. Дөньябызны онытып карадык, үзебез дә галәмгә очкан күк булдык.

Бераздан төшке ашка чакырдылар. Ашханә дигәннәре беренче катта. Зур тәрәзәле якты, матур зал. Озын өстәлләр. Табын әзер. Иң әүвәл зур тәлинкәләргә чөмәкәйләп өеп куелган әфлисуннар күзгә ташлана. Алар шундый матур булып балкыйлар ки, гүя өстәлебезгә кояш үзе төшеп утырган. Башта салат ашадык. Аннары — борщ, бәрәңге боламыгы белән котлет. Ниһаять, әфлисуннарга да чират җитте. Һәркемгә берәр җимеш. Их, авылга алып кайтып әбине сыйлыйсы иде моның белән. Көньяк күчтәнәче!

Тансык ризыкны әби белән бүлешеп ашарга гадәтләнгән мин. Бары — бергә, югы — уртак. Әфлисун түгел, борчак хәтле бер каен җиләген дә бүлешеп ашыйбыз әле без әби белән. Яртысы — аңа, яртысы — миңа. Җәйнең беренче җиләге була ул. Сыртын кояшка кабартып куйган артыш тавында, ялгыз чыршы төбендә пешә. Ничә ел күзәтеп йөрим, җиләк шунда кызара башлый. Җиләк әле чәчәктә генә, ә мин көтәм. Көтәм, көтәм... Көтә-көтә көтек булам. Көнгә артышлыкка кырыкмаса-кырык тапкыр барып кайтамдыр. Сәпитемә атланам да чыгып чабам, атланам да чыгып чабам. Акрын кызара. Җиләкнең очында бер-ике кызгылт төртке пәйда булуга, мин аны учыма куеп биетеп алам:

— Кызар инде, җиләккәем, тизрәк кызар!

Чү, мин аны үзем дә сизмичә өзеп алганмын бит инде.

Өйгә чабам...

Өйдә «ташбаш»ны пычак белән урталай бүләбез. Җәйнең көтеп алган мизгеле. Пешеп өлгермәгән җиләкнең ачысы телне әчеттерә, авызны бөрештерә. Тешсез әби аның тәмен дә тоялмыйдыр. Әмма без бәхетле. Бездән дә бәхетлерәк кеше юк!

...Мәскәү балалары әфлисуннарын ни арада җимереп ташладылар. Мин тирләгән учымда әвәләп утырам. Ашаргамы, юкмы? Авыздан сулар килә. Әфлисунның хуш исеннән борын яфраклары кытыклана, башлар әйләнә. Юк, мокыт булып күренсәм-күренермен, ашамыйм әле мин моны. Бүлмәгә алып менеп, тумбочкама куям. Тагын эләгәме, юкмы әле ул. Бүген безнең килү хөрмәтенә генә чыгарганнардыр аны.

Әфлисунны авылга, әбигә алып кайтачакмын!

*** * ***

Лагерь көннәре бер-бер артлы үтә тора. Рәхмәт төшкере, әфлисуннар тумбочкамда бишәү булды инде. Аларны күрүгә, нәфес кузгала. Әмма түзәм, ашамыйм. Хәер, беркөнне берсенең кабыгын тишеп, суын татып карадым әле. Ай-яй тәмле. Әбием авыз итә алса иде инде болардан. Үзе әйтмешли, язган ризык булсын. Язган ризык теш сындырып керер, ди ул. Тик менә авылдан килгән хатлар куандырмый әле мине. «Беркөе генә яшәп ятабыз. Әбиең генә авырый», — дип яза әни. Әнине беләм мин, әби алай-болай була калса да (Алла сакласын!), миңа дөресен язмаячак. Дөресен язса, кояшлы күгемне кара болыт каплап аласын, ялым ял булмасын белә бит ул. Инде «авырый» дип язарга җөрьәт иткән икән, димәк, әби начар. Бүген дә авылдан хат алдым. Әби һаман авырый. Әни «Яшь ленинчы»ны да җибәргән. Әле авылда вакытта ук редакциягә үзебезнең инеш бозында хоккей уйнавыбызны ясап җибәргән идем. Өстебездә — пәлтә-бишмәтләр, башыбызда — озын колакчынлы күн бүрекләр, кулыбызда — кәкре тал ботагыннан кисеп алган кәшәкәләр. Салкында шакырдап каткан ат тизәген куабыз. Газетаның дүртенче битендә шул рәсемемне бастырганнар. Янымда әби булса әйтер иде: «Рәхмәт, улым, Нуретдин бабаңның исемен балчык астында яткырмыйсың», — дияр иде.

Рәсемгә сөендем. Газетаның икенче битендә Ибраһим Газиның салкын кара рама белән әйләндереп алган фотосын күргәч, кәефем тагын кырылды. Әйбәт язучы иде. Урыны җәннәттә булсын.

Авыр уйлардан арынасым килеп, башымны чайкап куям һәм тагын тумбочкамны ачам.

Их әфлисуннар, әфлисуннар!..

Әбигә насыйп ризык булсагыз иде, Ярабби!

*** * ***

Юк, насыйп ризык булмаган икән...

Беркөнне төш турыларында бүлмәбезгә ак халатлы ике апа килеп керде. Килеп тә керделәр, без 17 малай яшәп яткан чиста, зур бүлмәне тутырдылар. Шүрәленеке кебек озын (һәрхәлдә, миңа шулай тоелды) бармаклары белән өстәл-тумбочка өсләренә кагылдылар, караватларыбызны капшадылар, тәрәзә астындагы батарея араларына кереп чыктылар. Күренеп тора, тузан эзлиләр. Мин, авызны күтәреп, аларга карап утырам икән, ә тумбочкамның ишеге ачык калган. Шунда берсенең күзенә минем әфлисуннар чалынган бит.

— Нинди склад бу?! Таракан үрчетергә җыенасыңмы? Бер сәгатьтән тагын кереп карыйбыз. Берсе дә калмасын!

Мин — күндәм малай. Күндәм өндәмсез эшләр. Бүлмәдә Сережа белән икәү генә идек. Сережа — Мәскәү малае. Без аны «Серый» дип йөртәбез. Мул итеп чәч җибәргән, зәңгәр, ялтырап тора торган очлы күзле, кубалак иренле. Сөйләшкәндә тотлыга. Тотлыкса да, күп сөйләшә. Җитмәгән җире юк. Ишектән кусаң, тишектән керә.

Тотындык Серый белән әфлисун ашарга. Уф, җаның теләмәгәндә ашаган ризык ризыкмыни! Авыз тутырып әфлисун чәйним. Суы ирен читеннән муенга агып төшә. Ни тәме, ни ләззәте. Авызда үсә. Серый исә ура гына. Ашап бетердек әфлисунны.

Тумбочка мәет чыккан өй кебек караңгыланып, котсызланып калды.

Әнинең хатын кабат укыйм. «Тик әбиең генә авырый» дигән сүзләрне «ышкый-ышкый» күзләрем кызарып чыкты. Шул юл турысында кәгазьгә тамган саргылтым бер тап та бар. Бәлки, май-мазар тигән булгандыр. Ә мин аны әнинең хат язганда тамган күз яше итеп кабул иттем. Әби турындагы авыр уйлар тагын да куерды. Тәмам хәсрәткә чумдым.

Сине юатырлык, сине мәэюслек хәленнән чыгарырлык, әбиемнең исән булуына өмет уятырлык бер кешең булса иде янында. Вожатыйларыбыз Марина белән Нина апаларга әйтеп карарга була да бит. Икесе дә безнең өчен үлеп тора. Белер-белмәс русчам белән сүз кузгатасым килми. Бәй, Рая бар бит. Хәлбуки ул үзенең самимилеге, төчелеге белән сине кызгана башлаячак. Аның моңсу күзләрен яшь пәрдәсе каплап алачак. Йөзендә газаплы теләктәшлек билгеләре чыгачак. Үзе дә елаячак, сине дә елатачак. Юк, кирәкми аңа әйтергә. Малай башым белән кызлар алдында балавыз сыгып тормам бит инде.

* * *

Безне монда «орлята» дип йөртәләр. Безнеңчә — бөркет балалары. Мәшһүр композитор Александра Пахмутова белән мәшһүр шагыйрь Николай Добронравов та «Орлята учатся летать» дигән шәп җырны нәкъ менә «Орленок»та булып киткәннән соң иҗат иткәннәр. Иҗат дигәннән, лагерьда минем өчен авыр уйлардан бераз арынып, күңелгә азмы-күпме юаныч табып торырлык урын — рәсем түгәрәге. Без — «бөркетләр» — кәгазь, буяу, пумалаларыбызны алып балконга чыгып утырабыз. Каршыбызда — диңгез. Барысы да диңгезне ясый. Ә минем күңелдә — авыл, үзебезнең Кесмәс буйлары. Бик сагындым туган якны. Син, диңгез, миңа үпкәләмә. Син, Кафтау, миңа үпкәләмә. Нишлим соң? Шагыйрь әйтмешли, үз тавын сагынмаган бөркет бөркетмени!

Берәү армиядән авылга хат җибәргән, ди. Болай дип язган, ди:

Сагынам күперләрне дә,
Гата-чатан,
Шәмәк-чулак,
Шакир-кутырларны да.

Сагынырсың шул! Безнең авылга акылга таманрак Масра Гөлсем белән Чыңгызхан күзле Фатыйма әбиләр килеп йөриләр. Шулар да искә төшеп куя. Килгән саен алар: «Әйдә, тәтә, чәй эчик әле», — дип, әби янына керәләр. Әби исә аларның авылга килүен ишетеп өлгергән, самавырын кайнатып куйган, хәзинәдә барын өстәлгә чыгарып тезгән. Чәй эчкәннән соң, Масра Гөлсем әбинең калай чиләгенә бер-ике йомырка да саласы.

И туган як! Муенына — камыт, иңенә ыңгырчак суктырса да, кәҗәләнми эшләп йөргән талымсыз атларың, юеш танаулы мәхлук бозауларың, син килгәндә капка астына кереп кача, киткәндә артыңнан өреп кала торган мактанчык көчекләрең, яз җылысын тансыклаган иркә мәчеләрең истән чыкмый. Истән чыкмый синең әрсез чыпчыкларың, әҗәткә баткан каргаларың, тишек башлы күкеләрең... Урманыңдагы сугыш чукмары наратларың, юаш юкәләрең, күп сүзле усакларың... Басуыңдагы әшәке-әче телле билчәннәрең, тәрбиясез алабуталарың, ялагай-җаһил эт эчәгеләрең...

И газиз туган як!

Башкаларның калын ак кәгазендә диңгез дулкыннары чайкалганда, минем пумалам-кыл каләмемнән каеннарның яшел яфраклары тама. Кара диңгез дулкыннарына сарыф ителәсе зәңгәр буявым кечкенә генә инеш булып ага. Бу — Кесмәс. Аның да кайсы җире диген әле — Гафифә әбинең бакча башы. Елгабызның борылган урыны, иң тирән, иң хәтәр төше. Шунда коенабыз, чирәмдә ауныйбыз. Җәй рәхәтен шунда күрәбез. Гафифә әбинең бәрәңге бакчасы бераз таптала инде тапталуын. Әмма безгә сүз әйтүче юк.

Ызанда Гафифә әби пәйда булуга, без качмакчы булабыз. Әби исә безгә карап елмая гына. Аның елмаюы шулкадәр ихлас ки, бу минутларда йөзендәге җыерчыклары да елмая кебек. Ул бакча башын үз итүебезгә сөенә генә бугай. Һәрхәлдә, миңа шулай тоела. Кара көзләрне, озын-озак кышларны, ярсулы язларны читтә, елга аръягындагы ялгыз өйдә ялгызы үткәргән карчык өчен без, бәлки, бер иптәштер. Караңгы төннәрдә өенә керергә теләп котырынган буранның улавыннан, электр баганаларының хәвефле сызгыруыннан, морҗаның әле моңланып, әле шомланып җырлавыннан гайре тавыш ишетмәгән һәм шул тавышлардан гарык булган күңеленә безнең шатлыклы авазларыбыз, чәтертән малайларның, чебен тимәс чер итәр кызларның чытлыклы чыр-чулары, бәлки, йөрәгенә ятышлы бер җырдыр.

Ватаныбыз — СССР, диләр. Аның бер башында кайнар ком, икенче башында котсыз котып, диләр. Ватан — Туган ил бит инде ул. Туган як! Комлыклар, котыплар миңа туган якмы соң?! Минем туган як — Кесмәс. Аның да без су коена торган төше. Күр әле, минем туган як Гафифәттәйнең унҗиде буразнасына сыеп беткән түгелме соң? Юк, кызыл йөзле оялчан җиләкләренә качарга печәннәрен өлгерткән Мөхетдин, Әсәт аланнарын, тук гөмбәләрен калын яфрак түшәге астына яшергән Сорна юкәлеген кая куясың? Кая куясың сарык көтүе, кәҗәләр киң вә тар сукмаклар белән чуарлап бетергән Шәрәфи, Әсретдин коры елгаларын, итәгеннән тибеп чыгып юлын зур елга-диңгезләргә кадәр сузган кәүсәр сулы чишмәгә хәер-фатиха һәм егәр биргән Кирәмәт тавын?! Аларны да бик яратам. Ә хәзергә мин рәсемемдә сурәтләгән Гафифәттәйнең бакча башы минем өчен Туган як та, Туган ил дә, Ватан да.

Иртәгесен ни күрим, рәсемнәребезне зур залның диварына элеп куйганнар. Күргәзмәдә — диңгез генә. Дөньясын су баскан да, минем каен-таллар гына исән-имин калган дип уйларсың.

Читтән генә күзәтеп торам, үткән-сүткән һәр кеше рәсемем янында тукталып кала. Диңгезнең колак ияләшеп бетә алмый торган шавыннан еракта җирнең дымын, җилләрнең шифасын буйларына сеңдереп утырган көяз каеннар, Кесмәсемнең аһәңле моңына башын игән моңсу таллар аларга да туган якларын искә төшерә, күрәсең.

Шул вакыт яныма минем белән рәсем түгәрәгенә йөрүче ике малай килеп басты.

— Син Татариядән бит әле? — дип сорады аларның берсе, минем рәсемемә карап.

— Әйе!

— Безнең отрядның вожатые да Татариядән бит. Фатхулисламова Соня. Город Арск бармы сездә? Менә шуннан ул.

— Бәй, мин дә шуннан бит. Арск минем дә Родина бит инде ул.

* * *

Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына, ди. Рәсәй картасында бер нокта гына бит инде ул Арча. Шунда туып, туган ягымның мин сулаган һавасын сулап, мин коенган суларында коенып үскән бер апа монда — Кафтауда, Кара диңгездә вожатый булып эшләп йөрсен инде, ә! Их, күрергә иде бит аны. Рәхәтләнеп сөйләшеп утырыр идек.

Аллага шөкер, борчу-хәсрәтләрне уртаклашыр кеше табылды.

Коридор диварында вожатыйларның исемлеге эленеп тора. Анда кемнең кайчан дружина буенча дежур торачагы күрсәтелгән. Фәтхелисламова. Якташым, райондашым! Бәй, иртәгә аның чираты. Без йокыдан торуга, бүлмәбезгә үзе керәчәк ул. Одеялны караваткa дөрес япканбызмы, мендәрне дөрес куйганбызмы? Шуны тикшерәчәк. Менә бит күрешергә җае да чыгып тора.

Ул төнне керфек какмадым. Тизрәк, тизрәк, тизрәк... Таң атсын. Фәтхелисламова апа керсен. Минем Сеҗедән икәнне белгәч, үзе дә гаҗәпкә калыр әле ул. Аның да минем белән бер сөйләшеп

утырасы килмәс дисезме? Аның да күңеле якташларын һәм татар телен тансыкламагандыр дисезме? Арча малайлары монда гел-гел килеп тормыйдыр әле.

Ниһаять, подъем!

Саумы, иртә! Саумы, кояш! Саумы, якты көн! Миңа бәхет вәгъдә иткән көн.

Әһә. Керде, керде. Туры борынлы кара-чутыр апа.

Үзебезчә, саф татарча эндәшәм үзенә:

— Сез Фәтхелисламова апа бит, име?

— Да!

— Апа, сез Арчадан икән ич, име?

— Да, из Арска.

— Мин дә Арчадан ич. Сеҗедән мин, апа. Сеҗедән. Сеҗене беләсезме?

— А ты постель заправил? Ну-ка покажи!

— Менә минем караваt. Шушында йоклыйм мин, апа.

— Заправь как следует. Одеялың җыерылып калмасын.

Якташ апам бүлмәбезгә тагын бер кат күз йөртеп алды да кәс-кәс атлап чыгып та китте. Мин аптырап басып калдым. Менә сиңа күрешү! Ярый әле соңгы җөмләсен татарча әйтте. Шунысы да күңелгә азмы-күпме юаныч булып куйды. Кая ул хәл-әхвәл сорашулар... Кая ул әби турында сөйләшү. Булмады. Берсе дә булмады. Аның «Әбиең терелер, борчылма» дигән өч сүзе җитә иде бит югыйсә.

Мин шып итеп караватыма утырдым.

Кемдер каядыр чакырды. Кемдер җилкәмә кагылды. Тик мин аларны ишетерлек-күрерлек хәлдә түгел идем.

Каттым да калдым.

* * *

Тукта, нишләп әле мин, әби дия-дия, үз итемне үзем ашыйм соң?! Мин бит шома, биек кәүсәле, җилпәзә сыман эре яфраклы пальмалар, дан-шөһрәт символы — хуш исле лаврлар, мәңге яшел магнолияләр илендә.

Диңгезне күр әле син!

Күр тауларны!

Нинди манзара! Нинди хозурлык!

Башыннан итәгенә хәтле куе яшел бөдрәләр белән капланган мәһабәт-мәгърур тауларга офыктан ук йөгерешеп килгән җитез дулкыннар бертуктаусыз нидер сөйлиләр. Гүя диңгез — тауларның җырчысы, сердәше, мәхәббәте...

Диңгез һәм таулар. Диңгез ярсып, дулап алганда да, таулар тыныч, сабыр. Давыл купканда да, диңгез холкын күрсәткәндә дә, таулар дәшми. Их, шул таулар кебек борчылмыйча, көймичә-көйрәмичә яшәсәң иде ул. Син монда әби дип ут йотып йөрисең. Отрядыбыз белән тауга менеп, диңгезгә хозурланып торганда, башка шундый уйлар килде.

Таудан төшкәндә, Сережа бер түмгәккә сөртенеп егыла язды. Шул мәлдә ачы итеп, яман сүгенеп алды. Нинди әшәке сүзләр! Әч-чак норсыз. Сүгенгәндә тотлыкмый тагын үзе.

Серый сүгенде. Мин тагын әбине искә төшердем инде. Шулай бервакыт биш-алты яшьләр тирәсендә, үзем дә белмичә-аңламыйча, урамнан ишетеп кайткан бер оятсыз сүз әйтеп ташлаганмын.

— Һай улым, — диде әби, өстәл янында утырган җиреннән ике кулы белән ике тезенә сугып, — нишлибез инде?

Мин ни булды икән дип гаҗәпләнеп карап торам.

— Авызыңа әшәке сүз кергән бит! — Әби почмыякта (авыл өендәге кухня. — *В.Н.*) әрле-бирле йөренә башлады. Караваt астыннан җиз комганын тартып чыгарды, аңа кече учак өстендәге мич казаныннан җылы су тутырды. Аннары зур табак алып идәнгә куйды да мине шул табак янына чакырды.

— Әйдә, улым, чайкыйбыз авызны. Иел. Мин учыңа су салып торам.

Һай шунда күргәннәр. Һи-и-и, авыз чайкауның ние бар, диярсез инде сез. Бер казан су беткәнче чайкап карагыз әле. Комган артыннан комган. Әби суны тутырып кына тора.

— Җитәр инде, әби, — дип ялварып карыйм.

— Алай гына бетми әле ул, улым. — Әби тагын учыма су коя.

Авызны чайкый-чайкый, тел әчетә башлады. Аңкауны көзән җыерырга тотынды. Табак өстенә иелә-иелә бил калмады. Җитмәсә, әби: «Улым, озаклап чайка, әйбәтләп чайка, әшәкесе кала күрмәсен», — дип үҗәтләнә-үҗәтләнә тукып тора.

Сережага мондый сабак эләкмәгән, күрәсең. Мәскәүдә су үзе өйгә килеп тора бит югыйсә. Без ерак чишмәдән ташып та, әби җиде-сигез комган суны җәлләмәде.

* * *

Оксана Буряк — безнең отряд советы председателе. Кырыс, усал кыз. Берәр эшне ул дигәнчә эшләмәсәң, беттең. Оксанадан эләгәчәк. Әллә Сусловның, әллә Громыконың оныгы диләр аны. Булыр-булыр. Күз карашы зәһәр. Нәкъ Громыконыкына охшаган юка иреннәр, текә маңгай... Чәче артка тарап, колакларына салындырып төшерелгән.

Оксана Буряк көн саен диярлек җыелыш җыя. Кемнеңдер тәртибен тикшерә. Аның янында селкенергә дә ярамый. Вакыты-вакыты белән отряд командирына ни куштан инде Серый, Буряк аның да тетмәсен тетә генә. Оксанага карап-карап торам да уйлап куям: «Бу кызның әбисе юкмы икәнни? Булса да аны сагынмыймы икәнни? Гомумән, ул бу дөньяда сагыну, ярату барын белмиме икәнни?»

Төн. Бар да йоклый. Мин йоклый алмыйм. Уйда — әби... Шул вакыт ишек ачылды. Коридордагы лампочканың сүрән яктысы бүлмәгә саркып керде. Кем анда? Рая Хәмидуллина икән. Нишләп йөри инде? Җиде төн уртасында безнең бүлмәдә аңа ни калган?

Рая туп-туры минем карават янына килде:

— Вакыйф! Син йокламыйсың мәллә? Оксана Буряк авырый. Син безгә кереп, аның маңгаен тотып кара әле. Яна! Үлә бит инде.

Керәм. Кызлар йоклый. Әнә Оксананың караваты. Иң түрдә, башкалардан читтә үзе бер дәүләт булып, җәелеп-таралып ята. Кызның маңгаена кулымны куям.

Абау!

Һушыңны алырлык әче тавыш. Оксана сикереп тора. Кызлар сикереп тора. Безнең бүлмәдәге малайлар уяна. Мәхшәр. Бетте баш. Иртәгәме? Иртәгә булачак хәлләр... Мәскәүгә, Кремльгә жалу китәчәк. Громыко килеп җитәчәк. Мине эттән алып эткә салачаклар, изәчәкләр, сытачаклар.

Вәйт дурак димә инде мине. Төнге сәгать 2 дә тып-тыныч йоклап яткан Громыко кызына кем ябыша инде?!

Хәмидуллина исә авызын ерып басып тора.

Ну, Рая!..

Ну, Рая!..

Ну, Рая(ц), погоди!

Иртәгесен, ни гаҗәп, отрядта бернинди шау-шу булмады. Тагын да гаҗәпләндергәне — йокыдан торып зарядкага чыкканда, гомер булмаганны, Оксана Бурякның мине елмаеп сәламләве.

Кичен «Время» СССРның тышкы эшләр министры Андрей Андреевич Громыконың чит илгә рәсми булмаган визит белән китүен хәбәр итте.

* * *

Бүген кич лагерьда тансы. Җырларга дисәң, минем колакка аю баскан, биергә дисәң, аякларым мишәйт итә. Утырып кына торам.

Салмак көй... Кемдер «белый танец» дип кычкырды. Кызлар егетләрне үзләре чакырырга тиеш икән. Бер пар чыкты. Ике, өч пар. Шулай да биючеләр азрак әле. Утны сүндерүләре булды, зал куера башлады. Мине — як-якка тырпаеп торган, киребеткән камыл чәчле, борынына-битенә мул итеп сипкел сибелгән малайны кем чакырсын инде? Шулай кимсенеп, ким-хур булып утырганда,

берьюлы ике кыз килеп дәште. Берсе — Оксана Буряк, дисәм, ышанасызмы? Икенчесе — буйга минем белән бер чамадарак таныш булмаган кыз.

Кайсын сайларга?

Мәсьәләне Оксана хәл итте. Кулымнан тартып торгызды да биючеләр арасына алып кереп тә китте.

Каян чыккан хәл бу? Беренчедән, председателебезне тансыда күргән юк иде әле! Икенчедән, бу горур, тәкәббер кыз ничек мине чакырасы итте икән? Теге вакыттагы «рәсми булмаган төнге визит» галәмәте түгелдер ич.

Бию диген инде моны. Миннән бер башка озынрак Оксана янында үземне әнисенең итәгенәябышкан елак малай кебек хис итәм. Өйләнгән булабыз. Авыр миңа. Ул дәшми. Мин дәшмим. Төнге хәлләрне искә төшерәсе килми. Аптырагач председателебездән сорап куям:

— Син Мәскәүдә мавзолейдан ерак торасыңмы?

— Мавзолей янында ук.

Ленин янына көн саен кереп чыгарга була дип уйлап алам. Без авылда двор өенә (конюшня ишегалдына ат сбруйларын киптерү өчен салынган йорт. — *В.Н.*) кереп чыккан кебек. Ул арада минем бәхеткә җыр да тәмамлана, без Оксана белән бер-беребезне ычкындырабыз.

Оксанадан котылуга, күзләрем бая мине тансыга чакырырга теләгән икенче кызны эзли башлады. Әнә ул. Кайда күргәнем бар соң аны? Йөзе, күзләре, елмаюы таныш. Бәй, лагерьга килгән көнне мунчадан чыкканда күргән кыз бит. Шул үзе. Зур кара күзләр, тыйнак елмаю. Ул да, мөгаен, Мәскәү кызыдыр. Бая нигә мине чакырасы итте икән ул? Йомшак-күндәм чәчле, сипкелсез малайлар беткәнмени.

Дәртле җырдан соң тагын салмак көй башланды. Безнең карашлар очрашты. Мин Аның янына килеп басканымны һәм бер-беребезгә тотынышып уптым илаһи әйләнә башлавыбызны сизми дә калдым. Матур кызның иңнәренә агып төшкән туры чәче битемә тиеп китә, һәм минем табан астына кадәр кайнар ток йөгерә. Каушыйм. Каушавымнан Аның аягын да таптап алам. Киеренкелекне йомшартыр өчен сорау биргән булам:

— Син Мәскәүдә мавзолейдан ерак торасыңмы?

— Мин Мәскәүдә тормыйм.

— Каян соң син?

— Урал тавыннан мин. Урал кызы!

Урал кызы! Урман кызы турында ишеткәнем, укыганым бар. Үзебезнең урманда да бар ул. Өч өйле Гәр-Хуторда яши. Җәйге челләдә урманда печән әзерләгәндә, җиләк җыйганда, безгә үзләренең коесыннан тешеңне сындырырлык салкын су алып бирә. Без аны Урман кызы дип йөртәбез. Ә менә Урал кызын — Тау кызын күргән юк иде әле.

— Урал кызы дисең инде алайса. Ә мин Татариядән. Татар мин.

— Татар. — Тау кызы серле генә елмаеп куя.

Безне «әйләндергән» көй соңгысы булган икән. Таралыша башладык. Урал кызын ай күрде, кояш алды. Мин аның исемен дә сорап калалмадым. Урал кызы түгел, югал кызыдыр ул, валлаһи. Көтмәгәндә пәйда була, күз ачып йомган арада югала. Күп сөйләшми, башка кызлар кебек, кырыкмаса-кырык сорау биреп, сине тинтерәтми. Буряк турында гына: «Сине тансыга чакырган теге озын кыз Косыгинның (Громыконыкы диме) внучкасы мәллә?» — дип сорап куйды. Аннары болай дип өстәде: «Үзеңне нинди кызлар тансыга чакыра!»

Беркөнне булган төнге маҗаралардан ул хәбәрдар түгел.

*** * ***

Һай, шул пионер лагеренда тезеләсе булмасын иде. Югыйсә кая барма, мәктәпкәме, музейгамы, мунчагамы, отряд белән тезелеп барасы, тезелеп кайтасы. Ул сафта йөрүләрдән тәмам гарык. «Орленок»та таләпләр аеруча кырыс. Үзең генә беркая да чыга, беркая да баралмыйсың. Бөтен җирдә фәкать отряд белән йөрисе. Шуның аркасында Рифкатьне дә күрә алган юк. Безнең аралашу отрядлар кара-каршы очрашканда кул күтәреп, сәлам биреп китүдән узмый. Күрешәсе, сөйләшәсе, күңелне бушатасы килә югыйсә.

Сочида дөньядагы барлык агач-куак, үсемлекләрне үзенә сыйдырган гаҗәеп бакчаны, андагы матурлыкны, космонавтлар утырткан агачларны карап йөргәндә, бер-ике сүз алмашып алырга өлгердек.

— Баегансың, — ди Рифкать.

— Көлмә инде...

— Беркөнне отрядыгыз белән каядыр бара идегез. Кул болгап карадым. Кычкырып карадым. Сәлам дә бирмәдең.

Үз уйларыма чумып барган вакыт булгандыр инде. Хәзер кая гына барсак та, каршыга килүче һәр отрядны энә күзеннән үткәрәм. Югыйсә Рифкать тагын «баетачак» мине.

Беркөнне стадионга бара идек. Каршыга бер отряд килә. Минем күзләр очланды. Рифкатьне эзлим.

Чү! Барган җиремнән туктап, баганадай катып калам. Отряд аны-моны сизми, атлавын белә, чөнки мин, буем кечкенә булу сәбәпле, иң артта, «замыкающий»лар рәтендә. Ни күрим, Ул да туктап кала. Мөлдерәп, дусларча карап торган зур күзләр. Ирен читендәге саран елмаю. Урал кызы! Минем Аңа ниндидер тылсымлы сүзләр әйтәсе килә. Ләкин сиңа кирәк вакытта табыламыни соң ул сүз! Бу очрашу мизгел эчендә булды. Урал кызы уң кулын өскә күтәреп, ак-нәфис бармакларын селкетеп алды да китеп барды. Мин беравык тынсыз-өнсез басып тордым әле. Аннары сабыр, горур кызның зифа буеннан, якты йөзеннән, акыллы күзләреннән аңлатып булмаслык татлы тойгылар ияртеп, отрядны куа киттем.

* * *

Календарьга карыйм. Бүген 25 март. Тагын өч көннән лагерь белән хушлашабыз. Минем өйдән чыгып китканемә 41 көн икән инде. Әфлисуннарым тагын байтак җыелды. Хәзер инде мин аларны тумбочкага түгел, чемоданыма сала барам. Көн саен бер ачып карыйм үзләрен. Уемда гел авыл, әти-әни, апай, туганнар, классташлар, авылдашлар. Һәм, әлбәттә, әби. Үземнең 41 көн әбисез торуыма гаҗәпләнәм. Авылда аннан башка бер көн дә тора алмый идем бит.

Һәр елны кышка кергәч, маллар суйгач, әби кунакка китә. Китә дип инде, әллә кая бармый, авылның түбән очына гына. Шунда бер ун көн чамасы оныгы Сәлим абый белән аның хатыны Нәкыя апа хозурында, алар тәрбиясендә яшәп ала. Әбине алып төшеп китәләр, ә минем өчен караңгы көннәр башлана. И-и-и ул мәктәптән ишеге тышкы яктан көрәк сабы белән терәтелгән ялгыз өйгә кайтып керүләр. Әти-әни эштә, апай укуда. Аның дәресләре соңрак бетә. Сумкамны идәнгә ташлыйм да түбән очка очам. Әби елмаеп каршы ала. Мин ярты көн Сәлим абыйларда ятам. Караңгы төшә башлагач кына өйгә кайтам. Бер көн уза, ике, өч көн... Болай йөрү туйдыра, һәм минем башта бер план туа: әбине урларга! Ничек урлыйсын да беләм. Һәр көнне кичке дүртләр тирәсендә колхоз кәнсәләрендә нәрәт. Аңа күрше Ташкич авылыннан да төшәләр, Мөрәледән дә киләләр. Һәркайсы ат белән. Берәрсенең атын сорап торам. Әбине түбән очтан югары очка алып менәргә кирәк иде, дисәң, кем каршы килсен.

Барысы да нәкъ мин уйлаганча була. Ташкич аты белән капка төбенә килеп туктыйм. Сәлим абый да, Нәкыя апа да эштә. Әбигә киенергә биш минут вакыт бирәм. Ул, әлбәттә инде, ике кулы белән башын тота, аптырашта кала, каушый, нишләргә белми. Отыры минем бу өйдән аннан башка чыгып китмәячәгемне аңлый. Киенә башлый.

Капка төбенә чыгабыз. Шөкер, кеше-мазар күренми. Әбине чананың түренә урнаштырам, үзем бер кырыйга чүмәшәм.

— Әйдә, малкай. На!..

Сез безне туры өйгә кайта дип беләсезме? Кайта ди... Еллар буена каралты-кура тирәсеннән беркая да китмәгән әбине авыл буйлап экскурсиядә йөртәм әле. Башта чаптырып кына мәктәпкә барып киләбез. Аннары фермага юыртабыз. Әби саламга чумган. Бахбай бертуктаусыз пошкыра. Сәяхәтебез Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашлар истәлегенә салынган һәйкәл янында тәмамлана.

Һәйкәл!.. Анда әбинең шушы яуда башын салган улы Фәһметдин абыйның да исеме язылган. Әби салам эченнән башын чак кына калкытып һәйкәлгә карап куя. Бу мәлдә ат та пошкыруыннан туктап тора.

Аннары — өйгә. На-на!.. Атка дилбегә белән җиңелчә генә кагып, чөңгереп алам.

Капкага килеп туктаганда, әби чанага тәмам сеңеп беткән була.

Бу сәяхәттән соң әбекәй бер-ике көн урыннан тормый. Үзе авырмый да. Авырса, әйтер иде, зарланыр иде. Юк, тормый ятуының хикмәте бар икән шул: ат чапканда төшеп калудан куркып, әби чанага шулкадәр нык ябышкан ки, аның кул башына, беләгенә кан сауган икән. Моны миңа соңрак әни тиште.

* * *

Бүген лагерьда иртәдән ыгы-зыгы. Китәбез! Ниһаять, туган якларга!.. Башта Биробиджан малайларын озаттык. Аннары — Сахалин, Ленинград, Киров... Ә без — Татарстан төркеме — иң соңгысы. Бөтенесен озаткач, кем әйткәндәй, капканы ябып, йозакны элеп китәргә тиешбез.

Көн буена урамнан кергән юк. Озатабыз. Кул кысышулар, кочаклашулар, адреслар бирешү, күз яшьләре... Тагын кул кысышу, тагын кочаклашу...

Өстә — үзебезнең киемнәр. Алары да сагындырган. Пәлтә белән бүрекне Көньякта түгел, хәзер бездә дә кимиләрдер инде. Яз бит, яз. Мин киеп куйдым әле. Тик бүреге генә кочаклашканда баштан төшеп интектерде. Анысын да бер-ике размерга зурракны алганнар шул. Минем башны бик зур булыр дип уйлаганнардыр инде.

Ниһаять, бөтен Россияне тотып, сыпырып, капшап чыкканнан соң төнгә таба безгә дә чират җитте. Мин юлга әзер. Өскә кигән. Чемодан тутырылган.

Җырлыйсы килә. Соңгы көннәрдә безнең күңелләрдә бер генә җыр:

Звездопад, звездопад —
Это к счастью, друзья говорят.
Мы оставим на память в палатках
Эту песню для новых орлят.

Хуш, «Орленок»!

Хуш, диңгез!

Хуш, Кафтау!..

Тукта әле, кузгалыр алдыннан чемоданымны ачып, әфлисуннарыма тагын бер карап алыйм әле.

Ачсам...

Эчем жу итте...

Әфлисуннар юк!

Әле бер сәгать-сәгать ярым чамасы элек кенә бүлмәгә кереп чыктым бит. Чемоданыма адреслар блокнотын салдым. Бар иде бит алар. Бар иде. Шуннан соң мәскәүләр генә китте бугай инде. Минем чемодандагы әфлисуннарны Сережадан башка берәү дә белми иде.

Ярар инде, нишлисең бит. Тагын әбием сүзләре искә төшә: «язмаган ризык». Минем чемоданга кергән «салкын тәпи»не исә Ходай үзе белер, үзе турылар. Монысы да әбием сүзләре.

Чемоданымны бикләп куймаганыма үкенәм, югыйсә ачкычы бар иде бит. Тагын да үкенечлерәге, Урал кызының ни исемен белмичә, ни адресын алмыйча калдым.

Их!..

* * *

30 март иртәсендә Мәскәүгә кайтып төштек.

Безне алып кайтучы абый да әйбәт кеше булып чыкты. Яше белән ул 50–55 тирәсендә булыр. Чал чәчле чын татар агае. Сабыр, тәмле телле. Үз-үзен тотышына, сөйләшүенә, киемнәренә караганда, әби әйтмешли, урында эшләүче булса кирәк. Обком, хөкүмәт тирәсендә түгел микән. Сорарга батырчылык итмәдек. Сухумига командировкага бардым, ди. Кайтышлый сезне дә кереп

алырга куштылар, ди. Абзыебыз әдәбиятны ярата икән. Ибраһим Газины җирләүдә дә катнашкан. 40 көндә туган телне тансыклагангамы, абзыебыз әдәби сүзләр белән матур итеп сөйләшкәнгәме, без аның авызына гына карап торабыз. Без аңа «Абый» дип эндәшергә күнектек, хәтта исемен дә сорамадык.

— Безнең кичкә кадәр вакыт бар. Мәскәүне күрәсегез киләме? — дип сорады абыебыз.

— И Абый, Абый. Мәскәү кайгысымыни... Өйгә кайтасы килә. Минем — Сеҗене, Рифкатьнең — Рәҗәпне, Рамилнең — Карадуганны, Гөлнәзирәнең — Курсаны, Рәшитнең — Сатышны, Миләүшәнең — Дәвешне, Фәритнең Чынлыны күрәсе килә. Син безне тизрәк Татарстаныбызга, Казаныбызга алып кайт. Аннары, күрмәгән Мәскәү түгел бит. Лагерьга барганда күрдек. Бөтен каланы әйләнеп чыктык.

— Ярый, балалар. Интегеп йөрмик алайса. Көне дә җайсыз. Бүген бит съезд ачылачак көн. Съезд!.. Кремль тирәсендәге юллар ябыктыр инде. — Абыебыз безнең «отказ»дан канәгать иде.

Мәскәүдәге Казан вокзалының бер почмагында кич җиткәнне көтеп утырабыз. Рифкать белән Мәскәүгә кайтканчы юл буе сөйләшеп кайттык, һаман да сөйләшеп туя алмыйбыз. Чиратлашып урамга да чыккалыйбыз, вокзал тирәләрен әйләнеп керәбез. Шул төштәге кибетләргә дә сугылып алабыз. Бөтен җирдә радио сөйли. Халык йотлыгып, дөньясын онытып, бөек Ленин эшен көне-төне армый-талмый дәвам иттерүче хөрмәтлебез, кадерлебез Леонид Ильичны тыңлый. Брежнев ашыкмый-кабаланмый, һәр сүзен сеңдереп, тәмле итеп сөйли. Ара-тирә авызын чапылдатып ала. Әфлисун ашыймыни. Күр әле син аны, нәкъ әби сөйләгәннәрне сөйли бит. Икесенең дә телендә бер сүз — план. План белән эшләргә, план белән яшәргә.

Брежневның сүзләренә караганда, совет кешесенең өстәлендә бөтенесе булырга тиеш. Тиеш тә бит, әбинең өстәлендә әфлисун бармы соң?!

Вокзал кайный. Халык, халык, халык... Кереп торалар, чыгып торалар. Үләм-бетәм, берсе сетка белән әфлисун күтәргән. Каян алды икән? Отыры әфлисунлы сеткалардан күз камаша башлады. Каян алалар соң, ә? Бәй, вокзал янында гына саталар икән. Урамда. Бая гына берни дә юк иде бит. Ни арада китергәннәр, ни арада бушатканнар, ни арада сата да башлаганнар.

Чиратка басам. Әбекәй исән-сау гына булсын. Үзенең әфлисун ашыйсы көннәре бар икән бит әле.

Чират шактый озын. Булсын. Басып торам. Минем алда ике кара-чутыр ир-ат тора. Көньяк кешеләренә охшаганнар. Артта ике әби быты-быты сөйләшә. Колакка чалынып киткән сүзләренә караганда, Мәскәүнең үзендә дә әфлисунны көн саен сатып тормыйлар икән. Бүген съезд хөрмәтенә генә чыгарганнар.

И рәхмәт инде сиңа, съезд!

И рәхмәт инде сиңа, партия!

И рәхмәт инде, Леонид Ильич!

Сәгать-сәгать ярым чамасы басып торганнан соң, аякка салкын үтә башлады. Әфлисун дигәндә түзәм инде. Тик менә әфлисуны гына бетеп бара түгелме?! Ачылмаган бер-ике әрҗә генә калды бит. Чираттагылар да сизә эшнең кая барганын. Арттагылар мине сулыш алып булмаслык итеп кыстылар. Бөтенебезнең күзе әфлисунда гына. Тагын ике әрҗә әфлисун калды. Алдымда җиде кеше. Миңа җитәргә тиеш.

Бер әрҗә калды.

Теге ике мужик аласы бар. Миңа каламы?

Калды пычагым. Комсыз каратут бу бәндәләр сатучы белән пышын-пышын сөйләштеләр дә әфлисунны әрҗәсе белән алдылар да куйдылар.

Тегеләргә ялварам:

— В деревне бабушка больная. Зинһар өчен, один апельсин. Пажалысты!..

Миңа кул гына селтәделәр. Икесе ике яктан әрҗәне күтәреп алдылар да китеп тә бардылар. Минем артта торган түтиләр дә гасабиланып сукранды. «Ну хоть мальчику дайте один апельсин», — дип кычкырды берсе. Алырсың эт авызыннан сөяк.

Шунда күзләремә яшь килде. Юк, әфлисун эләкмәүдән түгел, теге түтинең минем өчен әфлисун соравы, мине кызгануы күңелне йомшартты.

* * *

Үкенечле уйларга батып, тәмам мәэюслеккә төшеп вокзалда утырам. Күп тә үтмәде, микрофоннан безнең поездны игълан иттеләр. Чемоданнарыбызны күтәреп дәррәү перронга чыктык.

Менә безне туган якларыбызга алып кайтасы поезд. «Мәскәү — Свердловск» дип язылган. Килгәндә яшел поезд иде, кайтканда — кызыл.

Вагонга кердек. Урнаштык. Мәскәүнең авыр һавасы, вокзалның эчпошыргыч ыгы-зыгысы, җан биздергеч чират арыткан. Бераз ял итеп алу нияте белән башымны мендәргә төрткән идем, йоклап киткәнмен. Белмим, күпме йоклаганмындыр... чебен уятты. Уянуын уяндым, күземне генә ача алмыйм. Бигрәк әрсез-бәйләнчек чебен. Әле колакка куна, әле — борынга. Тукта әле, март аенда поездда чебен була димени. Тәгаен Рая Хәмидуллина инде бу. Бераз шаярып алмаса, бер-бер хикмәт уйлап чыгармаса, күңеле булмый аның.

— Рая, җитте сиңа. Рая, дим, ал кулыңны колактан! Хәзер кирәгеңне бирәм.

Ну үҗәт кыз. Колак белән борын арасында рәхәтләнеп сәфәр кыла. Хәзер күрмәгәнен күрсәтәм мин аңа. Чәчрәп торып, Раяның кулын җәт кенә эләктереп алдым да... Бәй!.. Өнемме бу, төшемме?.. Үз күзләремә үзем ышанмыйм.

Янымда...

Янымда... Урал кызы утыра.

Күтелмәгән бу бәхеттән эреп киттем.

— Әби авырый минем. Бик каты авырый. Син адресыңны бир әле. Адресыңны калдырасыңмы? Әби...

Ахмак беркатлылык бит инде бу. Әби турында нигә әйтеп торырга? Күңел нечкәрде шул, күңел. Адресны да хушлашканда алырга була бит. Арттан мылтык терәп тормыйлар. Җитмәсә, шулкадәр кызу сөйлим икән ки, пулеметтан атаммыни. Куркудан инде бу. Шушы кызны тагын югалтырмын дип куркудан. Аны азмы-күпме беләм бит. Истә-оста югында пәйда була ул. «Ә» дигәнче юкка чыга.

Урал кызы минем кирәгеннән артык хисләнеп китүемнән тыйнак кына елмаеп куя һәм сул кулымның аркасыннан сыпырып болай ди:

— Туктале, ашыкма син. Танышыйк башта. Син минем исемемне дә белмисең бит әле.

— Әйе шул. Исемең ничек, исемең?

— Ляля.

Фатих Кәримнең шигъри юллары искә төшә:

Исемең ничек? Ляля, диде ул,
Ә безнеңчә, Ләйлә инде ул.

Бактың исә, алар да шушы поездда икән. Бездән бер-ике вагон арттарак. Татарстан балаларының да шушы поезд белән кайтуларын ишеткән. Ишеткән дә...

Ләйләнең әнисе татар икән. Әтисе — урыс. Бу кызның елмаюлары ничек шулкадәр сөйкемле дисәм, әһә, аның хикмәте бар икән. Күр инде, әнисе татар диген, ә. Җан тартмаса, кан тарта, дигәннәре дөрестер.

Ләйлә Свердловскидан әллә ни ерак түгел бер поселокта яши икән. Туган ягының табигате искиткеч, ди. Урман, күлләр, тауларын сөйли. Мин үзебезнең Арчабыз белән мактанам һәм Ләйләне искәртеп куям: «Без Казанда төшеп калабыз. Син дәлше китәсең бит. Арчаны узгач, Курса булыр. Аннары — Шәмәрдән. Минем туган яклар инде ул. Безнең авыл Курсадан җиде чакрым гына. Тәрәзәдән карап кит. Күрми калма!»

Ләйлә күлдә ничек су коенуларын, беләк буе балык тотуларын сөйли. Мин Кесмәс чуртаннарын искә алам. Бездә ташбаш белән маймычтан башка балык юк дип мескенләнеп тормам бит инде.

Яз җиткәч, аларның күленә кыр үрдәкләре кайта икән. «Алар шундый матурлар, — ди Ләйлә, — кояшта яшел, зәңгәр, кучкыл, тагын әллә нинди төсләргә кереп балкыйлар. Үрдәкләр бәбкә чыгаргач, күл өсте кайнап тора, чуарлана, нәкъ синең битеңдәге сипкелләр шикелле». Кыз беравык миңа текәлеп карап торды да болай дип өстәп куйды: «Борының матур синең. Очы икегә аерылып тора. Үрдәк борынына охшаган».

Свердловскида булганым бар, дигәч, Ләйлә гаҗәпкә калды: «Шулаймыни?! Шәһәр ошадымы?» — ди. «Ошады, бик ошады», — дигән булам. Кая инде, без шәһәрне күрә алдыкмы. Чиләбегә, туганнарыбызга барганда, әни һәм бабай белән, поезд көтеп, вокзалда төн уздырдык. Свердловск йортсыз-җирсез сәрхушләре, аларны куып йөргән тупас милиционерлары, поездларга чыга торган бихисап туннельләре белән генә истә калган.

Ләйлә әбием турында да бик тәфсилләп сорашты. Кай җире авырта? Ничә яшьтә? Баярак әби турында сүз ычкындыруыма үкенгән булсам, хәзер тынычландым, хәтта сөенеп тә куйдым әле. Ник дисәгез, теге вакытта якташ вожатыйдан өмет иткән сүзләрне Ләйләдән ишеттем. «Әбиең сине сагынганга авырый. Син кайткач терелер. Менә күрерсең», — диде ул.

Ул кичне без вагонда ут сүнгәнче сөйләшеп утырдык. Иртән мин Ләйләне күрә алмаячакмын, чөнки Казанга әче таң белән кайтып төшәчәкбез. Аерылу бик кыен булды.

— Пока! Хуш, Ләйлә.

— Адресым кирәк түгелмени?

И Аллам, адрес истән дә чыккан. Тишек баш мин.

— Кирәк. Хәзер язып алам.

Чемоданымны ачып ручка эзләгән арада Ләйләдән җилләр искән. Ах, шайтан кыз! Адресыңны бирмичә качтыңмыни. Мин... сине! Мин... синеме? Мин сине хәзер үзем эзләп табам. Тәк, кайсы вагонда соң син?

Итекләремне киеп ятканда, Ләйлә тагын пәйда булмасынмы! Карыйм — кулында әфлисун.

Әфлисун!..

— Ал моны. Әбиеңә — күчтәнәч. — Ләйлә үзе дә шул әфлисун кебек балкый, яна иде.

Мин сүзсез, телсез калдым.

* * *

Казанда «Яшь ленинчы» аша безгә бик таныш булган (аның мәкаләләре сан саен диярлек чыга иде) Әнвәр Хуҗиәхмәтов каршы алды. Аның университетта укыганын белә идем. Бактың исә, эшләп тә йөри икән. «Яшь ленинчы» редакциясендә. Шәп егет! Ут егет!

Әнвәр абый безне Бауман урамына редакциягә алып кайтты. Кечкенә генә бүлмәгә барыбыз да сыйдык. Әнвәр абыйның өлгерлеген күр! Әле безне фотога төшерә. Әле блокнотын ачып нидер яза. Үзе бертуктаусыз сораштыра. «Яшь ленинчы»ның 5 май, Матбугат көненә багышлап чыгарылачак санына сезнең турыда бер полоса язма әзерлим. Укырсыз», — ди.

Без редакциягә кайтканда, бик иртә иде әле. Бүлмәләр бикле. Коридорда бер кеше дә юк. Отыры килә башладылар. Илгизәр апа, Саимә апа килде. Венера апа, Рәйсә апа, Фирая апа белән күрештек. Мин аларны күптәннән беләм. «Яшь ленинчы»га, балаларга мөкиббән журналистлар, киң күңелле, олы җанлы кешеләр. Их, редакция һавасын сулап, подшивкаларны актарып, газета тузанын эчеп бераз утыр идең ул. Юк, булмый. «Әби нихәл икән?» дигән сорау күңелне корт кебек кимерә. Безнең туганнар Болак буенда тора. Матбугат йортыннан биш минутлык юл. Әни дә хәзер шунда инде. Казанга 31ендә кайтып җитәчәгебезне язган идем. Безне «Татарстан» белән кайта дип беләләр бит инде. Ул поезд соңрак килә.

Ялына, ялвара торгач, мине җибәрделәр. Туганнарга кайтып җитүгә, шалтыратырга куштылар. Чабам, йөгерәм, очам. Атылып урамга чыктым. Чыгуым булды — кемдер арттан, якамнан эләктереп тә алды. Сизеп торам, кулы көрәк кадәр. «Казанның берәр шпанасы инде бу. Болай булгач, соңгы әфлисуннан да колак кагам икән» дигән уй мизгел эчендә баш миен сызып үтте. Борылып карасам, «Яшь ленинчы»ның фән, техника һәм спорт бүлеге журналисты Нургали абый Булатов икән. Ул хәл-әхвәл сорашты, аннары мине юл аша чыгарып куйды.

Туганнарга килеп кергәндә, әни һәм аның абыйсының хатыны Кадрия апа нәкъ менә вокзалга төшәргә җыенып йөриләр иде.

* * *

Казанда да, авылга кайтканда да әнидән әби турында берни дә сорашмадым. Дөресрәге, сорарга курыктым. «Әбиең юк бит инде, улым», — дисә, нихәл итәрсең. Юк, тегеләй-болай булган тәкъдирдә дә минем өчен әлегә ул исән-сау. Ул яши, яшәсен. Ул яшәргә тиеш!.. Яшәргә!

Ләкин күпме түзәргә була йөрәкне өзгәләп, җанны телгәләп торган мондый билгесезлеккә?! «Әби нихәл?» — дип турыдан-туры сорарга куркам.

— Әни, чемоданда әбигә әфлисун бар, — дип кенә әйтеп куям.

— И улым! Әбиең ашый алмас инде ул әфлисуныңны.

— Ник? Әби начармыни?

— Әйе шул, улым.

Күзләремнән яшь бәреп чыга. Аларны әнигә күрсәтмәс өчен вагон тәрәзәсеннән тышка карыйм. Каерылып-каерылып карыйм. Арчаны үттек. Шуны искәрдем: бу яктагы урман-кырлар Казаннан Арчага кадәрге табигать белән чагыштырганда сафрак, чистарак, аграк.

Әнә ике каен. Берсе — карт, берсе — бала каен. Бала каен карт каенга елышкан.

Стансада эти каршы алды. Атның иң кәттәсен — Курганны җигеп менгән. Сугышта булган, диләр ул атны. Яу ялкынын ялында яндырган. Фронтка товарнякта барган. Шунда куркып калган. Уттан курыкмый, поездан курка. Бүген дә өч вагонлы дизель поезды теләр-теләмәс кенә шуа башлаганда малкай тыныч иде әле. Кузгалып киткәндә кар тузаны туздырып, дөбер-шатыр килгән товарняктан өркеп хут алды бугай, Курган өзелеп-ургылып чапты.

Һи-и-и, монда һаман кыш икән әле. Тегендә агачлар яфрак ярды бит инде. Менә хикмәти Хода, моннан өч көн генә элек Кара диңгез хозурында идем. Ә бүген кар диңгезендә. Курган чаба гына. Чананың табаны юл катысына әллә тия, әллә юк. Ләкин минем янган йөрәккә, ашкынган күңелгә бу тизлек тә җитми. Канатлы ат булсын иде ул. Очсын иде ул.

Ниһаять, авыл. Багана башындагы лампочкадан төшкән яктыда койма буйларындагы кар көртләреннән нурлар чәчри. Курганның капка төбенә килеп туктавы булды, мин очкан ук кебек өйгә атылдым.

Керсәм — әби юк.

Үзе дә юк, караваты да.

Шул мизгелдә апам Ләйләнең «Әби, Вакыйф кайтты!» дигән сүзләрен ишетмәсәм, белмим, нишләр идем.

Бактың исә, җылырак булсын дип, әбине караваты-ние белән мич янына күчергәннәр икән. Ишек төбеннән күренми.

— Исәнме, әби!

— Улым. Һай, улым. Исән-сау йөреп кайттыңмы? Аллага шөкер, сине күрәсе көннәрем дә бар икән. — Әби, урыныннан торып, күрешергә кулларын сузды.

Шатлыгымның иге-чиге юк. Әбием исән-сау. Әмма бик бетерешкән, суырылган. Тавышы да зәгыйфь.

— Мин сиңа әфлисун апкайттым. Урал кызы Ләйлә бирде. — Чемоданымны ашыга-каударлана ачам һәм күчтәнәчне алып әбигә сузам.

— Рәхмәт, улым.

— Аша, әби, аша.

— Салкын бит әле бу, улым. Җылынсын бераз.

Әбине тизрәк сыйлыйсым килә. Апай без кайтыр алдыннан гына томалаган мичкә әфлисунны тыгып куйдык. Биш минутта җылыначак.

Ул арада эти белән әни дә кереп җиттеләр.

— Һай әнкәй, сине торгыздылармыни? Өзлегә күрмә тагын, — диде әни.

Бактың исә, соңгы вакытта әбинең мендәрдән башын күтәрерлек тә хәле булмаган. Гел яткан да яткан. Бүген аның үзе торып утыруына өйдәгеләр гаҗәпкә калды.

Утырып дога кылдык. Аннары эти ат тугарырга китте. Әбинең дә, әнинең дә, апайның да күзләре миндә генә. Йә, сөйлә! Ничек йөреп кайттың? Кайларда булдың,ниләр күрдең? И-и-и... Сөйләп кенә бетерерлекме соң? Китте сүз, китте сүз, китте сүз...

Җиде яшәр юлдан кайтса, җитмеш яшәр күрешә килер, ди. Минем кайту хәбәрен ишетеп, түбән очтан Сәлим абый да менеп җитте. Аның да теленә шайтан төкергән.

Гөр киләбез, шау итәбез.

Сүзгә мавыгып, вакытның үткәнен дә сизмәгәнбез. Төн уртасы җиткән бит инде.

Их, оныттык бит.

Оныттык! И-и-и Алла!

Мичкә әфлисун куйган идек бит. Янып-көеп беткәндер инде ул. Булмады. Шул бер әфлисунны да әбинең кулына тоттырып булмады.

Мич капкачын җәлт кенә ачабыз. Күчтәнәчне кисәү таягы белән җәлт кенә тартып алабыз. Ыгы-зыгы киләбез.

Әфлисун димәсәң, хәтере калыр. Кабыгы көйгән. Әле аны кулны пешерә-пешерә бүлгәләгән булабыз. Кисәкләреннән пар күтәрелә. Нәрсә инде бу? Шушы да булдымы әфлисун?! Харап иттек күчтәнәчне.

Сәлим абыйны озатып, ятарга җыенып йөргәндә карасам, әби өрә-өрә әфлисун ашап утыра. Шул көйгән әфлисунны.

— Ташласана, әби. Пычранма. Мичтә пешкән әфлисунны кем ашый инде?!

— И улым. Миңа бакчада пешкәне кирәкми. Нәкъ менә мичтә пешкән әфлисунда нәфсем бар иде. Ай-яй тәмле. Көлдә пешкән бәрәңге кебек. Ничек алып кайта белдең?!

Мине юатыр өчен генә әйткән сүзләрдер инде бу, дисәм, юк, әби чын-чынлап йотлыгып, мәмнүн булып ашый. Минем күчтәнәчне бәрәңге белән чагыштыруына бераз хәтерем калды калуын. Бәрәңге бездә өясты тутырык лабаса.

Әфлисунны әбигә әни биргән. «Хәерлегә булсын инде, — диде ул, — үзе сорап алды. Биш көн инде бер тәгам ризык капканы юк».

Әфлисун мичтә көйсә дә, кулым җиңел булды. Әби берни дә ашамагач, җыясы ризыгы бетте микәнни, дип, өйдәгеләр дә куркуга төшкән булган. Юк, бетмәгән әле, бетмәгән. Иртәгесен мичкә бәрәңге тәгәрәттерде.

Белмим, әллә «мичтә пешкән» әфлисунның шифасы тиде, әллә минем исән-имин әйләнеп кайтуым үзе дәва булды, күз тимәсен, әби тернәкләнә башлады, йөзенә төс керде. Уйлап-уйлап торам да уелыплар китәм, Урал кызы Ләйләнең «Син кайткач, әбиең терелер» дигән сүзләре тәки дөрескә чыкты бит. Күрәзәчедер син, валлаһи, серле, горур, мәхәббәтле Урал кызы. Әфлисуның өчен тагын бер кат рәхмәт сиңа, Ләйлә.

* * *

Яз язлыгын итә. Монда да кинәт җылытып җибәрде. Моңарчы нык кына тартышкан үҗәт кыш тәртәне китү ягына борды. Ике-өч көндә өй каршындагы тау түбәсендә парлы җир чыкты. Кояшы да нәкъ көньяк кояшы кебек, җылы, юмарт, мамыклы.

— И улым, — ди әби, тәрәзәдән тышка карап, — җылы яктан безгә дә җылы алып кайттың бит, Ходайның рәхмәте. Яз алып кайттың. Кояш алып кайттың.

Әбинең бу сүзләренә күңелем булып, үзем дә урамга карыйм. Әби белән икебез — бер тәрәзәдә. Икебез дә кояшка күз кысабыз.

Әй, Кояш!

Күр әле, мин әбигә сине дә алып кайтканмын бит, галиҗәнап Кояш. Әфлисуннарны да гел сиңа охшаттым мин. Тик сиңа беркем дә тия алмас. Сине беркем дә урлый алмас.

Безнең күзләр һаман тышта. Тәрәзә яныннан китә алмыйбыз. Күңелне кояшлары белән ымсындырып, ярсулы ашкыну белән тутырып, өмет учаклары белән балкытып, туган ягыма яз килеп ята.

* * *

Әби безнең белән тагын бер җәй җәйләде, тагын бер кыш кышлады. Хәер, кышны чыгарга өлгерә алмады. Гыйнварның егерме сигезендә ул бакыйга күчте. Без бу юлы да терелер, аякка басар дип өметләнгән идек. Юк, әби үлем түшәгенә яткан булып чыкты. Язларны ул бүтән каршы алалмады. Шунысы гаҗәп: гомер буена план белән яшәгән әби үлемен дә үзенчә планлаштырган булып чыкты. Вафатына бер атна кала, ул гел бер ягында гына ятты. Без кузгатмакчы булабыз. Ул тияргә кушмый. Бактың исә, җан биргәндә, үзенең кыйблага карап ятуын теләгән икән.

Иртәнге сәгать дүртләр тирәсе. Әти, әни, әбинең кызы Сәкинә апа, апай, мин — барыбыз да аягөстендә. Әни күршедәге Гыйззенисә әбине ясин чыгарга алып керде. Гыйззенисәттә укырга ашыкмады. Байтак вакыт әбигә карап тын гына утырды. Берзаман укый башлады. Бәгырьдән чыккан моңлы-аһәңле тавыш безнең җаннар, безнең күңелләр аша да тибрәлә-тибрәлә үтте. Гыйззенисәттә укый. Ара-тирә каз каурыен касәдәге саф чишмә суына манчып, әбинең иреннәренә тидереп ала. Әбинең иреннәре ялтырап-ялтырап китә. Гыйззенисәттә укуыннан туктады. Мәкам белән яңгыраган тавыш, «җыр» тынды. Ул «бисмилла» әйтте дә сары җирлеккә зәңгәр чәчәкләр төшерелгән өр-яңа яулык белән әбинең битен каплап куйды.

«Мине өйдән өзелгән көнне үк чыгарсагыз иде». — Гомеренең соңгы елларында әби бу сүзләрне гел тәкрарлап торды. Аның бу «планы» да гамәлгә ашты. Әби җомга көнне иртәнге алтынчы яртыда өзелде. Сәгать унбердә, җомгага кадәр гүргә иңдерелде.

Авыр туфрагың җиңел булсын, әбекәй.

Бу юлы да, әби авырып киткәч, кемдер әфлисун алып килгән иде. Әбигә биреп карадык, башын гына селкеде. «Юк, нәфсем юк, — диде ул, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп, — былтыр син алып кайткан әфлисун — ул минем соңгы әфлисуным иде, улым».

Аның бу сүзләрен Ләйләгә дә язасы булыр. Урал кызы белән хат алышуыбызны сезгә әйтеп тормам дигән идем инде. Серне ялгыш кына чишеп аттым бит.

## Карга карагы

### Хәтәр

Тимерхан төрмәдән качкан...

Май аеның тымызык кичендә сыерын савып, сарыкларын, каз-үрдәген ябып, бер кат эшен бетергәч, капка төбенә ял итәргә, ләчтит сатарга чыккан күрше-күлән бер-берсенә тиз ирештерде бу хәбәрне. Җинаятьчеләр турындагы китапларны су урынына эчеп, үскәч тикшерүче, юрист, һичьюгы милиционер булам дип хыялга чумган-җенләнгән Булатны авыл халкы колагы ияләшмәгән бу ят хәбәр эскәмиянең кырыена чүмәшеп кеше сөйләгәнне сеңдереп утырырга мәҗбүр итте.

Тимерхан шушы авылда — Өтермәстә туып үсте. Әтисе шәп мичче иде. Утызы да тулыр-тулмас борын машинага тапталып үлде. Малай әнисе белән генә калды. Әнисе гомер буена колхозда сыер сауды. Тимерхан тугызынчыда укыганда әнисе дә авырып китеп үлем түшәгенә яткан булып чыкты. Тимерхан япа-ялгыз калды. Тәвәккәл, йөрәкле егет булып чыкты тагын үзе. Чиләбе ягында яшәүче әнисенең бертуган сеңлесе алып китәм дип кайткан иде. Тимерхан китмәде. Балалар йортыннан да баш тартты. Шулай итеп, нигездә учакны сүндермәде, хуҗалыкны таркатмады. Бер-ике баш сарыгы бар иде — аларны да бетермәде. Ялгыз башы яшәп үз көнен үзе күрде ул. Җәен кеше өчен көтү чиратына чыкты. Кышын колхоз атларын карады. Дәресен дә калдырмаска тырышты. Аның иншаларын мактыйлар иде. Үз сүзе, үз фикере бар, дип әйтәләр иде. Кулы да эшкә ята иде. Бер дигән балта остасы. Эт оясын да чәчәкләп-чуклап ясап бирә иде. Сабантуйда көрәшкә керсәме?! Мәйдан кысыла, йөрәкләр кысыла. Мәктәпне тәмамлыйсы елны ук батыр калды бит. Район сабан туенда да 70 килога чаклы көрәшчеләрнең аңа чыкканы булмады. Каян килгән сәләттер, җиңел-матур көрәшә. Үзе дә әллә ни ватылмый, көндәшен дә азапламый. Ул көрәшкәндә, дөнья күргән абзыйлар баш чайкап куя. Тамагын

кайгыртучы булып, тәрбиядә торса, ничек көрәшер иде икән ул?! Кайда туры килсә, шунда капкалап йөреп тә ни хикмәт селти. Хәтәр! Хәтәр дигәннән шушы сүз Тимерханга сабантуйдан кушамат булып ябышып калды. Авыл сабан туемы ул, районныкымы, мәйданга килгән халыкның телендә бер сүз: «Хәтәр көрәшер микән?»

Солдат хезмәтеннән соң туры туган авылына кайтты ул. Исәбе авылда калу, өйләнеп, балалар үстерү иде. Тик күреп тора бит: колхозның рәте юк, атларны бетергәннәр, ферманы бетергәннәр. Бераз акча эшләп кайту нияте белән Тимерхан китеп барды. Аны, Мәскәү тирәсенә барып урнашкан, диделәр. Егетнең бер-ике ел хәбәр-хәтере булмады. «Кеше үтереп өтермәгә эләккән икән» дигән сүз авылдашларына аяз көнне яшен суккан кук булды. Нинди дөнья бу?! Адәмнәр адәм ышанмаслык эшләр эшләп ташлый.

...Капка төбе утырышлары гадәттә бер сценарий буенча бара. Көтү бүген урманга кергәнме? Сыерлар тук кайтканмы? Кыяк Кыямның сыеры көтүдән тагын качканмы? Болары утырышның төп сораулары. Аннары кәллә-мәллә сүз китә. Кем мунча яккан, кем коймак пешергән, кемнеңдер кишере тишелгән, кемнеңдер шалканы тишелмәгән. Кемдер балта саплаган, кемдер чалгысын печән өстенә таптап куйган. Ә менә Корыкукыр Кирам өендәге пычакларын һаман да кайрамаган. Хатыны зарлана. Сүз арты сүз. Телләренә шайтан төкергән. Монда сөйләшкәннәр чүп булып җирдә аунап калса, капка төбен себереп бетереп булмас иде.

Ә бүген пычагымамы ул Корыкукыр пычагы. Тимерхан өтермәдән качкан әнә! Ничек кача алган? Кая качкан?

— Кая качсын?! Өтермәдән Өтермәскә кайтыр инде ул. Менәтерә вәйт. Авылга. — Гыйзелбанат әбинең тешсез авызыннан сытылмыйча гына чыгып очты бу сүзләр.

Кирам чәчрәп торды:

— Монда кайтырга башына тай типмәгән ич аның. Өтермәскә кайтса, елан авызына үзе эләккән бака кебек кабачак ул. Погонлылар әнә тыз да быз йөреп тора. Арзамастан көтүләре белән килеп төшкәннәр әнә. Өен куна-төнә саклап яталар. Төнәгеен Наилгә, участковыйга да кереп чыктылар. Кайтмый ул монда. Государственно уйлагыз сез.

— Һе-һе... Белмим шул. — Банат әби шадра ияген яратып кына сыпырып куйды.

— Юк инде, юк, кайтмый ул монда. — Колга буе Корыкукыр тагын аягүрә басып сөйли башлады: — Менә әйткәние дип әйтерсез әле. Аңа йә далага, йә тайгага таярга! Анда этем дә күрмәячәк.

— Һе-һе... Туган як менәтерә вәйт...

— Мондагы күперләре янган инде аның, әби.

Ул көнне Кирам Тимерханның монда кайтмаячагын байтак кешегә кызып-кызып исбатлады. Аның белән берәү дә бәхәскә кермәде, Банат әби дә бүтән дәшмәде, чөнки Корыкукырның бер сүзне элеп алса өзми-куймый туктаусыз чәйнәвен беләләр иде.

Чатта Ансар күренде. Кичкә таба кая бара? Амбарынадыр инде. Эшенә. Хәер, эш димәсәң, хәтере калыр. Амбарын бер ача, бер яба. Эше булмаса да, фасунын китерә. Өй белән амбар арасын кырыкмаса-кырык тапкыр узадыр. Ялгыз башы өйдә нишләп ятсын инде ул буйдак. Бер-ике тавыгын исәпкә алмаганда, кош-корт, мал-туар асрамый. Ансар — битенә ыштыр каплаган йомык кеше. Берәүгә дә ачылып китми. Сөйләшкәндә аягындагы ертык кәвешенең очына карап сөйләшә. Кайчагында үзе сиңа эндәшә, кабагыннан зыкы коелып торган салкын күзләре исә сиңа түгел, янәшәңдә басып торган кешегә карый. Өтермәскә юлыгыз төшеп, култык астына иске халат кыстырган кеше очратсагыз — ул Ансар булыр. Кая барса да халатын калдырмый ул. Кемдә — нәрсә? Көтүчедә — чыбыркы, сантехникта — торба ачкычы, Жванецкийда — иске портфель, Ансарда — иске халат. Ул аны кими. Култык астына гына кыстырып йөртә.

Башка вакытта күзенең агы белән генә карап, ияген сизелер-сизелмәс кенә селкетеп, йөз сытып уза торган Ансар да, хикмәти Хода, күрше-күлән түгәрәкләнгән эскәмия янында туктады. Хәлбуки сүзнең Тимерхан турында баруын ишетеп туктады.

— Ул ристан монда кайтса, кешенең тавык-чебешен тагын кымтырыклый башлаячак икән... — Ансар бу сүзләрне эскәмиядән читтәрәк бүкәнгә утырган Булатның аяк астына карап әйтте. Әйтте дә, култык астындагы халатын капшый-капшый, үз юлы белән китеп барды.

Ансар Тимерханнан бер йорт аша гына тора. Ике арада — Гыйзелбанат әбинең туганнан туганы Мәсрүрә карчык. Ире сугыштан кайтмаган. Кортка ялгызы яши. Шул карчыкның бер-бер артлы ике тавыгы югалды бит бер елны. Күрше-күлән Тимерханнан шикләнде. Тавык тавык инде — актармаган җире, кермәгән тишеге юк. Тимерханга да кергәннәрдер. Ул очламады микән? Ялгыз башы нәрсә ашап торсын. «Шул гына, шул гына җитте тавыкларыңның башына», — дип, күрше әбигә койма аша пышылдады Ансар.

Күңелгә шик бер кердеме, корт кебек кимереп тора инде ул. Барыбер Тимерханга сылап калдырдылар ул тавыкларны. Үзенә турыдан-туры ярып әйтүче булмаса да — күргән яки кулыннан тоткан кеше юк бит — егетнең йөрәге бу шикләнүләрне сизмәде дисезме?! Хәер, әйтүчеләре дә булды бугай. Тик Тимерхан акланып йөрмәде. Димәк, гаепле.

Амбар янында машина тавышы ишетелде. Урамның буеннан-буена сузылган тузан-койрык тагып, «КамАЗ» үтеп китте. Күршеләр шоферны танымадылар. Янәшә утырганы участковый Наил иде. Сыер җилененә сөртә торган май, яңа сауган җылы сөт исе кытыклап торган борын яфракларын газлы төтен, солярка исе кисеп үтте. Башка вакытта гел Наил абыйсы янында чуалырга яраткан Булат бүген түзеп торамы соң инде?! Бүкәннән җәлт кенә сикереп торды да тузан болытына кереп чумды. Тимерхан абыйсы турындагы шомлы хәбәрне участковыйның үз авызыннан ишетәсе килә иде аның.

Булат килеп җиткәндә, Наил абыйсы машинадан төшеп өс-башын каккалап тора иде. Участковый: «Төрмәдән качкан кешедә синең ни эшең бар?» — дип авызны томаласа...

Малай сүзне читтән башлады:

— Берәр җиргә барган идең мәллә, Наил абый?

— Барган идем шул.

Җавап бирелде. Пауза. Икенче сорау әзер түгел. Сүзне ничек ялгап китәргә? Булатның тел очы тирләп чыкты. Аптырагач, теш арасыннан көйгә охшаш авазлар да сытып чыгарып карады. Хет Наил абыйсы үзе эндәшсен иде. Юк, кагынуын белә. Ниһаять, бер сорау туды:

— Наил абый, кичә сезгә милиционерлар килгән иде мәллә? — Монысы инде төрмәдән качу вакыйгасына якынрак иде.

— Килгән иде шул...

Тагын пауза. Хәзер Булат: «Нишләп йөриләр?» — дип сорарга тиеш иде. Кыймады. Текәрәк алдыруына үкенде. Чигенмичә булмый. Ничек кенә Наил абыйсының теленә ачкыч табарга?

— Энекәш! — Участковыйның үзенә эндәшүен ишеткәч, Булат дәресенә әзерләнмичә килеп тә, «2»ледән котылган кебек җиңел сулап куйды. — Менә чалгы алдым әле. Шәпме? Һәйбәтләп таптап, янавыч белән сызып җибәрсәңме, Гали пәкесе кебек була ул. Печән өстендә табып булмый аны. Печән дигәннән, син быел чүмәләгезне урлатма инде, яме.

Их, участковый, малайның тез астына типтең бит. Ул чүмәлә өчен үзенең дә йөрәге парчаланганын беләсең бит. Урманда һәркемнең үз аланы, үз чабынлыгы. Булатларныкы да бар. Авылдан ерак. Урманга кергәч тә хәтсез барасы. Ул көнне Булат белән әнисе печәнне киптереп җыйдылар. Ике чүмәлә очладылар. Булат һәм күршесе Кирам абыйсы — чабынлыклары да янәшә — печән саклап урманда төн кунарга булдылар. Кичерәк кенә шалаш әтмәлләделәр. Аяк астына кипкән печән түшәделәр. Шалаш эчендә җиләк исе, ылыс исе, миллек исе. Тагын ни кирәк? Көн сүрелеп, шалаш эченә серле караңгылык иңә башлагач, уңлы-суллы селтәнергә тотындылар. Әмма теңкәгә тигән камалыштан чыгам димә. Бәйләнчек озынборыннар гаскәрен җиңә торган түгел иде. Корыкукыр да, Булат та өйне сагына башладылар. Күз алларында бөтнек исе чыгып торган эссе мунча, җиләк салган сөтле чәй, кабартып куелган йомшак мендәр... Дөнья рәхәте.

— Тайдык өйгә. — Корыкукыр икеле-микеле уйларга хут калдырмыйча әзерләнә башлады. — Кемгә хаҗәт безнең печән?..

Булат ризалашты.

Шул көнне печән саклаучылар каз мамыгы тутырылган йомшак түшәктә эреп-изрәп йоклап ятканда, Булатларның бер чүмәләсен «утыртып» киткәннәр иде.

Караклар печәнне юлга ташып төягәннәр. Аланда тәгәрмәч эзе юк. Юлдан исә көненә дистәләрчә машина уза. Эзләп кара каракны! Табарсың кибәннән энә. Булат урманда төн

кунмыйча кайтып китүенә үкенде. Тагын да үкенечлерәге — милиционер булу турында күңелендә бөреләнгән балачак хыялын Наил абыйсына тишкән иде. «Их син!..» — диде Кирам белән Булатның төн уртасында авылга кайтып китүләрен һәм бер чүмәләдән колак кагуларын ишеткән участковый. Тел төбендә «Бер чүмәлә печәнне саклый алмагансың, кешеләрнең иминлеген ничек сакларсың?» дигән төрттерү ятканлыгы аңлашыла иде.

Участковый Булатның авырткан җиренә кагылуын үзе дә сизде, ахры, чүмәлә турында бүтән сүз куертмады.

— Ярый, энекәш, кереп ял ит. Иртәгә дә яшисе бар, — диде ул һәм малайның җилкәсенә авыр кулын салды.

Булат кайтканда, кичке эңгер-меңгер куерып, караңгы төшә башлаган, капка төбе таралган иде. Отыры авыл ут алып тормыйча гына төннең каракучкыл пәрдәсе астына качты.

Шомлы җил исеп куйды...

**Келәттә кемдер бар**

Корыкукырның сүзе дөрескә чыкты, ахры, Тимерханның кайтмавы булды бугай. Һәрхәлдә, Амбар-Ансар дөрес сукаламый микән. Мәсрүрәттәнең теге ике тавыгы, чыннан да, Тимерхан кулы булырга мөмкин. Ул киткәч, кош-кортка тиюче кеше юк бит.

Әйе, Тимерхан күренмәде. Капка төбе утырышлары яңадан үз темасына күчте. Кыякның сыеры көн саен качты. Корыкукыр, мин фәлән итәм, мин төгән итәм, дип күкрәк сукты. Үзенең пычак кайрарга һаман да кулы җитмәде. Амбар-Ансарның халаты култык астыннан чыкмады. Авыл шулай яшәде.

Яши иде...

Беркөнне кинәт кенә исеп куйган чәнечкеле җил белән тагын бер хәбәр сибелде.

Тимерханны күргәннәр!..

Колхозның бәрәңге базында качып ята, имеш. Кайсыдыр авылда ялгыз яшәп яткан бер карчыкның котын алганнар, төн уртасында бик каты капкасын какканнар. Имеш, зиратта яши Тимерхан. Зират дигәннән, анда чи такталардан ясалган бер табут бар иде. Чыгышы белән Өтермәснеке булган бер бабайны малайлары Казаннан алып кайттылар ул табутта. Бабай кайтты. Ята табутта. Монда исә мөселманча бөтен шартын китереп, ләхет алып, сәндерә ясап казып куйганнар иде каберне. Ходайның рәхмәте, авыл халкының бабайны «ящигыннан» алып кәфенләп күмәргә башы җитте. Беркөнне көтүчеләр зират кырыендагы карт каенга сөяп куелган шул адашкан табутның җирдә аунап ятуын искәргәннәр. Яңгырлы төндә Тимерхан кереп ятмады микән дип шикләнгәннәр.

Булат келәттә йоклый. Берүзе. Рәхәт анда. Көн буена миеңне кайнатырлык эсседә чабып йөреп арган-талчыккан гәүдәсен тычканнар пес итеп дым тарттырган салкынча түшәккә сузып салуы була — эреп йоклап китә. Бүген дә башын мендәргә төртүгә тәненең талгын бер рәхәтлектә оюын тойды. Тик күзенә йокы кермәде. Хәтәр турындагы уйлар керфекләрен терәүләп торамыни. Менә-менә Тимерхан келәтнең ишеген шакыр кебек:

— Ач! Мине яшер!

Алла сакласын! Булат ми күзәнәкләрен богаулап алган уйларыннан арынырга теләп күзләрен йомды. Юрганын маңгаена кадәр тартып менгерде. Бер карасаң, Тимерхан-ристанның Булаттан җиде төн уртасында җиде ишекне ачтырырга хакы бар.

...Ул елны яз сүрән генә торды-торды да көннәрдән бер көнне холкын күрсәтә башлады. Кайнады, ярсыды. Булат 4—5 яшьләр тирәсендә булгандыр. Борын асты белән бишмәтенең изүләре, күкрәк турысы ялтырап торган малай бер көйгә генә агып яткан тыйнак гөрләвекләрнең су ташкынына әверелүен, уенга мавыгып, искәреп өлгермәде, урамның теге ягында калды. Ничек чыгарга? Өйгә ничек кайтырга? Бердәнбер юл — авыл башыннан әйләнеп, ындыр артлатып кайту. Анда ташу болай ук дәһшәтле түгелдер. Сабый башына шундый юләр уй килеп торуын күр әле. Булат тәвәккәлләп китте. Авыл башын үтте. Басуга керә башлады. Кыр түрендәге

кучкылланып торган йөзьяшәр имәнлектән ташып чыккан караңгылык ни арада бөтен җиһанны ялмап алды. Күзгә төртсәң күренмәслек булып өскә ишелде. Җитмәсә, итеккә балчык сыланып интектерә. Уф! Аякны күтәреп тә булмый инде менә. Булат, асфальт өстенә җәелгән сумалага ябышкан чыпчык кебек, уңга-сулга талпынып карады. Мәмрәп торган басуның үзле балчыгы аны кузгала алмаслык итеп каптырган иде. Малай еларга да, еламаска да белмәде. Бар көченә тагын тартылды. Итектән генә түгел, йон оекбаштан да шуып чыккан ялан тәпи белән җиргә басты. Бозлы пычрак салкыны табан астын куырып алды. Шул мәлдә икенче аягының да тез тиңентен балчык боламыгына кереп чумганын искәрде. Туңган тәпиен авызына кабарлык булган Булат яланаяк кая басарга да белмәде. Җир йолкып алып калган сыңар итеген кимәкче булып азапланды. Әмма үзле-үзсүзле балчык икенче аякны да бирмәде. Малай артына утырды. Көч-хәл белән тагын торып басты. Җир-саз аны һаман үзенә суыра иде. Отыры ул аны йотачак. Булатның хәле бетте, тыны кысылды. Зар иңрәп кычкыра башлады:

— Үлә-ә-ә-әм! Әни-и-и!

Тавышы зәгыйфь иде. Тагын кычкырып карады. Капкынга эләккән күсе кебек як-ягына каранды. Беравык тын калып басуны тыңлады. Тик төн хакимлек иткән япан кырда гөрләвекләр шавыннан башка аваз ишетелмәде. Аягын селкеткән саен, өметсезлек билгесе йөрәген кимерә, тән калтырый, тешләр тешкә орынмый. Тирә-якта — караңгы кыр, тирә-якта — гамьсез төн. Башта — уйлар: «Мин бетәм. Минем гәүдәмне дә таба алмаячаклар. Тапсалар да, бүреләр, кыргый этләр ботарлаган сөякләремне генә җыеп алачаклар».

— Әни! Әни-и-ем! Үлә-ә-әм!

Кычкырган саен, гөрләвекләр шавы көчлерәк ишетелә, гүя газаплы-интегүле ялвару сүзләре кар сулары белән бергә юылып агып китә тора.

Булат шул мәлдә авыл башында ниндидер кучкыл шәүләнең хәрәкәтләнүен шәйләп алды. Гүя караңгы, котсыз кара пәрдә каплаган өметнең бер читендә якты тузан бөртеге пәйда булды. Тик мизгел эчендә шәүлә юкка чыкты.

— Үлә-ә-ә-ә-м! — Бар көченә азапланып, тилмереп кычкырган Булатның тавышы бу юлы шактый көр чыкты.

Тукта әле, бу кара-кучкыл нәмәрсә, серле шәүлә, ферма-әвенлек тирәсенә килгән бүре-мазар, эт-кош булып чыкса. Булатның тез буыннары туңудан да, куркудан да калтырый.

Шәүлә тагын кыймылдап куйды. Тагын эреде.

Булат өмет белән баккан мөлдерәмә күзләрен ферма ягыннан ала алмады. Әнә ул төн эченнән килеп чыкты. Кеше! Кешенең үзе!

— Әй, кем, нигә кычкырасың?

Булат Тимерхан абыйсын тавышыннан таныды. Малайның эченә азмы-күпме җылы йөгергән кебек булды. Хәл-җегәре соңгы чиккә җиткән булса да, сыекланганнан-сыеклана барган рәхимсез балчык боткасыннан чыгарга тагын бер кат омтылып карады.

— Эһ-эһ-эһ...

«Эһ-эһ»ләрне Тимерхан абыйсына ишетелерлек итеп тамак төбе белән әйтергә тырышты. Бот буе гына малай булса да, пычрак диңгезенә баттым дип, юеш балчык кебек җебеп төшмәгән, һаман тартыша-тырмаша, имеш.

— Булат, син түгелме соң? Нишлисең анда?

— Әй, әзрәк пысракка баткан идем лә...

— Син, Идел кичәсе егет, пычракка батып тормасаң... Бир кулыңны!..

Шул мәлдә Тимерхан абыйсы үзе дә җир «авызына» кереп баруын сизеп, аякларын җәт-җәт тартып алды. Пычрак кына дигәч тә, уен-муен түгел икән. Күр ничек суыра!

Тимерхан юлга чыкты да, аягын селкеп, итекләрендәге балчыкны төшерде һәм җир өстенә тагын кереп китте. Басуның киребеткән балчыгы аны тагын «биетте». Малайны йолкып алды алуын, тик итекләре калды. Тимерхан Булатны култык астына кыстырды да җир йоткан бәләкәй бутыйларны сул кулын бозлы балчыкка тыгып эзләде. Үзе дә батмас өчен бөтен авырлыгын уч төбенә җыеп эзләде. Берсен тиз тапты. Икенчесен эзләгәндә шактый тирләргә туры килде. Үзе дә пычранып бетте.

Кичтән канюшнига кайтмаган бер тайны эзләргә чыккан егет сыек балчыкка буялмыйча ике күзе генә калган малайны өенә кайтарып куйды. Кич буена авыл бетереп газиз баласын эзли-эзли акылдан шашардай булган, язгы ташуга агып киткәндер дигән җан өшеткеч уйлардан ярты чәче агарган бичара ана нарасые табылу шатлыгыннан Тимерханга рәхмәт әйтергә дә онытты.

...Булат әйләнеп ятты. Караваты киң. Түшәге йомшак. Тимерхан абыйсы гына кайларда йөри икән? Иртән аның өстенә юрган ябучы да, сыер саугач җылы сөт эчерүче дә юктыр.

Бакчадагы агач-куакларны борчып җил исте. Кемдер тыштан келәт ишеген тартып куйгандай булды. Лар астында баядан бирле кетер-кетер нидер кимергән тычкан да тынып калды. Сабырсыз җил, бер ягына таш кыстырылмыйча калган келәтнең идән астына тузандыр, чүптер тутырып, тагын исеп куйды.

...Авыл киче. Капка төбе. Шул ук эскәмия. Шул ук күршеләр. Шул ук сүз. Тимерханны тагын күргәннәр. Кирәмәт тавында. Кирәмәт тавы исә Булатларның бакча башында гына. Хәтәр ызан буйлап үрмәләп менәр дә килеп тә керер әле менә.

Көн кинәт бозылды. Алсуланып торган шәфәкъ кучкылланды. Отыры күк йөзен күңелне, җанны сытарлык авыр болытлар каплап алды. Бермәлне Булатларның иске капкасы шалт итеп ачылып китте. Ишегалдыннан чыккан бәйләнчек дымлы җил урамның каршы ягында үсеп утырган каен, юкәләргә ябышты. Күрше-күлән таралышты. Булат та капканы бикләп келәт янына килде. Беравык тын калып, уйланып торды. «Димәк, Хәтәр шушы тирәдә генә. Бәлки, ул бу мәлдә бакчага ук кергәндер. Ызан буйлап шуыша торгандыр. Бәлки, келәт эчендә үк утырадыр инде». Малайның уйларын төнгә хуҗа булып алган эчпошыргыч җил дә тарата алмады. Киресенчә, ул аны шомлы-шөбһәле уйлар сазлыгына этә генә, каһәр. Җитмәсә, келәттә ут та юк. «Әллә бүген өйдә генә йокларгамы? Сөт эчәргә тәки-тәк керәсе бар. Алай дисәң, караваты да, түшәге дә, мендәрләре дә келәттә бит». Үскәч, егет булгач, җинаятьчеләрнең үзләренә дәһшәт булып йөрисе Булатның куркып калуы белән һич тә килешәсе килмәде.

Малай ишекнең тоткасына ябышты. Шыпырт кына керергәме? Әллә ишекне тибеп ачарга да ук кебек эчкә атылыргамы? Гадәттә, киноларда җинаятьчене көтмәгәндә-уйламаганда кинәт бәреп кереп эләктерәләр. Теге каушап-югалып кала. Хәзер Булат та шомлы караңгылыкка ташланачак. «Кулыңны күтәр! Син тотылдың».

«Туктале, Булат! Кызма әле син. Кая сикерәсең? Тимерхан сине ике бармагы белән дә сыта бит. Шыпан-шыпан гына кер дә шыпан-шыпан гына ят инде. Юкка башыңны катырма. Шул дөм караңгы келәттә тычканнан гайре нинди җан иясе булсын. Кайчан керсен анда Тимерхан? Төнлә шакуы ихтимал. Беркөнне кемдер ишекне тартып куйды. Шул булмады микән?»

Ниһаять, ишек иренеп кенә шыгырдады. Келәт эчендәге салкын караңгылык авызын иләмсез ачкан аждаһа сыман йотарга әзер. Малай бусаганы атлады да туктап калды. Тагын бер адым атлады. Иелеп кулы белән нәрсәнедер капшагандай итте. Караватына барып җитмәгән иде әле. Отыры кулы түшәккә тиде.

Шул мәлне...

— Ай-й-й! — Булат җан ачысы белән кычкырып җибәрде һәм ук кебек ишегалдына атылды. Келәт ишеге төбенә хәтле ачык калды.

Нишләргә? Кайда йокларга? Аркан белән өстерәп кертергә теләсәләр дә, Булат келәткә кермәячәк. Малай ни булганын һаман да башына сыйдыра алмый иде әле. Дөм караңгыда түшәгенә иелүе булды — почмакта кемдер: «Пошт», — дип куйды. Бу — тәгаен Тимерхан. Күр әле син ристанны, аулак почмакка поскан бит.

Кара, җилле төн әсирлегендә үзе тоткын хәлендә калган Булат җәт кенә өй тәрәзәсен шакыды.

— Әни, әни, дим. Ач тизрәк!

— Ни булды, улым? Нишләп йокламыйсың?.. — Әнисе эчке яктан келәне кабалана-кабалана шудырды.

— Келәттә кемдер бар!..

— Кем булсын анда! Төн уртасында кем йөрсен?!

— Тимерхан бугай ул...

— Син ни сөйлисең, шайтан малай? Нишләп анда керсен ул?!

Булатның әнисе каяндыр тузанга баткан лампа табып алды. Селкетеп карады — керәчине бар. Филтәсенә ут элде дә келәткә китте. Булса да булыр икән йөрәк үзендә. Хәер, күрше авылдагы мәктәпкә берүзе җиде чакрым йөреп укыган ул. Дәресләре төштән соң булганга, авылга төн җиткәндә генә кайтып кергән. Юлда исә зират үтәсе.

— Кем бар анда? — Йөрәкле дигән әнисе дә келәткә килгән шәпкә үк кереп китмәде әле. Ул да сак маташа. Бер аягын бусагага куйды да сорауны тагын кабатлады: — Кем бар, дим?..

Тынлык. Келәттә келт иткән тавыш та юк.

— Ник дәшмисең?

Шомлы тынлык.

Әнисе бусаганы атлады. Лампаның сүрән яктысы караватны, караваттан идәнгә сузылып калган юрганны, түшәмне сыпырып алды, өстәл астын капшап карады. Бер почмакта әби-бабадан калган тубал, тырыс тора. Каба, кер бәләге, тәбелдерек аунап ята.

Келәттә кеше юк.

— Кемдер менә шушы почмактан «пошт» дип куйды бит инде.

Әнисе лампаны шул почмакка сузды. Идәндә утырып торган бодай ауган. Капчыкның авызы киткән. Әнисе кичкырын лардан он алырга кергәч, шунда бастырып чыгып киткән иде аны.

Капчыкны утырттылар. Бодайны кушучлап тутырдылар.

Юк инде, бүген келәттә йоклап булмастыр. Булат урын-җирен җыя башлады. Әнисе аны тышта, ишек төбендә көтеп торды.

Шул мәлне...

Артка, бакча ягына авыш келәт малайны юрганнары-ниләре белән бергә тагын «пошт» итеп ишегалдына «төкереп атты».

Лампа уты тагын теге почмакка ташланды.

Бая гына утыртып куйган, авызын бәйләмәгән капчык икенче якка ауган иде.

**Булатның бәрәңге базында күргәннәре**

Ул төнне Булат барыбер өйдә йоклады. Көтү куганчы уянды. Келәттәге төнге маҗаралар турындагы уйлар йокысыннан тиз уятты аны. Бодай капчыгыннан да куркып кал инде! Шуңа үкенү хисе аның вөҗданын газаплый, күңелен тырный иде. Малай ахылдады-ухылдады, маңгаена тибеп чыккан салкын тирне мендәр сүрүенә сөртте. Курку — табигый халәт. Тик менә әнисе алдында адәм көлкесенә калуы өчен ул үзен кичерә алмаячак. Әнисенең бердәнбер юанычым, таянычым дип йөрткән малае шыр җибәрсен әле.

Күңелдәге бөтен курку-шөбһәләрне юып төшерә торган илаһи таң яктысы өй эченә мулрак агып кергән саен, үкенү хисе көчәя генә барды. Чишмәле тау артыннан чыгып күтәрелеп килүче кояшның ил-көнгә сузган алтын нурлары тәрәзәдә уйный башлагач, җаны үзенә урын тапмады. Ястык-түшәген күтәрде дә янә келәткә чыгып ятты ул. Малай үз-үзенә сүз бирде: моннан ары беркемнән дә, бернидән дә курыкмаска! Аның бу дөньяда куркаклык белән саранлыкны җене сөйми!

Таң йокысы тәмле булса да, Булатта аның кайгысы юк. Әнисенең сыер саварга чыкканын, күрше-күләннең шау-гөр килеп көтү куганын — барысын да тыңлап ятты ул. Үзе дә торды. Әнисенең күзенә чалынмаска тырышып шыпырт кына өйгә керде. Кабыл-тибел генә тамагына капкалады. Аппетит юк. Акмуенның исә ашыйсы киләдер. Ул бозауны ындыр артыннан гына арканга алып китте. Каеш-бауны казыкка бәйләде дә, борчулы уйларыннан арынырга тырышып, күңеленә юаныч эзләп, тирә-якка карап торды. Җиргә җәй килеп ята. Үләннәрне, каен яфракларын яңа гына изелгән буяуга манып алганнармыни, алар ямь-яшел, җете, чиста, ялтырап тора. Кояш шушы яшеллеккә алтын йөгертергә тели, тирләп-пешеп нурларын коя. Тик алар яфракка төшү белән күзне иркәләп тагын бер балкып алалар да сеңәләр. Агачлар да, үләннәр дә кояшның алтын ашын йотып кына баралар. Кояш, кой аш! Шул нурларга ияреп сибелгән кошлар моңы гына каен очларына эленеп кала. Их, гел шулай нурлы, җырлы булып кына торсын иде бу

дөнья. Юк шул. Җир йөзендә һәрнәрсә үзгәреп тора. Кеше дә балкый, шатлана, кайгыра, сызлана, ялгыша, абына, үкенә...

Яшь бозау селәгәйле танавын ялап алды да, самими-ахак күзләрен кабартып, Булатка карап торды, гүя дустының йөрәк сызуын, борчылуын ул да сизә-тоя.

Булат, эш югында эш тапкандай, иске әвеслек тирәләрен урады, фермага сугылды. Сыерлар җәйләүгә күчкәч, малкайларның ихатасына күгәрченнәр, чыпчыклар хуҗа. Ындыр артлатып мәтәлә-кадала Кыям абзый чаба. Тагын кая кыяклый инде? Тәгаен колхоз эшен ташлап, берәр җиргә шабашкага таюы. Үзе ялт-йолт як-ягына карана. Йә пред, йә бригадир күрми микән дип шикләнә, күрәсең. Сыеры көтүдән кача, хуҗасы — колхоздан. Охшаса да охшар икән үз малына! Сыерының өч кушаматы бар: Кудырмәт («ку» сүзеннән), Гарасат, Афәт. Тагып кына торалар авылда кушаматны. Сыер әйбер әйтми, түзә. Тик менә көтүдән качмыйча түзә алмый. Ирек ярата.

Әнә колхозның иске бәрәңге базы. Авыл халкы аны «путвал» дип йөртә. Ул Гыйзелбанат әбинең өенә терәлеп тора дип әйтерлек. Ямь-яшел чирәм белән капланган яссылыкта бүселеп чыгып торган бер калкулык. Балчык түшәлгән түбәсен имән баганалар тотып тора. Баш-башларындагы керү-чыгу юлы туннельне хәтерләтә. Хәзер бәрәңгене яңа базга салалар. Уңыш шәп булган елны монысының да кирәге чыгып куя. Былтыр бу путвалның ишек катындагы оясына унлап капчык бодай да яшергәннәр иде. Караклар асларына су кергәнне сизде, күрәсең. Путвал тирәсендә бүтән күренмәделәр. Бодайны амбарга алып чыгып бушаттылар. Хак булса, Тимерхан шушы базда качып ята. Бәрәңге өмет итеп кереп чыккандыр, дип тә әйтәләр. Төрмәдән качтым дигәч тә, нәрсә ашап йөрергә кирәк. Аның да ашказаны бар бит. Бәрәңге булса, учак яга да көленә тәгәрәтә.

«Йөз кеше сөйләгәнне тыңлаганчы, бер тапкыр үз күзең белән күрүең яхшырак, диләр. Кереп чык әле, Булат, шул путвалга. Карап чык әле. Тимерхан шундамы? Юкмы? Эзе калмаганмы? Менә бит үз-үзеңне акларга, куркак булмавыңны исбатларга җае да чыгып тора».

Булат шундый уйлар белән сөзәкләнеп төшкән ат арбасы эзеннән базның як-ягына яртылаш ачылган ишегенә килде. Путвалны әкиятләрдәге кояшлы-җылы, якты дөньяга дәһшәтле авызын ачып карап яткан котсыз дию пәриенә охшатты ул.

Малай ишекне төбенә кадәр ачты. Яктылык баз эченә мулрак агып керде. Булат та аңа ияреп бер-ике адым атлады. Аннары беравык эчкә колак салып торды. Йөзенә дымлы салкын һава килеп бәрелде. Юеш балчык, черегән бәрәңге, күгәрек исләреннән күңеле болганып куйды. Булат тагын бер-ике адым атлады. Тагын туктап торды. Аллаһу әкбәр! Малай, икеле-микеле уйлап тормастан, уптым илаһи караңгылык эченә чумды. Тимерханның монда яту-ятмавын ачыклаудан бигрәк үзенең куркак җан түгеллегенә ышанасы, келәттәге төнге вакыйгаларның саташу гына икәнен исбатлыйсы, күңелен аз гына булса да чистартасы, тынычландырасы килә иде.

Путвал дөм караңгы. Булатның күзе тышта калды. Нindидер диварга килеп бәрелде. Кулы белән капшый-кармалый торгач, базны ояларга бүлгән такталар икәнен аңлады. Уртада коридор булса кирәк. Такталарга ышкыла-ышкыла бераз атлагач, малай туктап, тын да алмый тагын тыңлап торды. Кабер тынлыгы. Ул торган саен тәэсирлерәк, шомлырак була бара. Булатның мондый тынлык белән килешәсе килмәде, төбеннән үк кубарып тамак кырып куйды. Тавыш көр чыкса да, адәм бакмаслык салкынча тынчу баз, бик тансыклаган, күрәсең, аны шундук йотты.

Булат эчкәрәк узды. Өстенә ярмалы балчык коелды. Малай әллә нишләп китте. Тереләй күмәләрмени. Вак балчык — гүя гүр балчыгы, коридор такталары — гүя ләхет такталары.

Тышта кемнеңдер сөйләшкәне ишетелде. Булат «ләхет»кә посты. Юк, монда гына качып котылып булмаячак. Ул бер ояга сикерде дә түрдәге почмакка барып чүмәште. Ишек шыгырдап куйды. Тавыш эчкә кермәде. Бераздан ул тагын да тоныкланды һәм... югалды. Булат башын калкытты. Эчтә дә, тышта да тавыш юк. Киткәннәр, димәк. Дөресрәге, киткән. Үз-үзе белән сөйләшеп, юкны бушка аударып йөрүче генә булды бугай ул, чөнки тавышы бер дә үзгәрмәде. Малай яңадан коридорга сикереп төште. Ярый, керде, күрде. Базда Тимерхан да юк, шайтан да юк. Хәзер инде бу тәмугтан чыгып ычкынырга кирәк. Булат ишеккә юнәлде. Чү! Ачык ишектән саркып торган яктылык тәмам кысылып беткән. Булат адымын кызулатты һәм нәрсәдәндер

шикләнеп ишеккә ташланды. Шул мәлне баштан салкын су койган кебек булды, кан тамырлары кысылып, тез буыннары җебеп китте.

Ишек тыштан бик нык итеп терәтелгән иде.

Нишләргә?

Ничек чыгарга?

Путвалның икенче башы җир ишелеп томаланган. Булат читлектәге бөркет кебек күзләрен астан — өскә, өстән аска йөртте. Кая караса да, карашы өметсез караңгылыкка килеп төртелде. Котсыз-шыксыз караңгы базда бикләнеп калуын башына сыйдыра алмады. Тагын ишеккә ташланды. Этеп, сугып, тибеп карады. Тик кырыклы такталардан эшләнгән нык, авыр ишек бирешмәде. Аны кемнеңдер килеп ачканын көтәргә кала инде. «Сабыр гына көт, Булат. Авызыңда кан булса да, төкермә. Сине берәү дә өстерәп алып кермәде. Үзең кердең. Керүен кердең дә... Чыгуын... Җан биргәнгә юнь бирә, диләр. Ничек тә бер чыгарсың әле. Кеше төрмәдә дә утыра. Ун-унбиш ел утыра. Гомер буена утыра. Әнә төрмәдән качкан Тимерханны шушы базда яшәп ята икән, дип тә сөйлиләр әле. Нишләп монда ятсын ул?! Бер тәмугны икенчесенә алмаштырырга юләр түгел бит. Саф һавага, кояш нурына, иреккә сусаган адәм баласына путвал кирәкме?! Хәер, кем белә, бәлки, төрмәнең авыр һавасыннан, җан биздергеч мохитеннән туйган тоткын өчен туган ягындагы шушы баз да кадерледер. Һәрхәлдә, монда күңелеңне кысып торган нурсыз тимер рәшәткәләр дә, буйдан-буйга сузылган, бәгырьне чәнчеп торган чәнечкеле чыбыклар да, ачылганда-ябылганда шыгырдап-чыңлап тешкә тия торган иләмсез ишекләр дә, почмак саен кукраеп торган котсыз вышкалар да, каныңны эчеп йөрәккә төшә торган кибәк-кандалалар да, колакларын шомрайтып, телләрен чамасыз асылындырып бертуктаусыз ыслап, һич кирәкмәгәнгә абалап өреп торган этләр дә юк. Әйе, дөнья йөзен күрми, зинданда чери адәм балалары. Ә син бәрәңге базында очраклы гына бикләнеп калып та, бая өстеңә сибелгән иске балчык кебек коелып төштең. Үзеңне тоткыннар урынына куеп кара. Төрмәгә эләгүдән Алла сакласын.

Кеше бу тормышның рәхәтен дә, михнәтен дә күрә. Җинаятьчеләр туып үскән авылларда да тәрәзәләр кояшка карыйдыр, җәйге мамыклы кичләрдә елга суы коенырга җылы буладыр. Аларда да мунчаны бөтнек, мәтрүшкә кыстырып бәйләгән каен, имән миллекләре белән чабыналардыр. Дөрес, ул тоткыннар арасында нахакка гаепләнүчеләре дә бардыр. Булыр-булыр. Дөнья бу! Тукта әле, Булат, нигә үз-үзеңә нотык сөйләп утырасың әле. Бу кош-корт зинданыннан — элек монда колхозның иген басуына кергән казларны ябалар иде, кайчакта җим чүпләргә кергән тавыклар да оя такталары арасына кысылып кала — чыгу җаен карарга кирәктер бит инде. Әнә Тимерхан өтермә хәтле өтермәдән дә качып чыга алган. Ә син язын йомшап беткән елак бәрәңге дә борын төртеп чыга ала торган баздан чыгалмый аптырап утырасың». Булат уйларыннан арынып җәһәт кенә сикереп торды да, җанын кая куярга белми, ары-бире йөрергә тотынды.

«Тәк, бәләкәй чакта келәгә буй җитмәгәндә бөтен йөрү гел капка астыннан иде бит. Нигә әле монда да ишекнең астын казымаска. Баш сыйган хәтлерәк казыйсың да мәче кебек сузылып чыгасың. Их, булсын иде көрәк сыман бер әйбер». Тора торгач, бу караңгы базда күз дә ияләште. Малай базның бер почмагында мурган яркалар, черек-мерек такта башлары өелгән бер күчкә тап булды. Актара башлады.

Абау! Кулын ток куырдымыни. Күч астында ниндидер хәшәрәт ята иде. Йоны кошныкына охшаган. Карга-мазар кереп үлгәнме соң? Алай дисәң, исләнер иде ул. Булат, кулына бер таяк алып, үләксәне кәшәләп чыгарды. Бәй, тавык ич бу! Теге каракларның тишек-мошык капчыкларыннан коелып калган бодай бөртекләрен чүпләргә кергән тавыктыр инде. Кемдер аны тоткан да чалган. Һәм шушы күч астына яшереп куйган. Кем булсын? Хәтәрдер инде! Димәк, аның монда качып ятуы — хак сүз. Үзе кайда икән соң? Булат тагын тынсыз калып як-якка карады. Баз дәшмәде. Бая ишекне кем терәтеп китте икән? Төрмәдән качкан кеше көпә-көндез күз көеге булып йөрмәс бит инде?! Булат тавыкны үз урынына куйды. Өстенә теге күчне өйде. Хәтәр аны алырга киләчәк. Мөгаен, төнлә килер ул. Кайда пешерергә җыена икән ул моны? Наил абыйсы Казанга китте. Кич кайта. Аңа әйтергәме, юкмы бу хәлне?

Малайның бу күңел чиркандыргыч баздан котылу теләге тагын да зурайды. Көрәк дигән нәрсә табылмады. Шушы бичара тавык яткан чүп-чар оясыннан сука төрәне килеп чыкты. Суга батканда саламга ябышкандай, Булат ишек астындагы җирне шул утиль кисәге белән чукырга кереште. Чукыды-чукыды, тик эш үсми. Песи ялаган кебек кенә. Арба көпчәкләре таптап-тыгызлап бетергән балчык энә төртмәслек булып каткан. Җитмәсә, төрән вак таш кисәкләренә эләгә дә тешкә тиеп шыгырдый. Шул вакыт өстән балчык тузаны коелды. Баз эченә яктылык таягы сузылды. Булат төрәнен күтәреп шул турыга бер суккан иде — дивардагы калын гына бер ташның купканын искәрде. Аны теше-тырнагы белән тартып алды. Оя тактасына менеп басты да башын тыгып тышка карады. Кеше-кара күренмиме? Измә балчыкка гына утыртылган тагын бер-ике ташны төртеп төшерү әллә ни кыен булмады. Шулай итеп, баздан чыгу юлын Ходай үзе күрсәтте. Астан көткәнне өстән бирде. Чыккач күрде: ишек бер авыр торба кисәген җиргә батырып терәтелгән иде. Булат ташларны кире урыннарына урнаштырды. Үзеннән эз калдырмады.

Бәрәңге базында әҗәлен тапкан тавык турында ул әлегә беркемгә бер сүз ычкындырмады. План исә мондый иде: караңгы төшә башлагач, Банат әбинең абзар артына качып, засадада утырырга! Тавыкны кем килеп алыр? Хәтәрме, башка берәүме? Бу операциягә Наил абыйсын да чакырса... Кояшның утлы тәгәрмәче Кирәмәт тавына таба тәгәри башлагач, Булат йомыркасы бар тавык кебек йөри башлады. Ары сугылды, бире сугылды. Бер керде, бер чыкты. Үзләреннән өч өй аша гына сузылып яткан путвал тирәсен тагын бер күзәтеп килергә булды. Килсә... путвал ишеге ачык. Көндезге визит тагын кабатланды. Булат тирә-юньгә күз салып алды, аннары путвал эченә карап торды. Кеше-мазар юклыгына ышангач, базга керде. Дөресен әйткәндә, бу юлы да кыяр-кыймас, курка-курка гына керде. Исәбе — тиз генә керергә дә тиз генә чыгарга. Туп-туры теге такта башлары, утын яркалары күченә таба китте. Үзе ишектән күзен алмады. Тагын ябып калдырсалар... Хәер, чыгу юлын белә инде ул хәзер. Чү! Кемдер күчне актарган, таратып аткан түгелме?!

Тавык?..

Тавык юк!..

Хәтәр эше түгелдер бу. Төрмәдән качкан кеше көн күзендә монда йөрмәс. Төнәген капка төбендә Корыкукыр: «Иртәгә тимерчегә пычак кайратырга менәм», — дип сөйләнеп торды. Йә менгәндә, йә төшкәндә путвалга кергәндер. Аның ачмаган ишеге, кермәгән тишеге юк. Кулында пычагы да булса...

Төнге план җимерелде...

## Күкчә кызы

Булат аны сабантуйда күрде.

Күрде дә... күзләрен аңа төбәп катып калды. Малайның мәйдан бетереп йөргән аякларын бераз ял иттереп алу, аз гына утырып тору теләге белән тауга менеп барышы иде. Югарыда иптәш кызы белән басып тора иде Ул. Өстендә элпәдәй юка зәңгәр күлмәк. Җәйге күк төсенә охшаган якты, кояшлы, аяз көндә талгын җылы җилдә җилфердәп торган итәкләре офыкларга кадәр җитә кебек. Кызны да менә-менә күк гөмбәзенә очырып алып менеп китәр кебек ул күлмәк. Үзе дә күктән төшкән чибәркәйдер бу. Нәкъ уртадан ак юл калдырып иңнәренә агып төшкән кара чәч, кара күз, төз борын. Елмаерга гына яратылган, як-якка киерелеп тартылган нәфис дымлы иреннәр... Нәкъ София Ротару инде.

Күрше Күкчә кызы диделәр аны.

Ике авыл арасы ерак түгел, тартып-сузып, өч чакрым тирәсе булыр. Ул җәйне Булат бу юлны шактый таптады. Шул кызны күрер өчен генә йөрде ул. Велосипедына атлана да чыгып чаба. Күкчә — утыз-кырык өйле кечкенә генә авыл. Әдип Мөхәммәт Мәһдиев әйтмешли, кечкенә авылларның кызлары чибәр була, каһәр. Авылда башлангыч мәктәп кенә. Анысы да бүген-иртәгә

ябылырга тора. Укырга күбесе Өтермәскә йөриләр. София Ротару Чишмәбашка киткән. Анда аның бертуган апасы яши, кыз шуларда торып укый икән.

Булатның «разведка»сы озакка сузылды. Инде җәй уртасы җитте. Матур кыз белән танышырга-сөйләшергә җай чыкмый. Беркөнне клубтан кайтканда малай, юк егет — борынына кызлар исе кергәч, малай буламыни инде — ияреп караган иде.

Чибәркәй өенә кайтып җитеп, капка келәсенә үрелгәндә генә эндәште ул аңа:

— Әй, кызый, сиңа бер сорау бар иде.

— Йә, әйтеп кара. — Кыз күмер күзләрен Булатка төбәде.

Егет ни дип әйтергә дә белмәде. Джинси чалбары, кофтасы тәненә сыланып торган калку түшле, үзеннән озынрак бу кыз алдында телен йотты. Аның «Исемең ничек?» «Йөргән егетең бармы?» дигән дежур сораулар бирәсе килмәде. Хикмәтле сүз башта юк. Күр әле, күпме йөреп, «свидание»гә әзерлексез килгән бит.

— Юкмы сүзең? Соравың да юкмы? Алайса, минем сорауны тыңла. Кесәңдә кулъяулыгың бармы? — Кыз җавапны көтеп тормыйча җәт кенә кереп тә китте.

Булат үзе дә сизмәстән битен сыпырып алды. Борын асты чиста иде. Нигә андый сорау бирде ул? Борын астың кипмәгән килеш кызлар янына килгәнсең дип малайсытып әйтүе инде тәгаен. Их, Ротару, Ротару! Пычаксыз суйдың бит егетне.

Бу кыз белән борчак пешереп булмасына борчылып, аңа үпкә-ачу саклап, аны онытырга тырышып та онытa алмыйча газапланып йөргән көннәр артта калды. Таза бәдәнле дип әйтерлек бу кыз янында үзенең ябык, курач булуына гарьләнде Булат.

Юк, болай пешмәгән булып йөреп булмый. Үсәргә, гәүдәне, килеш-килбәтне кеше карарлык рәвешкә кертергә, тән тәрбиясен кайгыртырга кирәк. Булат йөгерә башлады. Җәй беткәнче чапты, көз чапты. Кышын чаңгы шуды. Яшелчә бакчасындагы үзе ясап куйган турниктан төшмәде. Шушы мавыгуларның файдасы тиде, күрәсең, сөбханалла, егет кинәт калынаеп-үсеп китте, җилкәләре киңәйде, тәненә ит кунды. Язын район үзәге Артышлы Тауга солдатка беренче тапкыр каралырга баргач та табиблар мактадылар үзен. Әнә шул көнне Ротару (Булат сорашып белде, аның исеме Гөлия икән) белән тагын очрашу насыйп булды. Кайтканда поездданн төшүгә күреп алды ул аны. Кызның да каяндыр кайтышы иде. Стансадан Өтермәскә Күкчә аша кайтасы. Димәк, бергә кайтачаклар. Гөлиянең күңел кылын тагын бер тартып карарга форсат бар.

Юлга чыктылар. Һавада — төче ис. Тирә-юньдә — ташу, гөрләвекләр шавы. Бераз баргач, Булат Гөлиянең арттарак калуын искәреп алды. Классташ малайлар кызу бара шул. Егет адымнарын әкренәйтте. Дөрес, яшьтиләр әллә ни ерак китә алмады. Алда үзән чыгасы. Хәтәр үзән! Юл өзелгән иде. Кыска кунычлы бутый кигән Гөлиягә бу ташкынны ерып чыгу турында уйлыйсы да юк. Кыз да, малайлар да бермәл югалып калдылар. Ничек тә чыгасы инде. Кырда кунып булмый бит. «Ябыш миңа әйбәтләп», — диде Булат Гөлиягә һәм аны иплəп кенә күтәреп алды. Кыз чырылдап, чинап-чиелдап җибәрде. Үзе исә йомшак нәфис куллары, җылы беләкләре белән Булатның муенына чорналды. Егет, су төбен итегенең табан асты белән капшый-капшый, акрын гына шуа башлады. Кар суы итеккә тулырга тора. Булатның башында бер генә уй: аяк таеп китеп егылмаска гына. Югыйсә эш харап. Бозлы суда үзең дә коеначаксың, Гөлияне дә коендырачаксың. Аннары бу кызның күзенә күренмә инде. Булат суның урта бер җирендә туктап калды. Малайлар аңа көч биреп кычкырып тордылар. Ул аларны да, ташу тавышын да, гөрләвекләр шавын да ишетмәде. Аның колагына кызның кайнар, дәртле сулышы гына бәреләә иде. Тәки чыктылар бит! Дөрес, Булатның бутыена су тулды тулуын. Аның каравы Гөлия чиста, коры. Егет бу кыз өчен кар суына муеннан батарга да риза.

Ташудан алып чыгып аягына бастыргач та, Гөлия Булатның муенына уралган кулларын беравык «чишмичә», ычкындырмыйча торды.

Бәгырьләрдәге туң юмарт кояш җылысында эреде, күңелләрдәге юшкын кар сулары белән агып китте, хисләр көчле ташудай ургылды, йомык йөрәкләр тук бөреләр белән бергә ачылды...

Җирдә яз иде...

**Өрәк**

Һәр шимбә, якшәмбедә Күкчә клубында дискотека. Дискотекадан соң Булат Гөлияне озатып куя. Бүген дә озатты. Кайтып җиткәч, гадәттәгечә, ике яшь йөрәк капка төбендә сөйләшеп утырдылар. Сүз ара сүз чыгып, Гөлия Хәтәр турында сорашып куйды. Тагын күрүчеләр юкмы? Тотмаганнармы?

Булат бермәл уйга калды. Бәрәңге базын, суелган тавыкны күз алдына китерде. Боларны Гөлиягә әйтергәме? Юк, әлегә әйтми торуың хәерле.

Егет белән кыз арасындагы төнге сөйләшү Тимерхан качып яткан Кирәмәт тавы белән зират тирәсендә барды. Зират дигәннән, Булат моннан ун еллап элек авылларында булган бер вакыйганы сөйләде.

Үзләренә чыбык очы туган тиешле Вениамин абый ат җигеп стансага төнге поезд каршына менә. Поезд килеп туктый. Тик аннан берәү дә төшми. Вениамин абыйның да кайтасы кешесе кайтмый. Электричка «дежурный» кычкыртып ала да кузгала, отыры төнге урман эченә шуып кереп югала. Вениамин абый атын кайтыр юлга бора. Тирә-юньдә шомлы төн. Эт тә юк. Тынлык. Ара-тирә ат пошкырып, чана шыгырдап куйганы гына ишетелә.

Ат кинәт туктап кала. Вениамин абый чөңгереп ала, дилбегәсе белән суккалап карый. Малкай кузгалырга уйламый да. Каршыда бүре-фәлән юктыр ич? Вениамин абый чанасыннан сузылып-каерылып юлга карый һәм шунда бер кеше басып торуын күреп ала. Кем ул? Төн уртасында япан кырда ялгызы кем йөри? Ат борчыла, кыбырсый. Төнге мосафир, малкайны куркыта-куркыта, чана янына килеп баса.

— Өтермәскә шушы юлдан барасымы?

— Тек минем шул авылга кайтыш. Утыр әйдә!

— Рәхмәт!

Теге чанага тезләнә. Ат кушаяклап чабып китә.

— Өтермәскә кемгә кайтасың?

— Мине авылда онытканнардыр инде. Кырык бердә сугышка чыгып киткән кеше мин. Мәсрүрәнең ире Сахап булам.

— Тек син исәнмени? Сугышта үлдең бит син!

— Авылда көтеп торучы, каршы алучы юк инде алайса...

— Ник алай дисең? Хатының исән.

— Ул мине онытты инде...

— Тек сугыш беткәнгә кырык ел. Кайда, нишләп йөрдең соң син?

Фронтовик дәшми. Ул юл буе башка бер сүз дә әйтми.

Авылга җитәрәк, зират янында атны туктатырга куша:

— Мин, абзый, зиратка кереп чыгам. Син кайта тор, сөенче ал. Бераздан мин дә кайтырмын. Чәй куеп торсыннар. — Төнге юлдаш, карга бил тиңентен бата-чума, зиратка кереп китә.

Ул төнне бөтен авыл уяна. Мәсрүрәләрнең өе халык белән тула. Тулмый ни! 40 ел элек сугышта һәлак булган солдат кайтып төшсен әле!!! Көтәләр. Иренеп кенә кышкы таң ата. Көн туа. Мәсрүрә нишләргә белми. Ире Сахап күренми дә күренми. Зиратка баралар. Карыйлар: карда кергән эз дә юк, чыккан эз дә юк. Буран-мазар булмады, җил дә исми. Югыйсә ул эзләр күзеңә керердәй булып ярылып ятарга тиеш бит инде.

Вениамин абзыйны сүгәләр:

— Йөрисең шунда кысыр сөенче белән...

— Күзеңә генә күренгәндер ул...

— Чанаңда йоклап китеп, төш күргәнсеңдер...

Вениамин абый сүзен бирми:

— Кайтты. Зиратка кереп китте. Валлаһи газим. — Аннары болай дип өстәп куя: — Мине юләргә санамагыз инде. Салмыш та түгел. Үзем күрдем, үз күзләрем белән. Ипидер...

Каравылчы Габбас атның ак күбеккә батып, әсәренеп, алакаеп кайтып керүенә гаҗәпләнә, югыйсә Вениамин абзый малны каулый, куа торган кеше түгел.

Соңыннан авыл халкы Сахапның өрәге кайткандыр дип фараз кыла.

...Гөлиягә нәрсә аңа, егете сөйләгәннәрне йотлыгып тыңлап утырды да өенә кереп ятты. Булатка исә, төнне ярып, Өтермәскә кайтасы. Зиратны үтәсе.

Әнә шул өрәкле зиратны!

Тимерхан качып яткан зиратны!!!

Каберстанга җитәрәк йөрәк леп-леп итә башлады. Әле ярый ай яктысы бар. Курыкмас өчен Булат Гөлия турында гына уйлый. Уй аңа — иптәш. Күңел экранында — яраткан кызы, җимеше, юанычы... Охшаса да охшар икән Ротаруга. Юк, ул аңа охшамаган. Ротару аңа охшаган. Гөлия — бер генә, бердәнбер!

И зират! Адәм баласына җир куены ачыла, «постоянный прописка» бирелә, бөкреләр турая торган урын. Нишләп болай серле, сагышлы, караңгы, куркыныч соң син?!

Зираттагы җен-пәриләр, өрәкләр, Тимерханнар Булатның күңел экраныннан Гөлияне тартып төшермәкче булалар. Кыз бирешми. Теше-тырнагы белән каршы тора. Көрәшә.

Шул вакыт зиратта әрвах-мәетләр патшалыгының тынычлыгын бозып, кабердә яткан үлекләрне, агач башындагы козгыннарны сискәндереп, чырт итеп ботак сынып куйды.

Абау!

Күңелдәге экран да, Гөлия дә юкка чыктылар. Каядыр очып киттеләр.

Күз алдында йөрәгең ярылып үләрлек коточкыч күренеш: кулына озын таяк тоткан берәү зираттан чыгып бара... «Төн. Зират. Тимерхан. Өрәк. Таяк... Тө... Зир... Тим... Өр... Тай...»

Кара куркуга төшкән Булат космик старт алды. Шабыр тиргә батып, артына борылып карарга да куркып, авылга хәтле чапты.

Теге адәм: «Тукта, тукта, чапма!» — дип кычкырып калды.

Булат өенә дөбер-шатыр кайтып керде. Ашамады-эчмәде, юрган астына чумды. Таң атканчы күзенә йокы эленмәде. Төнге зиратта күргәннәре башына сыймады. Кем булыр ул таяклы адәм? Өрәкме? Тимерханмы? Тимерхан дисәң, буе икенде күләгәсе кебек озын иде. Хәер, курыкканга куш...

Ул төнне Булат келәттә түгел, өйдә йоклады.

**Борчулы төн**

Числинникта — җәй, ә көн утырырга уйламый әле. Әле салкын, әле яңгыр. Көн кинәт кенә суытып җибәргәч, Булат та вакытлыча келәттән өйгә күчте.

«Капканы бикләп, эшне бетереп кердем. Син бүген чыгып йөрмисеңдер инде?» — дип сорады әнисе беркөн кич. Кая чыксын? Зиратта күргәннәреннән соң Булатның беркая чыкканы юк.

Алар ул көнне иртәрәк яттылар. Икесе дә ятуга йоклап киткәннәр. Төн уртасында сискәнеп-куркышып уяндылар. Утны кабыздылар. Аптырашып бер-берсенә карадылар.

Кемдер капканы кага!..

Кем икән ул? Җиде төн уртасында вакытлы-вакытсыз кем йөрер? Булат эчтән генә уйлап куйды: «Тәгаен Тимерхан бу. Димәк, теге төнне зираттан чыкканда ул аны танып калган. Әллә путвалга кереп, күзәтеп йөргүен сизгәнме? Кулындагы таягы да эшкә яраган. Капкага шуның белән бәрепме-бәрә». Әнисе күрше авылдагы төнлә капка каккан тавышка уянып һушыннан язган теге әбине күз алдына китерде. Һушыңнан да язарсың, шашарсың да бу хәлгә. Күр әле, чакырылмаган төнге кунак баганалары череп болай да аварга торган капканы бертуктамый кыйный. Әле ярый янында улы — Булаты бар. Үзең генә булсаң...

— Ут-күз юктыр бит? — Әнисе өйне ишекле-түрле йөреп чыкты. — Юк, тәрәзәләргә төн сыланган. Хәер, пожар булса, чаң кагарлар иде.

Булат чөйдәге бушлатка үрелде. Теге көнне келәттәге бер капчык бодай аркасында хур булган егеткә бүген куркып торуын әнисенә һич тә сиздерәсе килмәде.

— Син чыкмакчы буласың мәллә? Тилермә! Бәлки, кагар-кагар да китеп барыр. — Әнисен әйт әле, ни йөрәкле хатын инде, Ул булып Ул куркып калды.

Тавыш бермәл тынып торды. Өйдәгеләрнең «Китте, ахры» дип уйлаулары булды — таяк капка «кабыргаларын» тагын саный башлады. Гүя таяк йөрәккә, җанга суга.

Аптырагач әнисе дә киенде. Икәүләшеп баскычка чыгып бастылар да ишегалды түреннән кычкырдылар:

— Кем син?

— Ы-ы-ңы-гы...

— Кем?

— Гы-ы-ы-ңы-ы...

— Кем дисең?

— Ы-ы...

Әнисе карашын Булатка төбәде:

— Юк, улым, юньле кеше түгел бу. Тизрәк өйгә кереп китик. Ишекне биклик. Икебезне дә харап итеп куймагае...

Булат кереп китәргә уйламый иде. Капкага килергә дә ашыкмады. Тагын бер сорап куйды:

— Тимерхан абый, син мәллә?

— Ыңа...

— Тимерхан абый!

— Гы-ы-ң...а.

Тукта, хатын-кыз ич бу. Тавышы ирләрнекенә охшамаган.

— Ы-ңа-а. А-а... вәйт! — Капка артындагы адәм тагын да үҗәтләнебрәк, тагын да катырак кага башлады. — А-ңы... терә вәйт.

— Бәй, Банат әби түгелме соң? Нишләп йөри ул? Ни булган?

Капка ачылды. Анда, чыннан да, бер кулына таяк тоткан, икенче кулы белән авызын томалаган Гыйзелбанат әби басып тора иде. Аның кул хәрәкәтләреннән, ыңгырашуларыннан шунысы ачыкланды: йоклаганда ияге төшкән бичара карчыкның. Булатның әнисе исә чыккан, тайган, каймыккан сөяк-санакларны урынына утырта белә. Банат әби дә азапланып яткан-яткан да, әрнүенә чыдар хәле калмагач, ярдәмгә өметләнеп монда килгән. Байтак вакыт тырыша торгач, Булатның әнисе дә, әби дә шабыр тиргә баткач, ияк урнашты, карчыкның теле ачылды. Ул тешсез авызын метмелдәтеп рәхмәтләр укыды.

Гыйзелбанат әби өенә кайтырга чыкканда, урамда яктыра башлаган иде инде...

**Ансар янды**

Булат бәрәңге базына яшерелгән, муеныннан кан саркып торган тавык, төнлә зираттан чыгып килгән таяклы кеше (Тимерханмы ул, өрәкме, шайтан белсен) турында берәүгә дә сөйләмәде, бу серле-шикле вакыйгаларның сүлен чыгармады. Наил абыйсына да ләм-мим бер сүз әйтмәде. «Тавыкны кулдан ычкындырдым, Хәтәрдән куркып качтым», — дип сөйләп торсынмыни. Хәер, борчулы эш-мәшәкатьләр Хак Хаҗи малаена — участковыйга көн саен өстәлә тора.

Көпә-көндез урам уртасында кыңгыр эш өстендә Ансар-Амбар тотылды. Бу юлы култык астындагы яраткан халаты хыянәт итте аңа.

Кирамнар турысында Булат белән Корыкукыр преднең куе пычракка кереп баткан «Волга»сын этеп маташалар иде. Хуҗа үзе дә шунда. Чаттан Ансар килеп чыкты. Амбардан кайтып барышы. Башка машина баткан булса, гамьсез генә үтеп киткән булыр иде. Ыштыр бит. Пред хәтле предкә булышмыйча ничек китәсең?! Ансар да, теләр-теләмәс кенә, бер кулы белән машинага ябышты. Икенче кулда — кадерле халат. «Волга», куе-зәңгәр төтеннәр чыгарып, кинәт кенә алга тартылып куйды. Ансар аяк астындагы йомшак кәсләргә сөртенеп егыла язды. Култык астындагы халатыннан целлофан пакет шуып төште. Аннан бодай агып чыкты. Шул бөртекләр белән бергә җәен, кышын Ансар-Амбарның култык астында йөргән, төсе уңып беткән халатының бөтен сере агып чыкты. Кучкылланып торган пычрак балчык өстендә гәрәбәдәй алтын бөртекләр пәйда булды.

Ансар янды! Кем әйткәндәй, Биатайныкы ярылды.

— Капчыклап урлый алмагач, аз-азлап урлыйсың, ә, — диде пред, аяк астына чәчелгән икмәккә кызганулы караш ташлап.

Аның «капчыклап» диюе теге вакытта бәрәңге базына яшерелгән бодайны күздә тотуы иде булса кирәк.

— Тавыкларга сибәргә алган идем... — дип быдырдады Ансар.

Аның шыр сөяккә калган, йоны коелып беткән ике тавыгы гына барын беләләр бит инде. Әби-чәбиләргә шыпан-шыпан гына капчык-капчык икмәк сатып ятуын да сизә башладылар.

Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә, диләр. Ансарның әле амбарга куелуына ел да юк. Менә шулай, Булат, кабасы кеше үзе дә килеп каба ул. Тик Булатның бүген урланган бодайга әллә ни исе китмәде. Аның җете күзе гел халатта булды. Халатның якасына һәм итәгенә тигән зәңгәр бояуга игътибар итте ул.

Зәңгәр бояу!..

Тәк, зәңгәр... Нәкъ күк төсендәге сыек-ачык зәңгәр. Шунда ук кучкылланып торган тагын бер тап. Кан табына охшаган. Булат әллә нишләп китте, нәрсәнедер исенә төшереп, сискәнеп-калтыранып куйды.

Юк, күпне күргән, сусәргән, күңел чиркандыргыч иске халат серләрен ачып бетермәде әле...

Ансар тотылган көнне үк прит участковыйга мөрәҗәгать итте: «Каракның өенә кереп, келәтенә, лапасына күз салып чык әле». Наил шул көнне үк бастырып килеп тә керде. Ул кергәнче, Ансар өч капчык бодайны, ике арадагы койманың такталарын кубарып, күрше Мәсрүрә карчыкка шудырып өлгергән иде инде. Участковый керде, карады. Тычкан егылып төшсә, башы ярылыр, келәт тә, лапас та, лар да чиста иде.

Ансар-Амбар берәүнең дә йөзенә күтәрелеп карамас булды. Гел сукранып, үзалдына сөйләнеп йөрде. Аның шулай үз-үзе белән сөйләшеп йөрүен Булат та күрде. Күрде һәм уйлап куйды: «Теге көнне аны бәрәңге базына ябып калдыручы да шушы Ансар-Амбар булмады микән? Амбары да шунда гына бит. Ә халатындагы зәңгәр таплар?

Ах ул зәңгәр, зәп-зәңгәр таплар?!»

Беркөнне Булат Наил абыйсының: «Келәте буш, лары буш. Иске мунча ләүкәсе астында яткан капчык төбендә нәрсәдер бар иде. Анысы да тавык җоны булып чыкты», — дигән сүзләрен ишетеп калды. Сүз Ансар-Амбар турында бара иде. Тавык җоны Булатның бөтен тынычлыгын алды. Ул участковыйдан шул җон турында кат-кат сорашты, аңа урман бете кебек кадалды. Наил абыйсы: «Нигә хаҗәт соң сиңа ул җон?» — дип сорагач, егет иске бәрәңге базында күргәннәрен сөйләп бирергә мәҗбүр булды.

Суелган тавык Гыйзелбанат карчыкныкы булып чыкты. Моны ишеткән Булат шул көнне үк, йомычканы йомыш итеп, әбигә керде. Керде дә үгезне мөгезеннән алды:

— Банат әби, нишләп бу тавыкларыңны зәңгәргә буядың?

— Тамга, менәтерә. Бу чыгарган соңгы оянык гел кара тавыклар булды. Күршеләрнеке дә кара, менәтерә вәйт. Буталышып бетәләр. Минекеләр аларга керә, аларныкы — миңа. И олан, бер тавыгым юкка чыкты бит әле. Тәк йөргән җирдән суга төшкән кебек булды, менәтерә вәйт. Шул югаласы көнне барысына да зәңгәр бояу сөртеп чыгардым. Улым чардуган буярга Казаннан алып кайткан иде. Озак кибә торган бояу. Шул Тимерхан хәерсез генә эләктерде, ахры. Иртән Ансар әйтте аны. Чыгарма бу кара каргаларыңны, диде. Кара булгач минем тавыкларны «карга» дигән була инде ул. Әйтерсең лә үзенекеләр — һөмай кошы. Менә шул Ансар әйтте, теге төрмә кошы качып кайткан, эләктермәсен каргаларыңны, диде. Карга карганың күзен чукымый, ә карга карагы чукый, дип тә сөйләнеп торды әле, менәтерә вәйт. Шунда тавыкларымны ишегалдына кертеп, капканы ябып куйган булсам, менәтерә вәйт. Ярар инде, буласы булган, буявы сеңгән.

Булат Банат әбисе сөйләгәннәрне утырган тавык кебек тын да алмый тыңлады. Үзенең дә бәрәңге базында футболкасына тигән зәңгәр бояу тапларын күз алдына китерде. Кулы канга да буялган иде. Егет участковыйга барысын да сөйләп бирде. Ни өчен Ансар-Амбардан шикләнүен аңлатты. Хак Хаҗи малае Ансарга янә сугылды. Бу юлы теге капчыкны актарып карады. Булат

дөрес шикләнгән. Участковыйның зәңгәр сөртелгән бер-ике бөртек җонны папкасына алып салуын күргәч, янәшәсендә басып торган хуҗа катып калды.

Шул көнне Ансар-Амбар йортын бикләп, ике тавыгын суеп биштәренә салды да авылдан чыгып ычкынды.

**Авыл печәнгә төште**

Соңгы вакытларда теңкәгә тигән болытлы көннәр, үҗәт яңгырлардан соң күк йөзе ачылып китте, көн утырды. Җәй канатын җәйде. Тимерханны бүтән күрүче булмады. Хәер, кем күргән соң әле аны? Мин күрдем дип тәгаен әйткән кеше бармы?! Имеш-мимеш, гайбәт-майбәтләр бер колактан керде, икенчесеннән чыгып китте. Төнге зираттагы таяклы өрәк кенә һаман да Булатның күз алдыннан китмәде.

Печән өсте.

Уттай кызу печән өсте.

Авыр, мәшәкатьле көннәр. Күңелле көннәр. Ах, ул урманда печән чабулары. Җәй зеңгелдәп тора. Урман зеңгелди. Зеңгелди күңел. Хисләр нечкәрә, бәгырьләр йомшара, бер-береңә ачу-үпкәләр онытыла.

И урман!

И печән өсте!..

Кеше күңеле чалгы чыңына сискәнеп, үлән арасыннан пырх итеп күтәрелгән кошчык булып талпына, урманның назлы куенына кереп сеңгән аулак аланнарга бихисап чәчкәләр булып сибелә, җәйнең сутын сеңдергән җиләкле пакуслар булып сузыла.

Булат та печән чабарга, күзен ертып, таң ката китә. Башта биек тау менәсе, аннары күкчәчәкле кырны үтәсе, урманга кергәч, тагын 5–6 чакрым барасы. Тауны менгәч, егет утырып хәл ала. Хәл алмый, Күкчәгә карап Гөлияне уйлап ала. Инде ул да торгандыр. Юк, тормагандыр әле. Караватына ябышып, кайнар сулышы белән мендәрен эретеп ятадыр. Бәлки, торгандыр. Алар да печәндә бит.

Гашыйклар кичә генә күрештеләр. Йокы нәзер түгел, иртән-иртүк торасы булса да, капка төбендәге эскәмияне озак җылыттылар. Гөлия өенә кереп киткәч, Булат, тауга менеп, Өтермәскә тау башыннан кайтты. Хәзер ул зират янынннан йөрми, өстән йөри. Башы ике түгел бит зират ягыннан йөрергә. Бу юл да куркыныч. Тау күкрәгенә утыртылган яшь наратлар арасыннан кыргый этләр ырлап кала.

Ачтым басу капкасын,
Җәйдем киндер басасын.
Унөч яшьтән гыйшык тотып,
Күрдем гыйшык җәфасын, —

дип җырлаган, ди берәү. Җәфалы булса да, татлы, ләззәтле ул гашыйк булу. Яшьли сөйгән ярлар ятка кала, диләр. Аларга егетнең җавабы әзер: «Калдырмасаң — калмый ул!»

Булат утырган урынынннан сикереп торды да, кулларын өскә күтәреп, киерелеп алды. Күңелдә дәрт ташый, тамырларда яшь кан йөгерә. Их, тизрәк барып җитәсе иде дә печән чабасы иде. Киң сулап, киң алдырып, киң пакуслар салып...

Чабынлыкка җитәрәк егет олы юлдан читтә, карурман белән әйләндереп алынган, үзе генә белгән кечерәк кенә бер аланга сугыласы итте. Анда елның елында җиләк шәп була. Быел да бар микән? Разведка ясап чыгарга кирәк. Егетнең исәбе — кайтышлый җиләкне сабагы белән җыярга! Кич Гөлиягә җиләк бәйләме бүләк итәргә!

Булат аланга керде. Керде дә көтмәгәндә-уйламаганда бер шалашка тап булды. Читтәрәк казан асылган. Корыган каенга балта кадалган. Баш миен бер сорау кисеп алды: кем? Егет җәт кенә чыршы артына посып күзәтә башлады. Ак каенга эленгән көзге кояш нурларын сындыра, күзне чагылдырып зәһәр яна. Әһә, бер адәм заты шалаштан чыкты да шул көзге янына килде. Кулына нәрсәдер тоткан. Пумала икән. Икенче кулында — касә. Ул пумаланы касәдәге күбеккә батырып алды да битенә ышкый башлады. Кырына, димәк.

Бу Тимерхан иде!..

**«Зэк» кайчан елый?**

Кая ул җиләк карау... Кая ул печән чабу... Җиләк кайгысымы?! Печән кайгысымы?!

Урманда кеше үтерүче, куркыныч җинаятьче качып ята. Соңгы вакытта арзамаслылар аның коралланган булу ихтималын да кисәттеләр. Ристаннар — алар дүртәү булган икән — качкан көнне шул тирәдәге бер хәрби частьтан корал урлыйлар. Шик боларга төшә. Бу хәбәрне ишеткәч, Булат уйлап куйган иде: «Коралы була торып, нигә таяк тотып йөрде икән соң ул зиратта?»

Тизрәк, тизрәк авылга төшәргә! Участковыйга әйтергә! Печән өстендә урманның кайнаган вакыты. Җинаятьче, моны сизеп, бүген-иртәгә табанын ялтыратырга мөмкин. Аның өчен кеше күзеннән ерактарак булу хәерле.

Булат авылга борылды. Әле артына, әле як-ягына карый-карый йөгерде. Хәтәр сизмәде тагын үзен. Сизсә, атарга да күп сорамас. Олы юлга чыгуга аңа икенче Булат дәште: «Туктале, кая барасың син, малай актыгы? Оныттыңмыни теге чакта язгы ташу вакытында басуда үлә язганыңны. Тимерхан абыең килеп коткармаса, беткән идең бит. Сине әҗәл тырнагыннан тартып алучыны, коткаручыңны сатмакчы буласыңмы? Эчеңдә җаның бармы синең, юкмы?!» Беренче Булат тагын телгә килде: «Нигә туктап калдың? Кузгал, атла, йөгер, чап! Кеше үтерүченең кайда качып ятуын күреп тә ни намусың белән дәшми калырсың. Үзең үскәч бандитлар белән көрәшмәкче буласың тагын. Хәчтерүш! Ашык, ашык, Булат, җинаятьчене ычкындыра күрмә».

Ул арада колакта Наил абыйсының кайчандыр әйткән сүзләре яңгырый: «Бу эштә, энем, дусмус, кода-кодагый юк. Бу эштә фәкать закон гына бар. Шуны үтисең икән, синнән кеше чыгачак!»

Газаплы-интегүле уйлар Булатны озак ычкындырмый торды. Ай авыр хәл. Ул Хәтәрен әйтер идең инде, шайтан алгыры, нәкъ менә Булатка очрап торырга кирәк бит! Хәер, күңеле сизенгән иде аны.

Булат авылга төшеп китте...

...Аланга бу юлы керү җайсызрак булды. Аяк астында аунап яткан черек-чарык, ботак-сатак, кеше буе кура, кычытканнар, биткә-күзгә сыланып-сарылып интектергән пәрәвез челтәрятьмәләре... Моның өстенә чыршы ботаклары чалбар-күлмәкне эләктереп ала, эләктереп ала да җибәрми, гүя урманның Тимерханны бирәсе килми. И урман, урман, кеше җанын кыючы икәнен белмисең шул син аның. Синең өчен барысы да газиз бала шул.

— Кулыңны күтәр! Каршылык күрсәтсәң — атам! — Участковый кабурасындагы тузан җыеп яткан пистолетын Тимерханга төби. Качкын шул мәлдә корыган каен артына сикерә һәм агачтан балтаны тартып алып милиционерга томыра. Наил абыйсы башын җәт кенә иеп калырга өлгерә. Балта доңк итеп карт наратка килеп кадала. Ул арада ристан шалашына чума һәм шуннан ут ача. Наил абыйсы да утка ут белән җавап бирә. Китә атыш.

Куркудан котлары алынган мәхлук җәнлекләр тирә-якка сибелә. Тыныч яшәргә күнеккән, келт иткән тавышка да сискәнеп китә торган бичара кошлар җан ачысы белән кычкырып һавага күтәрелә. Үз гомерендә мондый хәлне күрмәгән урман зар иңрәп ыңгыраша. Ул да булмый, Хәтәр аланнан карурманга ташлана. Кача бит, кача! Участковый аны куа китә. Бермәлне Тимерхан абынып егыла. Наил абыйсы, аның өстенә басып, пистолетын «зэк»ның чигәсенә тери.

Әйе, Хәтәрне кулга алу операциясе менә шундыйрак сурәттә дә булырга мөмкин иде бит. Һәрхәлдә, Булат атышу ихтималын күздә тотып бик борчылды. Наил абыйсы борчылмагандыр дисезме?! Ни уйлавын йөзенә чыгармаса да, ул да бигүк чиста эшкә бармаганын, «юешкә» керү ихтималын сизә-аңлый иде.

Шалашны күрүгә, участковый Булатка катгый әмер бирде: «Дөнья хәлен белеп булмый. Син хәзер бу тирәдән югаласың. Аңладыңмы? Бәладән баш аяк».

Булат калды. Бераздан алан түрендә Хәтәрнең көр тавышы яңгырады:

— О-о-о, Наил! Мин Сезне көтә идем, гражданин начальник.

Операция шау-шусыз, атышсыз, кансыз булырга охшап тора.

Бераздан шалаш янына, борын төртәсе килеп, Булат та килеп басты. Сүз тыңламаган малайга участковый күзен чайпалдырып карады.

— О-о-о, Булат та монда икән! Үскәнсең, егет булгансың, — диде Тимерхан.

Хәтәр әллә ни үзгәрмәгән. Кыска чәч, киң маңгай, якты күзләр, сау караш. Үзе шактый арыган күренсә дә, аның алгарак чыгып торган киңчә ияге бу егеттә зур ихтыярлылык, үз-үзенә ышану барын искәртеп тора. Буй-буй күлмәгенең кыска җиңеннән кабарган тыгыз мускуллары шәйләнә. Шалашы таслап салынган киртәләргә печән түшәп эшләнгән. Моны күрүгә Булат уйлап куйды: «Төннәрен черки, озынборыннарга ничек түзеп ятты икән. Үзләре Корыкукыр белән бер төн дә түзә алмадылар». Шалаш түрендә кипкән үлән җәелгән «караваt». «Идәндә» — банка. Банкада — сөт. Шунда ук кулга да тотып, җилкәгә дә асып йөри торган зур сумка. Наил белән Булатны иң гаҗәпләндергәне Шүрәле булды. Хәтәр монда да тик ятмаган, аны үзе ясаган. Корыган агач кисәгеннән нинди сын килеп чыккан. Кемнәрне генә сөендерми дә, кемнәрне генә юандырмый синең бу Урман сарыгың, и Тукай! Өйдә — чисталык-тәртип. Йорты — парна кыры. Тирә-якта — сер сыяр алан, сабыр урман.

Өчәүләшеп юлга кузгалдылар. Сөтле шалаш, корымлы казан, түтәсе күгәрә башлаган балта, хуҗа китеп барганга, нәүмизләнеп калдылар. Боек, моңсу карашлы Шүрәле дә калды.

— Их, егетләр, белмисез хәлләремне, — диде Тимерхан, авыр сулап. — Нахакка эләктем бит мин. Эштән кайтышлый ресторанга кереп утырдым. Ресторан димәсәң, хәтере калыр, бер өйнең адәм рәтенә китерелгән подвалы инде. Утырам шулай. Акча бар. Заказга мебель эшлим. Кухня шкафлары, стенкадыр, чурттыр-мурттыр. Ресторанда бер егет бәйләнде. Ашаган-эчкән. Чут кәгазен миңа суза. «Түлә!» — ди. С какуй стати мин аңа түләргә тиеш әле. Сикереп тордым да теге нахал-наглыйны якасыннан тотып җилтерәттем. На «шару» ашап йөрүче сорыкортларны җенем сөйми. Минем тегене җилтерәткәнне, әйе, әйе, җилтерәткәнне — сукмадым, суксам үтерәм бит — официанткалар да, бармен да күреп тордылар бит инде. Ресторанда утыруымның яме, ашның тәме китте. Расчет ясадым да өйгә кайтырга кузгалдым. Кайтырга чыккансың икән, юлыңда бул инде. Мин, юләр, урамда, ишек төбендә тәмәке тартып торам бит әле. Бераздан теге дә атылып чыкты. Чыкты да, беркемгә күтәрелеп карамыйча, урамның теге ягына йөгерде. Мин — аның артыннан. Исәбем — тагын бер тапкыр иманын киергә. Якасыннан эләктереп алуым булды — егет минем өскә ауды. Йөзе ап-ак, маңгае — шабыр тир. Шунда ни күрим, күлмәгенең күкрәк турысыннан кан тибеп тора. Моңа кадаганнар. Егетне җиргә сузып салдым. Кулымда җан бирде. Халык җыела башлады. Ни арада ментлар, «скорый» килеп җитте. Ментлар мине һәм тагын бер-ике егетне бөкләп машинага тыктылар. Кесәләрне тентеделәр. Отделда минем свитерны салдырдылар, сораулар биреп башны катырдылар. Иртәгесен теге егетләрне чыгарып җибәрделәр. Мин калдым. Свитерга кан эләккән. Экспертизага биргәннәр. Тикшереп карыйлар — теге егетнең каны. Шуннан башланды инде мине газаплаулар, җәфалаулар. Егеткә бәдрәфтә кадаганнар. Кем кадаган? Черт белсен! Беркем күрмәгән! Шунысын башыма сыйдыра алмыйм: пычак кергән йөрәк белән подвалдан йөгереп менәргә һәм урамның теге ягына йөгереп чыгарга каян көч тапты икән ул?! Җитмәсә тагын, үтерелгән егет шундагы бик зур бер түрәнең улы булып чыкты. Өстән приказ — үтерүчене немедленно тотарга! Тотмасагыз... Кемнең эштән китәсе килсен?! Тиз «тоттылар» бу эшне, миңа сыладылар да теге түрәгә рапорт бирделәр. Кеше күзе алдында теге егетне якасыннан тотып селкегәнсеңме? Селкегәнсең! Свитерыңа каны тамганмы? Тамган. Тагын ни кирәк?! Әле официантлар алдында, үтерәм, дип тә әйткәнмен, имеш. Җиде ел чәпәделәр. Хатаны төзәтерләр, хакыйкать җиңәр дип ышандым. Көннәрдән бер көнне тимер ишекне ачарлар да: «Галлямов, с вещами на выход!» — дип әйтерләр кебек иде. Тот капчыгыңны! Көттем-көттем дә, әллә иблис котыртты, качарга булдым. Юк, котыртмады иблис.

Төрмәдән качуым — гаделсезлеккә нәфрәтем!

Бу — протест!

Нишләп әле мин бер гаепсезгә «падаль»ләр, «поганяло»лар, «опущенный»лар, «легавый»лар, — җыен фуфло белән бергә бер ояда тончыгып ятарга тиеш?! Нишләп әле мин гөнаһсыз башымны ташкапчыкта черетергә тиеш?!

Нишләп?!

Торып-торып төртенердәй булырсың. Ачу килә. Юк, мин анда тәртип бозмадым үзе. Берәүгә дә кул күтәрмәдем, берәүдән дә кыйнатмадым. Төрмә дигәч тә, анда да шәп егетләр күп анысы. Тик аларга «есть за что» утырырга.

— Сездә ни хәлләр соң? Син, Булат, ничәнче класста инде?

— Быел унга барам.

— Син че! Да, үтә гомер. Кайчан гына кеп-кечкенә малай идең.

Әңгәмәгә участковый кушылды:

— Сөтне каян алдың соң? Әллә сыер да асрадың инде ул урманда?

— Син че, бер матур апаегыз ташып торды. Тамагымны да кайгыртты, сатмады да.

«Сатмады» дигән сүз йөрәгенә ук булып кадалдымы, Тимерхан абыйсының үз итеп сөйләшеп кайтуы, бер гаепсезгә газап чигеп йөрүләре болай да беркатлы күңелен йомшартып җибәрдеме, Хәтәрнең яну-көюләре малайның ныгып җитмәгән психикасына тәэсир итеп куйдымы, Булат барган җирдән бер кирәкмәгәнгә-урынсызга участковыйга ялвара башлады:

— Наил абый, әйдә, тимик аңа! Калсын шушында. Аны бездән — икебездән башка бер кеше дә күрмәде бит әле. Наил абый, зинһар! Жалкы бит!

— Ни сөйлисең син, юләр. Шаяртасыңмы, әллә чынлап әйтәсеңме?

Юк, Булатның сүзләре ихлас иде.

— Их син, башың яшь, дөресрәге, яшең баш шул әле. — Наил абыйсы Булатка гаҗәпләнеп һәм чәнчеп карап куйды.

Их Булат, Булат! Гаепләме ул, гаепсезме, суд карарын Өтермәс урманында үзгәртеп булмый шул. Участковыйның аны үтәмәскә хакы юк. Хак Хаҗи малаена үтенү-ялваруларын саташу, ахмак беркатлылык икәнен егет үзе дә аңлады. Наил абыйсы алдында балалыгын-малайлыгын тагын бер күрсәтеп алуына үкенде. «Юк, Булат, чыкмый синнән бернинди хокук сакчысы». — Егет бу минутларда үзенең татлы хыялын да тимер читлеккә озата иде.

— Син че, Булат, — диде Тимерхан, малайның борчу һәм үкенү тулы карашын тоеп, — эләктермәсеннәр, дисәм, мин бу шалаштан сез килгәнче үк тайган идем инде. Төрмәдән дә качарга була, сездән дә... Тик бер җирдән качып булмый.

Каян дисезме?

Үз-үзеңнән!..

Кара сакалың, гәрчә ул кемнәрнеңдер пычрак кулы белән тагылган булса да, синнән калмый, кая барсаң да сөйрәлеп бара. Аннары болай йөрү дә туйдырды инде. Күпме йөрергә була йортсыз йомран булып?!

— Төрмәдән ничек качтың соң? — Сорауны участковый бирде, Булат башын аска иеп тын гына атлавын белде.

— Беләсеңме, Наил, өеңдә тәртип булсын дисәң — өястыңда тәртип булсын, илеңдә тәртип булсын дисәң — төрмәдә тәртип булсын.

Илдә бардак — төрмәдә бардак. Син че! Әйе, шулай.

Качканда канализация торбасына кермәдек, контейнерга чүп астына ятмадык — чиста качтык. Койма астын казыдык. Дүртәү шуышып чыктык. Чыгуга дүртебез дүрт якка сибелдек, югыйсә каптырачаклар. Туган якка шактый озак кайттым. Көндез кемгәдер мич чыгарып бирәм, бакча казыйм, балта-пычкы тотам. Төнлә юлда. Шулай кайтып җиттем мин. Артышлы Тау станциясендә ике мент янына килеп, юри генә тәмәке сораган булдым әле. Тәмәке дә бирмәделәр, миңа да тимәделәр.

Койма астын казыдык, дигәч, Булатның күз алдына иске бәрәңге базы килеп басты, сука төрәне белән ишек астын чокып маташуы исенә төште.

— Сине иске бәрәңге базында да, зиратта да качып ята икән дип сөйләделәр. — Участковыйның бу сүзләрен ишеткәч, башын аска иеп барган Булат та күтәрелеп карады.

— Син че. Базда — бәрәңге, зиратта адәм сөяге чери. Ә минем черисе килми әле. Минем яшисем килә. Матур яшисем килә.

Туп-туры урманыма күз төбәп кайттым мин. Мәктәптә укыганда ук ятимлегемә, кеше балаларыннан ким-хур яшәвемә нәүмизләнеп киткән чакларымда да мин урманга барып, кү-

целемә юаныч таба идем. Урман — үзе бер дөнья. Җанлы дөнья. Ипле дөнья. Кешелек җәмгыятенә ничек яшәргә кирәклеген урманнан өйрәнәсе. Кырмысканы гына ал. Иң бөек математиклар — кырмыскалар. Кырмыскалар — иң шәп академиклар. Ояларын гына күрегез сез аларның. Гаҗәеп төгәллек. Искиткеч проект! Вентиляциясенә кадәр бар. Күрер күзгә күренми торган, бөкләп тыгып куйган бер яфрак кисәге генә үзе. Әле тагын аварийный вентиляцияләре, аварийный ишекләре бар. Һәркайсы табигатьнең бер капризына — йә яңгырга, йә давылга исәпләнгән. Кайсына исәпләнгәне ояга нинди градус белән урнаштырылуыннан тора. Төрмәдә пожар чыга калса, Алла сакласын, янып үләсең. Вентиляция дә юк анда. Булса да эшләми ул. Хәер, кайда эшли соң ул? Их, егетләр, кырмысканыкы кадәр генә дә хокукыбыз юк бит безнең бу кара дөньяда.

— Син бүген кырынгансың, чиста күлмәкләр кигәнсең. Әллә теге чибәркәй килергә тиеш идеме? — Участковый елмаеп куйды.

— Син че, ул ерактан килә бит. Әллә нигә бер генә килә. Эш кешесе. Сезне каршы алырга кырынып куйдым. Юк, юк, шаяртам. Беләсезме, урман кырынмаганны яратмый. Кырынмасаң, юынмасаң, җиләген дә, какы-кузгалагын да яшерә. Бүген мунча көне иде.

— Ниткән мунча ул тагын?

— Караңгы төшкәч, Поп елгасыннан бер чиләк су алып менеп куям. Иртән учак ягып кайнатам. Шуның парында утырам. Мәтрүшкәле, бөтнекле миллегемне шул суда пешекләп чабынып та алам әле.

— Тагынниләр җимерттең? Погоннарыма карама, допрос алу түгел, үз итеп сорау.

— Уйланып яттым. Кабартылган түшәктә генә йоклап, шәп креслода гына утырып, башыңа уй килми. Арт никадәр йомшакта, ми шулкадәр сыек. Адәм баласы ни өчен яши бу дөньяда? Зир-зибәр килеп болганып беткән бу дөньяда? Мин «зэк» булыр өчен яшәдемме? Юк, адәм баласы бәхетле булу өчен яши. Ә үзе бәхетнең ни икәнен аңламый.

Авылда Сабантуй көнне җанымны кая куярга белмәдем. Эчемдә ут дөрләде. Түзә алмадым, Кирәмәт тавына чыгып, мәйданга карап тордым. Халык әллә ни күп булмаса да, Сабантуй бит ул. Шул ук болын, шул ук су буе. Яр буендагы өянкеләре дә шул ук. Гөрли бәйрәм: колгага да менәләр, ярышалар да. Атлар да чабыша. Тик алар икәү генә калган икән инде.

Көрәш!.. Татарча көрәш!.. Син че!

Йөрәгем кысып куйды. Эчемдәге ялкын ургылып тышка бәреп чыкты. Мин — ут эчендә. Нишлим? Күлмәгемне салдым да кулыма сөлге итеп чорнадым. Каршымда — имән. Мин аңа чытырдатып ябышам, төбе-тамыры белән күтәреп алмакчы булам. Үзем елыйм. Мин — «зэк», Сабантуй көнне, мәйданга керә алмыйча, авылымның тау башында елап утырам. Халык бәйрәм итә. Классташлар, яшь чакта без күз атып йөргән чибәр кызлар, кунаклар кайткандыр. Алар — бәхетле. Тик шул хакта берәрсе уйлап карады микән?! Артыңнан йә пистолет, йә автомат төбәп тормасалар — иң зур бәхет шул.

Их, егетләр, бәхетле булырга язмагандыр инде миңа. — Тимерхан урманда ятып кеше белән сөйләшүне тансыклаган, күрәсең, күңелен бушатты да бушатты. — Минем язмыш гел нахактан тора. Авылда яшәгәндә күрше Мәсрүрә әбинең тавыкларын суеп ашаучы булып чыктым бит инде мин. Уф, шул чакта гарьләнгәннәрем. Кем әйткәндәй, хурланып сарут тамырына асылынып үләрдәй булдым. Тавыкка тиямме соң инде?! Җитмәсә, ялгыз карчыкныкына! Син че! Сабантуйда алган тәкәләремнең дә итен кешегә өләшә идем бит.

— Син оныт инде ул тавыкларны. Аны ашаучы тотылды.

— Да син че! Кем ашаган? Ничек тотылды?

— Менә Булат тотты аны. Синең «дустың» Ансар эше булып чыкты ул.

— Круто, братан! Кайда, ничек тоттың? Сөйлә әле!

Балтасы суга төшкәндәй, үзенең кәвеш очларына карап барган Булат берни дә сөйләрлек, берни дә әйтерлек хәлдә түгел иде.

— Күңел үсеп китте бит әле, егетләр, югыйсә мин бу тормышта өмет-ышанычны бөтенләй югалтып бара идем инде. Рәхмәт, брат! — Тимерхан кояшта-җилдә ашалып беткән бармакларын Булатка сузды. — Кулың җиңел булып, бу нахактан да котыла алсам иде, Ярабби.

Шул минутта тимер читлек гүя җимерелде. Балачакның татлы ак хыялы ак болытлар өстендә тирбәлде, күктәге ак кыялар эргәсенә кунды.

Хыял кыяга кунса, Булатның йөзенә исә елмаю кунды.

Артышлы Таудан Хәтәрне алып китәргә тиешле машина килеп җиткәнче, Тимерханны колхоз ашханәсенә алып керделәр. Пешекче — Корыкукырның хатыны аңа аш салып бирде, «второй»га бәрәңге белән зур гына тавык боты китерде һәм әйтеп куйды:

— Айлар буена урманда ятып, йөрәгең киселгәндер, аша!

Тимерхан ашны ашады.

Тавыкка тимәде.

* * *

Тимерхан киткән көнне кич капка төбендә пычакларны һаман да кайрамаган Корыкукыр төкерек чәчте:

— Күрдегезме, минем сүз дөрескә чыкты. Әйттем ич мин сезгә ул Тимерханны урманга кача дип.

— Менәтерә вәйт. Син әллә кая, тайгага, дидең түгелме соң? — Банат әби, ияге тагын төшә күрмәсен дип куркып, сүзен иреннәре арасыннан сөзеп чыгарды.

— Ник тайга урман түгелмени?! Безнең урманның тайгадан кай җире ким?! Тайгага дисәм дә, Айга димәдем бит. Государственный масштабта уйлагыз сез. Ату чыгардылар, зиратта качып ята, имеш. Булдым мин ул зиратта. Төнлә булдым. Черт та юк анда. И беркөнне әни төшкә керде бит, Гыйзелбанаттәй, ышанасыңмы? Улым, ди, бакчама кәҗәләр керә, ди. Коймасы юк, ди. Уянып киттем. Һай, минәйтәм, чардуган сорый ич бу. Әнинең үлгәненә биш ел. Һаман чардуган куярга кул җитми. Йөрәгем түзмәде. Тордым да, метр ярымлы линейка тотып, төнлә зиратка киттем. Әнинең каберен үлчәргә. И анда бер кызык хәл булды бит әле. Каберне үлчәп чыгып барам, берәү Күкчәдән кайтып килә. Танымадым кем икәнен. Кызлар яныннан кайтышы булгандыр инде. Мине күрде дә йөгерде генә. Тукта, минәйтәм, чапма, бергә кайтабыз. Юк, чапты гына.

Күршесе Кирам абыйсының бу сүзләрен тыңлап утырганда Булатның җилкәләре куырылды, башы аска иелде. Үзе: «Бүген Гөлия янына туры юлдан барасы булыр», — дип уйлап куйды.

...Ул көнне Кыяк Кыямның Кыямәт кушаматлы «тоягы» көтүдән тагын качты.

## Җиденче палата

Сорау: Бүген өлкәннәр балаларны иң әүвәл кемнән, нәрсәдән якларга-сакларга тиеш? Сугыш чукмарларыннанмы, террорчыларданмы, наркоманнарданмы?.. Ачлыктанмы, бәла-казаларданмы?
Җавап: Өлкәннәрнең үзләреннән.

*Халыкара балаларны яклау көне уңае белән бер телевизион тапшыруда яңгыраган сүзләр.*

Бүген мәктәпкә барганда, улыгыз Ардуанны машина таптаган. Аны «скорый» белән 12 нче бүлнискә алып киткәннәр. — Безгә шалтыраткан хатын тагын нәрсәдер әйтте инде. Тавышы калтырый иде, соңгы сүзләрен аңлап булмады. — Хатыныгыз эшкә килеп җитмәде әле, шуңа күрә сезгә шалтыратабыз.

Иртән редакциягә эшкә килүгә, менә шундый аяктан егарлык хәбәр алдым. Шып итеп урындыкка утырдым. Хәлем китте, күз алларым караңгыланды. Башта бер генә сорау: улым исән микән? Чабарга, тизрәк бүлнискә чабарга! Безнең редакция урнашкан Язучылар берлеге йортының ишегалды машина белән тулы була торган иде. Бүген бер «Волга» да бер «Джип» кына. Үзебезнеке эш белән киткән иде. «Волга» бер дус мөхәррирнеке. Аңа керәм. Хәлне аңлатам.

— Их, машинаны бик бирер идем дә, срочно барасы җир бар, — ди ул, сәгатенә карап, һәм йөзенә мул итеп интегүле-газаплы теләктәшлек билгеләре чыгара.

«Джип»ның хуҗасы — Семен атлы бер эшкуар. Аны белмим. Шулай да аңа әйтеп карарга җөрьәт итәм. Семен минем ни йомыш белән йөрүемне ярты сүздән аңлады.

— Киттек! — диде ул, ике дә уйламыйча. Безгә аның хезмәттәше Айрат та иярде.

Кызыл «Джип» Казан урамнарындагы машиналар ташкынын, вак ташлар арасыннан шуышып барган кәлтә елан кебек ера-ера, алга чаба. Әмма ул миңа барыбер акрын барган кебек тоела.

— Тизрәк, Семен! Зинһар өчен, тизрәк!

Кызыл утка туктап калганда, мин җанымны кая куярга белмим. Шушы минутларда улым үлем белән тартышып ятадыр да, мин генә аны әҗәл тырнагыннан тартып алып калырмын кебек.

Башымда утлы уйлар өермәсе. Иртән телефоннан алган йөрәк өзгеч хәбәрнең һәр сүзен күңел иләгеннән үткәрәм. «Улыгызны машина таптаган». Көпчәк астында калган була ич инде бу. «Безгә шалтыраткан хатын тагын нидер әйтте инде. Тавышы калтырый иде. Соңгы сүзләрен аңлап булмады» дигәне «улыгыз үлде» дигән хәбәр түгелме соң инде.

— Семен, ашыкмасагыз да була. Һай, Аллам, шул бердәнбер улымны да күпсендеңмени соң?

Семен белән Айрат миңа борылдылар:

— Син кайгырма. Тынычлан.

— Ул бүлнистә морг бит. Зур морг. Апам шунда ятканда, мәетләрне китерүләрен үз күзләрем белән күреп тордым. Исән булса, аны Казанның бер башыннан икенче башына алып китмәсләр иде. Югыйсә РКБ безнең янда гына бит. Коткарып калырлык булса, шунда гына алып керерләр иде.

Йөрәгемнең тагын хәле китте. Күкрәгемне кайнар дулкын кысты.

«Беләм мин ул моргны. Эшләми ул. Ремонтта». — Семенның шушы сүзләрен ишеткәч тынычлангандай булдым.

«Караңгыда адашмас өчен юлчыга — бер шәм яктысы, салкында өшемәс өчен кечкенә генә бер учак җылысы да җитә», — дигән әдип. Ә менә кайгы-хәсрәткә чумган кешенең өмет учагын тергезеп җибәрергә бер сүз җитә икән.

Рәхмәт сиңа, Семен!

Миңа бүлнискә синең белән барырга Ходай үзе кушкандыр. «Морг ремонтта» дип әйтүең күңелдәге сүнеп килгән күмерләргә өреп җибәргәндәй булды.

Тик бу юаныч әллә ни озакка бармады. Бактың исә, шофер бүлнискә юлны белми икән бит. Юлны белмәгәч, моргның эшләмәгәнен каян белә ул?! Соцгородка җитәрәк сулга борыласы булган. Ә без егерме икенче завод янына китеп барганбыз. Йөри торгач, бүлнискә әйләнгеч ясап, Шималь, Коры Елга бистәләре ягыннан килеп төшәргә мәҗбүр булдык. Бу араны үтү миңа

Мәскәүгә барып кайткан кебек тоелды. Әнә бүлнис. Чү, морг эшли түгелме соң?! Ишеге ачык. Аннан аз гына читтәрәк «скорый» да тора. Улымны алып килгән машина шушы микәнни инде? Эчем тагын жу итте. Тәнем чымырдап куйды. Күкрәк эчендәге меңнәрчә кыллар чытыр-чытыр килеп өзелде.

Ах син, Семен, алдагансың ич!

Йөрәгемне учыма кысып, бүлнис ишегалдына уздым. Ә җирдә яз. Апрель кояшы җиһанны нурга күмә. Их, яшисе дә яшисе бит әле. Юк, аякларымның һич кенә дә моргка таба атлыйсы килми. Үземнең «приемный покой»га килеп керүемне сизми дә калдым.

Стена буенда носилка. Аңа ак халатлы бер егет, ике хатын-кыз иелгәннәр. Кем ятканын һич күреп булмый. Менә берсе чүт кенә читкәрәк тайпылды. Шул мизгелдә дер-дер калтырап торган иреннәрне шәйләп алдым. Бу кипкән зәңгәрсу иреннәр — минем улым бит!

— Улым! — Носилка өстенә капланып, Ардуанның үземнеке төсле каты куе чәчләреннән сыпырам.

Аның сул як чигәсе кара янган. Ияге сыдырылган.

— Улым, син исән! Аллага шөкер! Аллага шөкер!!! Аллага шөкер!!!

Мин тагын аның киребеткән чәчләреннән, йомшак кулларыннан сыпырам. Хикмәти Хода, Ардуанның иреннәре калтыраудан туктый. Әле генә теше тешкә тими иде бит. Үзе дәшми. Моңсу күзләрен бер ноктага төбәгән дә уйга калган.

— Улым, әйтче, кайда, ничек булды бу хәл?

Ардуан әллә ишетә мине, әллә юк. Ул арада ак халатлы егет кулы белән җилкәмә кагылып ала.

Мин читкәрәк китәм. Семен белән Айрат та монда икән. Китмәгәннәр. Шатлыгымны уртаклашучы беренче кешеләр — алар.

— Сез малайның этисеме? — Каршымда кулына микрофон тоткан бер чибәр генә кыз тора. Ә уң яктан безгә «Эфир» дип язылган камера төбәлгән.

— Әйе, этисе булам.

— Улыгыз ничәнче класста укый?

— Өчтә.

— Ул мәктәпкә һәр көнне үзе генә чыгып китәме?

— Үзе генә. Беләсезме, мәктәпкә кадәр бернинди юл чыгасы юк аңа. Фәкать тротуардан гына барасы. Аның өчен җаныбыз тыныч иде. Кайда бәргән аны машина? Башыма сыймый.

Без сөйләшеп торган арада, Ардуанны рентгенга алып кереп киттеләр. Коридорда сумкасы белән бутыйлары гына аунап калды. Бутыйларын пакетка салдым. Сумкасын алыйм дисәм, китаплары, дәфтәрләре коелып төште. Һай, улым, ничек исән калдың син?! Сумкаң төбе тетелеп беткән бит. Җепләре генә калган. Аны бүлниснең чүплегенә чыгарып ташлаудан башка чара юк. Кем белә, бәлки, нәкъ менә аркаңа аскан шушы сумка саклап калгандыр әле сине.

Улымның исән калуына ышандым. Инде хәлен беләсе килә бит. Башына зыян килмәгәнме? Аяк-куллары бик нык имгәнгән булып гарип калмасмы? Үпкә, бөер, бәвел куыгы, ят җире ни хәлдә?

Бераздан барысы да ачыкланды.

— Улыгызның баш мие селкенгән, таз сөяге сынган, — диде травматология бүлеге мөдире.

Әлегә буш карават юк икән. Көтеп торырга куштылар. Көтәбез. Сулда — табиблар бүлмәсе, уңда — операция залы. Ардуан яткан каталка белән рәттән тагын бер каталка тора. Анда бер абзый ята. Ул менә-менә операциягә кереп китәргә тиеш. Шунда аның түшәмгә текәлеп уйга чумган нурсыз күзләренә, кәфен төсле агарып чыккан кызгандыргыч йөзенә игътибар иттем. Юк инде, чырай юк. Мәет тә мәет, бу да мәет. Абзый борчыла, курка, күрәсең. Менә аны алып кереп тә киттеләр. Ходай түземлек бирсен сиңа, абзый.

Отыры улым йоклап китте. Биш минут черем итте микән, дерт итеп куркып-сискәнеп уянды.

— Сумка, минем сумка кайда?

— Борчылма, улым. Монда сумкаң, монда.

Шөкер, улымның гаме бар икән әле. Шушы хәлдә дә сумкасын сорап ята бит, бичара.

— Улым, әйтче, зинһар. Кайсы төштә, нинди машина бәрдерде сине? Ничек? — дип сорыйм Ардуанның кулын учыма алып.

Ул кулын җәт кенә тартып алды. Иреннәре кысылып куйды. Ияге шадраланып чыкты. «Нервылар кысылган» дип уйлап алдым эчтән генә. Димәк, әлегә баланы аптыратмау хәерле.

Шул вакыт носилка янына буе белән дә, яше белән дә нәкъ улым чамасындарак, киңчә борынлы, куе кара кашлы бер малай килеп басты. Ул чәчләрен маңгаена кыеклатып төшереп тараган. Өстендә — фасонлы кара майка. Муенында — керләнгән муенчак. Ул самими күзләрен улыма текәгән. Бу малайга ни-нәрсә булды икән дип кызыксынып йөргүеме, әллә улымны кызганып басып торуымы? Ардуан аның шулай чекерәеп карап торуын яратмады. Карашлары очрашуга башын читкә борды. Ә мин, улымның ачуын чыгарып тормасын әле дип, бу малайга сүз катарга булдым:

— Нинди муенчак асып йөрисең син?

Малай минем эндәшүне генә көткән диярсең — яныма ук килеп утырды. Чит кеше белән сөйләшү аңа тансык, күрәсең.

— Ә минем, абый, умыртка сөяге бит... Беренчесе, икенчесе, дүртенчесе хөрест. Чана шуганда сикертмәдән очып сальто ясаганмын. Ә бу малайга ни булган?

— Машина белән сөзешкән.

Муенчаклы малай әүвәл миңа сәерсенеп карап куйды, аннары ихлас елмайды.

— Аны безнең палатага салалар. Җиденчегә.

— Шулаймыни? Димәк, бергә ятачаксыз. Ә син ни атлы буласың соң? Исемең?

— Исемем икәү минем. Башта Жаншет идем. Хәзер — Нияз.

Сәгать-сәгать ярымлап көткәннән соң, урын бушады. Җиденче палатаның түрдәге караваты. Ардуанны каталкадан анда күчерү шактый кыен булды. Улым сул аягына бармак белән дә кагылдырмый. Әрнидер инде. Аптырагач, җәймәсе белән күтәреп салдык. Салып сулыш алырга да өлгермәдек, шәфкать туташы — чәчләре чаларган өлкән яшьтәге бер апа — каталка белән шалтыр-шолтыр тагын кереп җитте.

— Нуриев, операциягә! — диде ул.

Ардуанны караваттан янә каталкага күчердек. Аның «ой, ой» дигән әрнүле тавышы йөрәккә тиеп алды.

Носилканы дөбер-шатыр алып чыгып китте әлеге апа. Аллага тапшырдык. Тик аның малайны алып чыгып китүе кая да, кире әйләнеп керүе кая. Операцияне ясамаска булганнар.

— Яшь организм. Таз сөяге үзе ялганачак ул, — диде табиб.

Палатага тагын бер матрас алып керделәр. Аны тыгызлап төрделәр. Ардуанның аякларын күтәртеп шул матраска куйдылар. Бер ай буена менә шулай селкенмичә ятарга тиеш икән бу бичара.

* * *

Җиденче палата. Зур тәрәзәле, диварларының аскы өлеше караңгы яшел белән зәңгәр кушылган буяуга буялган бер бүлмә. Биш караватта — биш малай. Иң түрдәгесендә — тәрәзә буенда — биш яшьлек Ярослав. Ул этисе белән уйнаганда муенын имгәткән. Ардуанга каршы яктагы стена буенда муенын чана шуганда авырттырган Азат ята. Хәер, сез аларны ята дип уйлыйсызмы? Палатаны, коридорны бер итеп чатыр чаба алар. Бүлнис халкы да, шәфкать туташлары да бу самими карашлы, сөйкемле малайларны ярата, үз итә кебек тоелды миңа.

Ә менә Ардуанның баш очында яткан малайның исеме Гадел икән. Ул да улым кебек 7–8 яшьләр тирәсендә булыр. Машина көпчәге астында калган. Ишегалдында өстеннән «Газель» чыгып, сул аягын тез түбән чәрдәкләгән. Монда шул аякны кыйпылчыклардан җыеп улакка салганнар да карават башына тарттырып куйганнар. Өченче атнасын инде, ни уңга, ни сулга борыла алмыйча, аягы тышауланган килеш ята икән мескен бала. Бик нык тартылган, суырылган. Аның очлаеп чыккан ияге, тырпайган колаклары, борынындагы чекерәйгән сирәк-мирәк сипкелләре, эчкә баткан зәңгәр күзләре, нечкә муенында һәм агарынып калган йөзендәге тармакланып киткән зәңгәрсу-соры тамырлары кызгану хисе уята. Әнисе туң йөрәкле, каты

бәгырьле хатын, ахры. Шул шыр сөяккә калган малайны гел кагып-сугып тора. Юк, карап-карап торам да, күңелгә бер дә ошамый әле бу хатын. Палатадагыларның барысын да үз кубызына биетмәкче. Төшке аштан соң: «Тихий час! Барыгызга да йокларга!» — дип әмер биреп ята, субакы. Үзе улы янына түнде. Гадел исә, җилкәләрен куырып, стенага сыланды. Күр әле, нишли бит, ә! Үз өендәмени. Күрсәтергә иде сиңа әлчеңне!

Палатада телевизор да бар. Азатның әтисе өеннән алып килеп куйган. Сәгать алтылар тирәсендә «Эфир»ны кабыздык. «Перехват» программасыннан Ардуанны да күрсәттеләр. «Малай иртән мәктәпкә барганда бик ашыккан. Юлны чыкканда уңга-сулга карамаган. Нәтиҗәдә машина астына эләккән», — дип бирделәр. Нинди юл икән соң ул? Берниндн юл чыгасы юк иде бит аңа? Шулай баш ватып утырганда, палата ишеген шакыдылар. Урта яшьләрдәге бер ханым: «Бүген машина бәрдергән малайның ни хәле бар икән дип керүем иде, — диде. — Безнең стройка янында булды бит ул хәл. Инвалидлар өчен төзелә торган йорт янында. Без шунда идек. Монда ирем янына килдем дә, тукта, минәйтәм, кереп чыгыйм әле. Атнакич шушы бүлнис дежурит итә бит. Аны да монда салган булырга тиешләр, минәйтәм».

— Нинди машина бәрдерде аны?

— «Жигули». Ак төстә.

— Ничек бәрдерде соң?

— Без килгәндә, шофер малайны күтәргән дә нишләтергә белми әрле-бирле йөренә иде. Ай-яй курыкты инде ул үзе дә. Аннары ГАИ килде, «скорый» килде.

— Нишләп юлга чыкты икән соң ул, шайтан малай?

— Тротуар пычрак бит. Үтеп булмый. Шуңа күрә машина юлына чыгып, шуннан үтәләр.

Хатын килгәч, мин өйгә кайтып киттем. Кайтышлый, әлеге төзелешкә сугылдым. Төзелеш димәсәң, хәтере калыр, аның коймасы да юк икән бит. Шуңа бөтен урамны пычраткан инде ул. Кая анда тротуар?! Аны археологлар килеп казысалар да табарлык түгел. Бөтен тирә-як тездән саз. Монда машина юлына чыкмый хәлең юк. Тиздән ул юл да балчыкка күмеләчәк. Пычрак аның да уртасына кадәр җәелгән.

* * *

12 нче бүлнисең травматология бүлегенә килеп керсәң, бөтен кеше имгәнеп беткән икән дип уйларсың. Палаталарны әйтмим дә инде, коридорда да буш урын юк. Авыруларга сәлам биреп, җиденче палатага таба барыш.

Бер абзый туктатты:

— Син улыңа әйт әле, нишләп операциядән курка ул. Әйт әле, курыкмасын. Менә мин ясаттым. Курыкмадым. Кулбашымның бер тамыры өзелгән булган. Дачада кар көрәгәндә катырак селтәнеп җибәргәнием. Әйт әле, әйт яме, операциядән курыкмасын. Теге Юан әйбәт ясый икән ул.

Бу абзыйны кайда күргәнем бар соң? Йөзе таныш. Бәй, төнәген без палатада урын бушаганын көтеп утырганда аны операциягә алып кереп киттеләр бит. Кан качкан иде аның йөзеннән. Ә бүген, күрәсезме, Берлинны алган кебек йөри. Операциягә алып кергәндә улымны ярты юлда боруларын үзенчә аңлаган инде бу.

Мин дә аңа табибларның кире уйлауларын әйтеп тормадым инде.

* * *

Төш вакыты җитте. Ардуанга утырырга ярамый. Яткан килеш ашатасы. Ике кашык шулпаны матур гына шудырдым. Тик өченче кашыкның яртысы авызына эләкмәде, иягеннән агып төшеп муенына китте. Улымның йөзе сытылды, иреннәре кысылды, күзләре дымланды. Башын стенага таба борды ул. Дүртенче кашыкны, күпме генә кыстасаң да, капмаячак иде инде.

Нервыланып яткан улыма күз көеге булмыйм әле дип, читкәрәк китеп утырдым. Азат белән Ярослав вак-вак шакмаклардан нәрсәдер төзеп әвәрә киләләр. Гаделнең әнисе кроссворд чишә.

Улы аңа баядан бирле нидер әйтмәкче:
— Әни, әни, дим...
— Комачаулама!..
— Әни, тыңлап тор инде. Бүген мин төштә әтине күрдем.
— Йә, шуннан...
— Бүген әти килмәс микән?..
— Каян белим мин. Башымны катырма.

Ниязның исә эшләр хутта. Муенчагына гер асып, шуны башы-ияге белән күтәреп ятарга тиеш булган бу малай аркасын стенага терәгән, аякларын бөкләп куйган да рәхәтләнеп китап укый. Аңа карап-карап торам да уйлап куям: «Йа Ходa, Нияз кебек тә укып була икән бу дөньяда китапны. Малайның күзен очландырып, йотылырдай булып утыруы бер хәл. Әле сез аның авызыннан чыккан авазларны ишетсәгез: ах, уф, һай, хи-хи-хи-хи, ха-ха-ха, ой, ба-а-а, во... Ул әсәрнең геройлары белән утка керә, суга сикерә, карурманнар чыга, чүлләр кичә, борчыла, сөенә, яна, көя, сугыша, җиңелә, кабат сугыша, җиңә, үлә, терелә, тагын үлә, тагын терелә... Күр әле, малайның маңгаеннан тир бәреп чыкты, аркасыннан пар күтәрелгән кебек булды. Нияз китапны ябып күкрәгенә кысты да моңсу күзләрен бер ноктага төбәп уйга калды. Байтак шулай йомылып утыргач, ул торып үзенә ашарга әзерләү хәстәренә кереште. Малай бүлнис ашларын ашамый икән. Ул аларны теге усал хатынга биреп бара. Аңа өстенә кайнар су салгач өч минутта пешеп чыга торган вермишель булсын. Малай су кайнатып, ыгы-зыгы килеп йөргән арада сорап куйдым:
— Китап укырга яратасың, ахры?
— Бик яратам, үлеп яратам.
— Нәрсә яратасың соң? Юмормы, фантастикамы?
— Барысын да.
— Шигырьне дәме?
— Обожаю.

Туктале, минәйтәм, әдәбиятка мөкиббән бу малай үзе дә кулына каләм алып кәгазь тырнаштыргаламый микән?..

— Бәлки әле, үзең дә шигырь язасыңдыр, шагыйрь Зөлфәт әйтмешли, «Такташ калыбына дыңгычлап».

Нияз беравык миңа гаҗәпләнеп карап торды, аның бит алмалары кыңгыр эш өстендә тотылган малайныкыдай кызарып чыкты. Аннары яныма килеп, колакка пышылдады ул:

— Абый, сез минем шигырь язганны каян белдегез? Әйе, язгалыйм мин. Кешегә генә күрсәтмим. Бер классташ кызга күрсәтеп караган идем, көлде генә.

Шул вакыт палатага буе уртачадан бераз калкурак булган, сызылып киткән кара кашлы, почык борынлы чибәр генә хатын килеп керде.

— О-о-о!.. Әни килде. Әнием!.. — Нияз йөгереп килеп аны кочаклап алды. — Әнием! Әйдә әле, мин сине күтәрим әле.

— Кит әле моннан, кит! Кеше көлдермә. Так, син нишләп караватыңда түгел? Нишләп ятмыйсың?

Нияз тиз генә караватына сузылып ятты һәм, керләнгән муенчагына гер асып, үзен арканлап та куйды. Макарон онытылды. Әнисе киткәнче селкенәсе түгел, менә шулай кымшанмыйча, сабыр гына ятасы икән аңа.

Күренеп тора: малай әнисе белән бер күрешеп сөйләшүне тансыклаган. Ул аннан әтисен, өй хәлләрен сораштыра. Тик әнисенең ачылырга әллә ни исәбе юк. Әңгәмә ялганып китә алмый. Чибәр ханымның җаваплары бер-ике сүз белән чикләнә.

Нияз укыган китаплары турында сөйли башлагач, җай табып әйтеп куйдым:
— Сезнең улыгыз да шигырьләр яза икән...
— Хи, шигырь тагын аңа. Ул хәчтерүшкә.

Аның сүзләре Ниязның күңеленә төртеп алды, күрәсең.

— Алай димә, әни, язгалыйм мин, — диде ул һәм, әнисенең сүзләренә аз гына хәтере калды булса кирәк, башын диварга таба борды.

— И хәчтерүш. Кайчан язганың бар? Хәер, бер күрсәткән идең шул. Тик рәте-чираты юк иде ул шигыреңнең.

Ул арада «кунагыбыз» китәргә дә җыена башлады. Нияз: «Китмә инде, әни. Аз гына утыр инде», — дип ялваргач, тагын бераз юанырга булды. Малай гер асып көн буена ятарга да риза, тик әнисе генә янында булсын.

— Юк, улым, китим әле мин. Барасы җирләрем бар. Ә син торма, ят. Менә вермишельләрең. — Ханым барыбыз белән дә елмаеп хушлашты да җәт кенә чыгып та китте.

Ә бер-ике минуттан Нияз, арканнан ычкынган бозау кебек, коридорның бер башыннан икенче башына чаба иде инде.

*** * ***

Бүген төнлә бүлнистә Ардуанны саклаган хатыныма эшкә иртүк китәргә кирәк булып, мин улым янына иртәнге ашка ук барып җитәргә тиеш идем. ЮХИДИгә кереп-йөреп соңга калдым. Улымның мине көтә-көтә күзе күгәреп беткәндер инде. Ашыйсы-эчәсе килми микән? Кысталып ятмый микән? Шушы сораулар юл буена баш миен игәүләп барды. Йомышын кешегә әйтергә ояласын, читенсенәсен беләм бит инде.

Килсәм, Ардуан: «Мин ашадым инде, эти, чәй дә эчтем», — дип ята. Күңеле дә үсә башлаганга охшаган.

— Кем ашатты соң сине?

— Гаҗилә апа.

Адәм баласына күп кирәкмени, теге усал хатын дигәнемнең улы Гаделне ашатканда Ардуанга да өлеш чыгаруына күңелем булды. Ә мин, юләр, аңа сырт кабартмакчы булып йөрим тагын.

*** * ***

Бүген Ардуанны апасы карый. Төнгә дә ул калачак. Миңа килеп тормасам да була иде инде. Бала бит, эштән соң хәлен белеп кайтыйм дидем. Көндез бүлнискә ЮХИДИдән килгәннәр. Сорау алганнар. Ардуан: «Юлга чыкканда уңга борылып карадым, сулга карамадым», — дигән. Аның бу сүзләрен язып алганнар да апасыннан кул куйдырганнар. Шулай итеп, бөтен гаепне малайга чәпегәннәр. Югыйсә мине капитан: «Сездән башка беркемнән берни дә сорамаячакбыз», — дип ышандырган иде. Ярар инде, хәерлегә булсын. Улым исәнме? Исән!

Ә кичен өйгә кайткач телевизорны кабызсам, экранда — Казан шәһәре эчке эшләр идарәсенең ЮХИДИ бүлеге башлыгы Ш.Юмаев. Турыдан-туры элемтә. Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына, ди. Тиз генә телефон трубкасын алып «Эфир»ны җыям. «Имәнлек урамында инвалидлар өчен йорт төзелә. Төзелешнең коймасы да юк. Шуңа күрә тирә-юне тездән пычрак. Янәшәдә ике мәктәп. Укырга баручы балалар машина юлына чыгып үтәргә мәҗбүр. Шушы көннәрдә монда 9 яшьлек бер малайны машина бәрдерде инде. Мондый фаҗига тагын кабатланмас дип кем ышандыра ала?!»

Хәлбуки минем сорау эфирда яңгырамады.

*** * ***

Бүлнискә килеп керүгә, улыма операциядән курыкмаска кушкан абзый каршы алды:

— Сине көтәләр анда. «Эфир»дан килделәр, «Эфир»дан! Улыңа әйт әле, операциядән курыкмасын!

Төнәген Юмаевка биргән сорау галәмәтедер инде бу. Малайны гына гаепле итеп калдырган телевидение дә үзенең хатасын төзәтергә җыена.

Ардуан интервью бирергә әзер. Урын-җире тәртиптә. Хатын иртүк эшкә киткән. Тагын Гаҗиләгә рәхмәт инде. Мендәрне кабартып, уңайлап куйган. Хәтта тышлыгын да алмаштырган. Малайга өр-яңа футболкасын табып алып киерткән.

— Ничек булды бу хәл? Сөйлә, Ардуан! — Хәбәрче кыз улыма юан микрофонын сузды.

— Юлга чыкканда уңга карадым, сулга карамадым. Һәм мине машина бәрдерде.

И шайтан малай. Тагын шулай сөйләп тора бит. Юк, бу юлы «Эфир»га мондый җавап кирәкми.

Ниһаять, тырыша торгач, Ардуаннан «Анда бик пычрак. Үтеп булмый» дигән сүзләрне әйттерә алдылар. Ә кичен чибәр Айгөл Мирзаянова «Город» программасын болай башлады: «9 яшьлек малай, Казанның Иманлек урамында инвалидлар өчен төзелә торган йорт яныннан үткәндә, шушы төзелеш аркасында үзе чүттән генә инвалид булмый калды...»

* * *

Вакыт дигәнең бүлнистә дә үтә тора. Аллага шөкер, улымның әрнү-сызланулары басыла төште. Альбом, карандашлар соратып алды. Яткан килеш рәсем ясый. Малай кеше нәрсә ясасын инде — солдатлар да кораблар. Нияз-Жаншет аның иҗатын читтән генә күзәтеп йөри. Үзе дә кулына каләм алып, нидер сызгаларга тотына. Шигырь яза икән. Берсен миңа да күрсәтте.

Әй, солдат, солдат,
Алып бир миңа бер ат!

— Йә, ничек?.. — Малай күзләрен миңа төбәде.

— Рифмасы бар. Тик мәгънәсе юк. Сиңа каян, нинди ат алып бирсен соң ул солдат? Акчасы юк аның. Үзе дә ачлы-туклы.

Нияз килеште. Баш какты. Менә тагын Ардуанның альбомына күз салды.

— О-о-о. «Титаник», — диде ул һәм, тумбочкасы янына утырып, тагын кәгазь-каләмгә ябышты.

Борыны очына тир бәреп чыкканда шигырь әзер иде инде:

Әй, «Титаник», «Титаник»,
Ерак бармыйк, тукталыйк...

— Монысында рифма да, мәгънә дә бар, — дидем мин, малайның башыннан сыйпап. — Гүя «Титаник»ның һәлакәткә дучар булачагын алдан сизәсең. Шуңа күрә кешеләрне кисәтәсең, уяу булырга чакырасың.

Шушы сүзләремнән соң малайның башы күккә тиде. Ул шигырен күтәреп коридорга очты. Аны тагын кемнәргәдер укытып кайтты бугай. Тик менә кире бүлмәгә кергәндә кәефе төшкән иде. Бактың исә, «операциядән курыкмый торган» абзый: «Иртә әле сиңа шигырь язарга. Шагыйрь булу өчен башта йә университетта, йә академиядә укырга кирәк», — дип, малайның бөтен уй-хыялларын челпәрәмә китергән.

Кешегә шигырь язу сәләтен Ходай гына бирә, минәйтәм. Нияз тагын яныма килә, күңелен үстерерлек өметле сүзләр көтеп, күзләрен миңа бага. Без аның белән коридорга, ишек катындагы буш кушеткага чыгып утырабыз.

— Нияз, — минәйтәм, — бәлки әле, Аллаһы Тәгалә үзе сиңа шагыйрь булырга кушкандыр. Хәтта псевдонимың бар. Жаншет. Бәлки әле, киләчәктә зур сәхнәләрдә мондый сүзләр яңгырар: «Сейчас прозвучат стихи великого татарского поэта Жаншета».

Шаяртып әйтәм, билгеле. Бернинди Жаншет, Манжетлар кирәкми. Нияз. Нинди матур исем бит инде!

Шагыйрь, зур сәхнәләр, дигәч, Нияз үзе дә «О-о-о!..» дип куйды.

— Беләсезме, абый? — Малай күзләрен тутырып карады һәм, сөйләргәме-сөйләмәскәме дигәндәй, пауза ясап торды: — Без Горкида ундүртенче катта яшибез. Безнең тәрәзәдән Идел күренә. Ә Иделнең теге ягында биек тау. Мин җәйге эссе көннәрдә лоджийга чыгам да тауга карап торам. Шунда бер чишмә бар. Әйе, әйе, мин аны өй тәрәзәсеннән үк күрәм. Ышанасызмы? Их, шул чишмәнең суын бер эчәсе иде. Менә шулай, кеше күрми торган нәрсәләрне күрәм мин. Беләсезме, тагын нәрсә күргәнем бар минем. Минем әби: «Кеше ышанмаслыкны чын булса да сөйләмә», — ди. Сезгә генә сөйлим, абый. — Нияз тагын миңа сынаулы караш ташлап беравык

карап торды. — Безнең ишегалдында бер эт яшәде. Аягы гарип иде аның. Үзе шундый матур. Борыны кара, үзе дә кара, тәпиләре генә ак. Ак итек кигән кебек. Без аңа оя ясадык. Өйдән ашарына ташып тордык. Мин әни бүлеп биргән ашны ашыйм, ә итен сиздерми генә кәгазьгә төрәм дә эткә алып чыгып бирәм. Ә беркөнне чыксам, ни күрим, этебез юлда кан эчендә ята. Машина таптап киткән. Үзе шабыр тир булган. Көч-хәл белән сулый. Күзләре ачык. Мин аны нишләтергә дә белмим. Бер-ике тапкыр тирән итеп сулады да кулымда үлде мескен. И жәлләдем дә инде. Мин шул вакыт аның гәүдәсе өстендә ниндидер томан кисәге эленеп торганын күрдем. Шушы этнең җаны булган бит ул, абый, име.

— Булмас димә... Кеше җанын үлчәп тә карадылар түгелме соң инде...

— Кешенең җаны да күренәдер шул, име, абый. Шоферны әйтәм. Шул аксак этне нигә таптатырга инде. Машинасының тормозлары бардыр бит. Юк, таптаткан да качкан. Җүнсез! Әле кичә генә бер китап укыдым. Бер утрау турында. Кечкенә генә бик матур утрау. Һәм менә шунда кешеләр дә бик матур яшиләр. Бер-берсеннән көлмиләр, бер-берсен рәнҗетмиләр, бер-берсенә матур сүзләр генә әйтәләр. Этләр, мәчеләр анда рәхәтләнеп йөри, кошлар да рәхәтләнеп оча. Утрауда закон бер генә: һәр көнне һәркем яхшылык эшләргә тиеш. Бездә дә шулай булсын иде. Их, минем дә шул утрауда яшисем килә.

«Ты, не дури!» — Колак төбендә яңгыраган һушыңны алырлык, таш ярырлык тавыштан икебез дә сискәнеп киттек. Бактың исә, Ниязның әтисе килгән икән. Ул да улы башына гер асып караватта ята дип уйлый бит инде. Ә Нияз бүген хәтта муенчагын да салып аткан. Тиз тапты аны тагын үзе. Җәт кенә киде дә герләрне асып та куйды. Әтисенең акыру-бакыруларын ул инде ятып тыңлый иде. Дөрес, озак ятарга туры килмәде үзенә. Әтисен ай күрде, кояш алды. Ул арада төшке аш вакыты җитте.

Аштан соң Гаҗиләнең кырыс тавышы яңгырады:

— Тихий час. Барыгызга да йокларга!

Минем сәгать дүрткә кадәр вакыт бар. Эшкә барып килергә кирәк. Баскычтан төшкәндә бер агай игътибарымны җәлеп итте. Дөресрәге, үзе түгел, кулындагы таягы. Күпме таяк күргән бар. Мондыйны күргән юк иде әле. Чәчәкле-чуклы таяк бу. Агай аны үзе ясаган. Һәр бизәген иренмичә юнып-чокып, күпме күз нурын түгеп утырган.

Тик сабы гына юанрак булган булуын. Бераз гына юкарткан тәкъдирдә кулга тагын да җайлырак булыр иде.

— Андый-мондый һөҗүм итә калсалар, саклану чарасы да бу, энем, — ди агай.

— Сиңа кем тисен инде, абзый!

— Алай димә — дөнья бу!.. И энекәш, 45 нче елны фронтка китеп бер фашистны да кыйный алмыйча кайттым мин. Үзем — десантник. Псков дивизиясендә хезмәт иттем. 170 прыжок минем чутта. Өйрәнүләрдән баш чыкмады. Кая гына атмадылар безне.

Урманга төшү бик хәтәр иде. Төнлә бит. Очлы чыршыга эләксәң, шампурга киертелгән ит инде син. Күпмесе шулай харап булды. Фашист өстенә төш идең ул. Төш тә тукма идең үзләрен. Юк, без сугышка соң алынгач, өлгерә алмый калдык шул. Кул кычытып калды. Аның каравы күрде безнең дә башлар. Сугыш беткәч тә җиде ел хезмәт иттем әле.

*** * ***

Бүген кич өйгә кайтканда әлеге дә баягы инвалидлар өчен төзелә торган йорт яныннан үттем. Бәй, төзелешнең коймасы пәйда булган. Тротуарны да, юлны да чистартканнар. Балчыгын кырганнар. Кулдан килерлек эш икән югыйсә. Шуның өчен бер гөнаһсыз малайны машина бәрдереп китүен көтеп ятарга кирәк булды микәнни? Шундый шул инде без: башка бәла килгәч кенә селкенә башлыйбыз.

Өйгә кайтып почта әрҗәсен ачсам, хат ята. Казан шәһәре эчке эшләр идарәсенең ЮХИДИ бүлеге начальнигы Юмаевтан. Хатны укыйм. «Җир казу эшләре кагыйдәләрен бозган өчен «Казанхимстрой»ның 2 нче төзү-монтаж идарәсе начальнигы И.Локмановка һәм «Гидроспецстрой» җитәкчесе А.Муравьевка дәгъва белдерелде». Тагын укыйм. «Татарстан Республикасы Президентының «Шәһәрләрдә һәм башка торак пунктларында төзекләндерү,

чисталык һәм тәртип саклау кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү турындагы Указының 11 нче маддәсен бозган өчен «Гидроспецстрой»ның участок начальнигы А.Соловьевка административ материал җибәрелде, шулай ук «Гидроспецстрой»ның баш инженеры В.Кругляк «наказать» (ничек «наказать» иткәннәр икән соң? Шелтә белдерелгәнме, штраф чәпегәннәрме, әллә бу — күзгә төтен җибәрү генәме?) ителде».

Бу төзелешнең нигә коймасы булмаганын аңладым хәзер. Начальниклар күп. Түрәләр күп. Ә чын хуҗа кем соң монда? Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала? Эзләп кара хәзер гаепле кешене! Эт — эткә, эт — койрыкка. Бездә шулай инде: чиновниклар күп, эшләүче юк. Ике хуҗага — бер ишәк.

Туктале, бу хат белән мавыгып китеп, онытып торам икән. Мин Гаделнең әтисенә шалтыратырга тиеш бит. «Әти, әти» дип өзгәләнә бит инде бичара малай, әнисен дә алҗытып бетерә. Көн туды исә, башында бер генә сорау: «Бүген әти килмәс микән?» Ай ярым вакыт узып киткән, әтисе ник бер күренсен. Малайны таптаткан шофер да бер күренгән дә юкка чыккан. Башка әтиләрнең уллары янына килеп йөрүен Гадел күрми дисезмени?! Аның да йөрәге өзгәләнми дисезмени?! Аптырагач Гаҗилә ханым менә шушы номерны бирде: «Бүлнистә телефон юк. Өйгә кайткач шалтырата алмассың микән. Әтисен әйтәм, бер килеп китсен иде инде». Каударлана-каударлана, Гаҗилә язып биргән саннарны җыям. Трубканы, тавышына караганда өлкән яшьтә булса кирәк, бер карчык алды.

— Исәнмесез! Сезгә шалтыратуымның сәбәбе шул: минем улым белән оныгыгыз Гадел 12 нче бүлнистә бер палатада яталар. Җиденчедә.

— Сезгә нәрсә кирәк?

— Мин дөрес эләкмәдем, ахры. — Үзем җыйган саннарны кабатладым. — Сезнең номерыгыз шушымы соң?

— Әйе.

— Сез Гаделнең дәү әнисе буласыздыр ич.

— Шуннан...

— Сезнең оныгыгыз бүлнистә ята. Аның әтисен күрәсе килә.

— Әнисе котыртып ятамы?! Бездә әнисенең бер әйберсе дә юк.

— Юк, ул сездән әйбер сорамый. Ул Гаделне әтисе белән күрештерергә генә тели.

— Молодой человек! Тагын бер тапкыр әйтәм, аның монда бер әйбере дә юк.

— Юк, аңа бер әйбер дә кирәкми. Ул фәкать...

Сөйләшү шушы урында өзелде. Әңгәмәдәшем трубканы куйды.

Кәефем китте. Мин дә Гаделнең үзеге өзелгәнен күрмиммени?! Мин дә аның гаҗизләнеп авыр сулауларын, уфылдауларын ишетмиммени?! Минем дә аның әтисен бүлнискә, улы янына китертәсем килмимени?!

Аягым тартмый бүген бүлнискә. Килүгә Гаҗилә: «Шалтыраттыңмы?» — дип сораячак. «Әти киләме?» — дип, Гадел дә моңсу күзләрен миңа багачак. Ни дип җавап бирим соң? Ә мин барырга, төн буена улым янында булган кызымны алмаштырырга тиеш. Бүлниснең ишеге төбендә үк Нияз очрады. Чәтертән малай мине тәрәзәдән күргән дә каршыма йөгереп чыккан. Җитмәсә, ул да шул сорауны бирә:

— Гаделнең әтисенә шалтыраттыгызмы? Киләме? Килсә, мин сез палатага кереп җиткәнче аннан сөенче алам.

Их Нияз, Нияз! Синең дә Гаделне куандырасың киләдер шул инде. Күңелең һаман игелек эшләүдә. Ни дип әйтим соң? Айлар буена бүлниснең тынчу палатасында интегеп яткан Гаделнең һәм Гаҗилә ханымның күңелләрен җылытасы да килә. Шул ук вакытта аларны кысыр өмет белән яшәтүдән дә ни мәгънә?! Беравык аптырашта калып торганнан соң, Ниязга турысын әйттем:

— Кистереп вәгъдә бирүче булмады шул...

— Ә сез номерны дөрес җыйдыгызмы?

— Дөрес җыйдым кебек. Ах, Нияз, Нияз! Ничек чыга белдең әле каршыма? Әйбәт сорау бирдең. Мин дөрес җыйсам да, Гаҗиләнең дөрес язып бирмәве ихтималмы? Ихтимал!

Палатага керә-керешкә Гаҗиләгә үзем сорау бирдем:

— Син, дустым, телефонны дөрес язып бирмәгәнсең, ахры?..

Әйе, шулай дигән булам, гәрчә үзем кәгазь кисәгендәге ул саннарның дөреслегенә һич кенә дә шикләнмим.

— Дөрес, — диде Гаҗилә, ике дә уйламыйча, һәм иреннәрен кысып тын гына торганнан соң сорап куйды: — Трубканы каенана алдымы?

Мин дәшмәдем.

— Аңлашылды.

* * *

Обход вакытында без коридордагы кушеткага чыгып утырдык. Бу юлы Гаҗилә белән.

— Нишләп сез көне-төне монда ятасыз, — диде Гаҗилә һәм, нәрсәгәдер гаҗәпләнгәндәй, күзләрен зур итеп ачып миңа төбәде. — Сез бит — эш кешесе. Ә минем беркая да барасым юк. Ардуанны үзем карармын.

— Әйтүең өчен рәхмәт. Сине күпме интектерергә була.

И Гаҗилә, Гаҗилә... Үзе дә тәмам туйгандыр инде бу бүлнистән. Без әле улымны хет чиратлашып карыйбыз. Әнисе, апасы, мин. Туганнар көн саен диярлек хәлне белешеп тора. Авылдан әни килеп оныгы янында бер тәүлек утырды. Улымны бәрдергән шофер да кереп йөри. Гаҗилә көне-төне берүзе. Аның да өенә кайтып, юынып, йомшак иркен түшәктә ял итәсе киләдер бит инде. Сабыр, нык хатын икән. Улы белән җәфа чигүләре җитмәгән, Ардуанны да үз канаты астына алмакчы була бит әле.

— Син үзең, Гаҗилә, өеңә кайтып берәр көн ял итеп кил. Мондагысын без үзебез җайларбыз, көйләрбез.

— И-и-и, кая кайтыйм соң мин... Киров урамындагы тугыз квадрат метрлы бер бүлмәдә торабыз инде без. Анысы да бер белгән хатынныкы. Йортны бүген-иртәгә сүтәргә тиешләр. Кешеләр яңа фатирга күченә. Ә безгә юк инде. Прописка булмагач. Каенана үзләренә яздырмады. Дүрт бүлмәледә малае белән икесе генә яшәсәләр дә. Йортка килен булып төшкән көненнән үк, фатирны бүлеп алырга килдең, дип, үзәк бәгырьләремә үтте. Прописка турында авызымны да ачканым булмады югыйсә. Ә улы — әнисе малае. Аның бер сүзеннән чыкмый. Авызына гына карап тора. Каенана белән бер елга якын этле-мәчеле яшәгәннән соң, имчәк баламны күтәреп чыгып киттем. Берни сорамадым. Әле ярый әнә шул бүлмәсен биреп торган иптәш хатын булышты. Горшокка кадәр алып бирде. Әтисе баштарак килгәләп йөрде. Хәзер эзе суынды. Гаделне машина таптаганын белгәч, бөтенләй югалды. Үзем эшләп торганда очын очка ялгап бара идек әле. Пароховойда эшләдем. Кыскарттылар. Цехыбыз белән киттек. Базарга чыгарга мәҗбүр булдым. Кульяулыктыр, оектыр-черттыр сатып тордым. Ялланып инде. Көнгә 30 сум бирәләр. Ярап тора иде әле үзе. Бу чурт побери малай болай булып куйды да, менә хәзер анысы да юк инде. Пароховойда хет больничный барыр иде.

Ярый әле авылда энекәш бар. Берүзе яши. Әти-әни — мәрхүмнәр. Шул энекәш сыер, сарыклар асрый. Тавык-чебеше дә байтак. Ел буена безне иттән өзми. Бәрәңге дә шуннан. Эремчеккә кадәр ясый. Өйләндерәсе иде үзен. Пеләшләнеп бетте инде, башында ике бөртек чәче калды. Ә менә башлы-күзле булу турында уйламый да. Хәер, кемгә өйләнсен соң ул?! Һәр ике өйнең берсендә буйдак. Безнең авылда гына да утызны узган утыз ир-ат бар, ди. Беркөнне авыл советы персидәтеле 29 ны санаган. «Утыз дигәннәр иде, берсе кайда соң?» — дип баш кашый икән. Баксаң, үзен санамаган.

Кызларны әйтәм, берсе дә авылга чыгарга атлыгып тормый. Хәер, чыгып нишләсен соң ул анда?! Ни эше, ни акчасы. Колхозның сарыклары бетте. Сыерлары кысыр. Алары да бетүгә таба бугай. Пред кирәк-яракка дигән булып машинасына сала да чыгып китә, сала да чыгып китә, ди. Сыер алып киткәндә рульгә үзе утыра. Сыерсыз киткәндә шоферын ала. Үзең мал асрамасаң, колхозныкын көтеп ятсаң, ачка үләсең. Үлүен үлмәссең анысы, һичьюгы бәрәңге ашап та торырга була. Тормыш булгач өс-башы да кирәк бит. Ә колхоз акчаны елга ике генә бирә. Сабантуйга — 100 сум, көзен Колхозчылар көненә — 300 сум. Халык яши үзе. Ә минем авылга һич кенә дә күңелем тартмый. Җаным бизеп, гайрәтем чигеп киттем аннан. Өч ел этине карадык. Каты

авырды. Авыруы теге «өч хәреф» инде. Ул үлә дип торганда, әни үлеп китте. Йөрәк белән. Әнидән соң да әти ел ярым ятты әле. Өйләребез, каралты-кура да бик начар калды. Энекәш сиплэтергә дип йөри йөрүен. Әлеге дә баягы шул акчасы юк инде.

Бу арада энекәш тә килә алмый. Бүген-иртәгә чәчүгә чыгарга торалар. Ярар, эшләсеннәр, салып кына йөрмәсеннәр. Соңгы вакытта чирткәли башлады. Эчсә дә, малларны карый үзе. Хи-и-и, кем эчми соң анда? Тик менә теләсә нәрсә эчәләр. Шунысы куркыта. Агуланып үлүчеләр дә булды инде.

* * *

Көннәрдән бер көнне палатабызның ишеге (ул көн буена ачык) төбенә, коридорга бер карават куеп, 45 яшьләр чамасындарак бер хатынны салдылар. Аның уң кулын бинт белән урый-урый тәпәч иткәннәр. Нияз вермишель өчен суга чыгып кергән иде. Белеп кергән: бу хатын кулын эшендә станокка кыстырган икән.

И бу тормыш... Балалар, оныклар кочарга, аларның чәч-башларыннан сыпырып торырга яратылган куллар станок рычагларына ябышырга, кувалдалар тотарга, шпаллар күтәрергә мәҗбүр.

Ә менә бу яшь хатын монда ничек килеп эләккән? Палатасында ятмый. Коридор буйлап әле бер башка, әле икенче башка тыз-быз йөреп тора. Чибәр, каһәр. Сызылып киткән нечкә каш, күккә чөелгән почык борын, янып торган күзләр. Озын куе керфекләре гүя күзләрдәге әнә шул очкын-ялкынны читкә-миткә әллә ни чәчрәтмичә саклар өчен яратылган. Күр әле син аны, күкрәген киереп, кәс-кәс атлап ни рәвешле йөри бит.

Чибәркәй — Утлыкүз — беркем белән дә сөйләшми, аралашмый. Үзенә сүз катсалар да, колак артыннан шудырып җибәрә. Аның турында беркем берни белми. Төп-төзек бу хатынның травматология бүлегендә йөрүе беренче карашка гаҗәп тә. Кыйнаганнар икән, тәнендә ушиб икән дигән имеш-мимешләр бар барын. Шайтан белсен. Ара-тирә йөзен сытып бөер турыларын сыйпаштыргалап ала ул үзе.

Хикмәти Хода, бүлниснең һавасын, мохитен үзгәртеп җибәрде бит әле бу Утлыкүз. Яралары төзәлә, хәле азмы-күпме арулана баручыларның һәм, әлбәттә, авыру карап утыручы ир-атның тынычлыгын алды. Ыңгырашулар, «ах-вах» килүләр кимеде. Хәзер ир-егетләрнең аягына баса алганы коридорга чыгарга тырыша. Утлыкүз бер болайга үтә, бер — тегеләйгә. Палатасына да керсә, шул «тихий час»та гына керә. Үзенә төбәлгән күз-карашлардан дәва, ләззәт ала бугай ул. Әйдә, йөрсенсәнә. Аңа карап мөкиббән киткән ир-ат халкына да сүз әйтмәгез. Матурлыкка карап соклануның ни гаебе бар?! Кайбер авыруларга әрнү-сызлануларын онытырып тору өчен бүлнисләрдә махсус чибәркәйләр штаты булдырсаң да ярар иде әле ул. Үлем-китем дә кимер иде. Әнә Казаннан фронтовик журналист Нәгыйм Мөхибуллинның сөйләгәне бар. Госпитальдә үлем түшәгендә ята икән. Беркөнне ул бөтенләй начарлана. Ә монда тәртип шундый: өзелер алдыннан шәфкать туташлары авыруны ваннага алып кереп юалар. Нәгыйм агага да чират җитә. Аны алып чыгып киткәндә, палатадашлары: «Татарину пора к Мухаммеду», — дип калалар. «Бермәлне күземне ачсам, — ди фронтовик, — каршымда чибәр кыз тирләп-пешеп мине юа. Аның матур гәүдәсенә, җилкәсенә агып төшкән сары чәчләренә, зәңгәр күзләренә карыйм. Үләсе килми генә бит. Юк, үлмәдем. Менә ярты гасырдан артык вакыт узды инде. Әле һаман яшим».

* * *

Соңгы бер-ике көндә коридорда тыз-быз йөрүчеләр күбәеп китте. Барысы да типсә-тимер өздәрдәй егетләр. Һәркайсы бүлнис киеменнән. Нинди җилләр ташлаган соң аларны монда? Монда бәла-казага дучар булып имгәнгән өтек-сөтек кешеләрне генә салалар түгелме соң? Көчен кая куярга белмәгән бу егетләрнең монда ятуы, һәрхәлдә, сәер, бик сәер. Теге «операцияне ошаткан» абзый аларга «диагноз»ны бик тиз куйды. Армиядән качып, чирлегә сабышып керәләр алар монда, диде ул, ике дә уйламыйча.

Гөнаһысына кермим, кемдә нинди чир булмас. Тик менә аларның моңарчы тыныч кына, ипле генә барган бүлнис тормышында бер кирәкмәгәнгә ыгы-зыгы тудырып, үз хәлен үзе генә белгән,

әрнү-газапларга тешен кысып, сабыр булырга тырышып яткан авыруларның саруын кайнатып йөрүләре генә ошамый. Коридор буйлап урык-сурык йөрүләренә дә түзәр идең әле. Аш өләшкәндә чиратсыз керәләр бит. Кулсыз, аяксызлар алдына керәләр. Әстәгъфирулла. Сары ыштанлы, камыл кебек каты чәчлесе бигрәк оятсыз.

Шунысы беркөнне теге десантник абзыйга болай дип әйтеп тора:

— Синең урының, старый, зиратта инде. Хет үзеңә кабер урыны алып куйдыңмы соң әле?

— Зираттан урынны күптән алып куйган идем инде мин, энем. Тик менә синең кебек япь-яшь егетләр миңа анда да комачаулыйлар. Урынны алып куюым гына була, алар минем урынга керәләр дә яталар, керәләр дә яталар.

* * *

...Бүлнистә режим шундый: кичке уннан соң коридорда да, палаталарда да ут сүндерелә. Йокларга! Ай ошамый да инде мондый тәртип теге әзмәверләргә. Яшь кан. Җегәр бар. Эш юк. Энергияне кая куярга белмиләр. Хәер, режим сиңа ошыймы-ошамыймы, килешергә мәҗбүрсең. Бүлнис бу. Шәфкать туташларының бер-ике тапкыр кырыс кисәтүеннән соң тегеләр ятарга мәҗбүр.

Бүген дә «отбой»дан соң тынлык урнашты. Тынлык дип инде, монда авыруларның ыңгырашулары, әрнүле-газаплы авазлары, «ай-вай»лар, «ах-ух»лар беркайчан да тынып тормый. Минем ятар урын юк. Коридорга палата ишеге төбендәге кушеткага чыгып утырдым. Кушетка бүген буш. Кайбер төннәрне анысы да эләкми. Аякларны бөкләп чүмәштем. Өстемә пәлтәмне япкан сыман иттем. Йомышы төшсә, Ардуан үзе дәшә. Мин көн буена эштә бит. Арылган, күрәсең. Чүт кенә авышып башны төрткән идем — йоклап киткәнмен.

Күпме черем иткәнмендер. Уяндым. Мин генә түгел, бөтенесе уянды. Кемдер бүлнисне яңгыратып укшый-коса. Күрше палатада ятучы бер абзый икән. Интегеп, газапланып укшый. Нинди генә тавышлар чыкмый үзеннән. Кизү торучы табиб, шәфкать туташлары чатыр чаба. Аларның ашыгу-кабалануларына, бер-берсенә өзек-өтек җөмләләр белән кызу-кызу дәшүләренә караганда, авыруның хәле шәптән түгел. Коридорның теге башында торган каталканы да җәһәт кенә алып килделәр. Абзыйны шуңа салып җәһәт кенә алып чыгып та киттеләр. Кая? Нәрсәгә? Абзыйга ни булган? Бераздан, колактан-колакка күчеп, бөтен палаталарны, коридорны бер сүз кисеп үтте: йөрәк!..

Йокы качты. Барыбызның да уенда әлеге абзый. Үз палатасына исән-имин әйләнеп кайта алырмы ул? Ни дисәң дә, йөрәк уен-муен түгел.

Теге хөрәсәннәргә генә йөрәк ни дә, өрәк ни. Әлеге ыгы-зыгы аларга ошады гына. Көндез йокларга, төнлә йөрергә күнеккәннәр, күрәсең. Тартырга гына ничә тапкыр чыгып керделәр. Ат азгыны тайга ияргән, ди. Утлыкүз дә алардан калмый.

Ярты сәгать чамасы узгач, күпне күргән каталка коридорда тагын пәйда булды. Шөкер Ходайга, абзый исән. Үзен палатасына алып кереп салдылар. Шәфкать туташының аңа әйткән: «Борчылмагыз. Тыныч кына ятыгыз. Йокларга тырышып карагыз», — дигән сүзләре ишетелде.

Утлар тагын сүндерелде. Шәфкать туташының: «Марш караватларыгызга!» — дип бер-ике тапкыр кистереп әйтүеннән соң, тегеләр дә барып яттылар.

Тагын тынлык. М.Мәһдиев әйтмешли, йоклагыз, адәм балалары! Авырулар, сезгә йокы бик кирәк. Табиблар, шәфкать туташлары! Кешене үлем тырнагыннан алып калдыгыз. Афәрин! Инде сезгә дә ял итеп алырга ярыйдыр. Иртәгә дә көн буена эшлисегез бар.

Бүлнис тынды. «Мес-мес», «пуф-пуф», «гыр-гыр»лар гына ишетелә.

Чү!

Үзәк өзгеч тавыш. Шул ук палатада. Теге абзый җан ачысы белән кычкыра. Шәфкать туташлары бүлмәләреннән торпедо кебек атылып чыктылар. Чыктылар да теге абзый янына чаптылар. Чапкан шәпкә берочтан теге каталканы да эләктерделәр.

Тагын ыгы-зыгы.

Тагын мәхшәр...

Тагын теге егетләргә лафа. Тычканга үлем, мәчегә көлке кебегрәк инде.

Үле-мәле палатага килеп керсәләр... бая гына әҗәл белән якалашкан абзыебыз гырлап йоклап ята.

Кычкыручы — бөтенләй икенче кеше! Яше утызлар тирәсендә булган бер ир. Торып утырган. Күзләре — маңгайда. Маңгае — шабыр тир.

— Ни булды? — дип сорыйлар аннан.

Дәшми.

— Ник кычкырдыгыз?

— Ай... Уф-ф-ф... Төш күрдем. Куркыныч төш.

И Аллам!.. Ходай сабырлык бирсен сезгә, табиблар, табибәләр, шәфкать туташлары!

*** * ***

Бүген бүлнискә кереп барганда бер егет эндәште:

— Сез травматология бүлегенә түгелме?

— Әйе, нәкъ үзенә.

— Җиденче палатадан Миңлебаева Гаҗиләне чакыра алмассыз микән? Мине халатсыз кертмиләр.

— Тек, мин шул палатага керәм! Гаҗиләне? Әйтермен, әйтермен.

«Бәй, Гаделнең әтисе килгән түгелме соң? — дип уйлыйм баскычтан менгәндә, — Гаҗиләнең энесе түгелдер инде. Аны пеләш диде бит апасы. Тәгаен Гаделнең әтисе бу». Кичә Гаҗилә: «Тагын бер шалтыратып кара инде», — дигәч, өйгә кайтуга чыктым. Трубканы тагын каенана алды. Бу юлы да сөйләшү ялан кул белән билчән йолыккан кебегрәк булды. Каенананың үз туксаны туксан, һаман бер сүзне тукый: «Аның монда бер әйбере дә юк». Шулай да сөйләшү юкка булмаган. Менә малаен җибәргән бит. Алай ук имансыз түгел икән әле.

— Гаҗилә, синең ирең килгән, ахрысы. Аста көтә, — дидем палатага керә-керешкә.

Гаҗилә минем халатны эләктерде дә чыгып чапты. Ах бу Гаделне! Әрекмән колак. Минем сүзләрне ул да ишетеп алган. Аның «Ур-р-р-а! Әти килде. Әти!» дигән сүзләре палатаны гына түгел, бөтен бүлнисне яңгыраткандыр. Малай сөенеченнән нишләргә дә белмәде. Ул шулкадәр шатланды ки, айлар буена хәрәкәтсез яткан караватка тарттырып куелган аягы тышауларны ычкындырып-җимереп атты.

«Сөен әйдә, сөен, сабый. Мондый бәхет тансык сиңа», — дип уйлыйм эчтән генә. Гаделнең сөенгәнен күргәч, үзебезнең дә күңелләр эреде. Баланы кызганудан гына түгел, аның шатланганын күрүдән дә күзгә яшьләр килә икән. Кеп-кечкенәдән михнәт-сынауларга дучар ителгән бер гөнаһсыз бала бит ул.

Ул арада Гаҗилә дә менеп җитте.

Чү...

Аның сытылган чыраен, уйга баткан күзләрен күреп, аптырашта калдык. Халатның да кирәге чыкмаган.

— Ни булган, Гаҗилә?

— Миңа срочно китәргә кирәк. Авылга. Энекәш авыр хәлдә. Гаделгә күз-колак булып торыгыз инде.

— Гадел өчен борчылма. Карарбыз!

Әнисе китүгә, моңарчы сабыр-тыныч яткан Гадел безне утлы табага бастырды. Аның: «Аягым, аягым. Авырта. Үләм», — дип кычкырулары йөрәккә кадалды. Табибларны чакырдык. Алар нишләтеп кенә карамадылар ул аякны. Бушаттылар, тарттырдылар. Тагын бушатып, тагын тарттырдылар. Аптырагач, укол кадамакчы булдылар. Гадел кадаттырмады, теше-тырнагы белән каршы торды.

Ак халатлы абыйлар, апалар!

Юкка мәшәкатьләнәсез бит сез. Авыртмый аның аягы. Чәрдәкләнгән булса да, сынык булса да авыртмый. Күңеле сынык аның. Күңеле әрнегәнгә түзә алмыйча елый ул. Күңелен сындырганнарга нәфрәтен белдерә.

Мине дә гафу ит, Гадел. Әтиең килгән дип ышандым бит. Чын күңелемнән ышандым. Ышанасым килде.

Гаҗилә дүртенче көнне кичкә генә килеп җитте. Арыган, алҗыган, тартылган. Күз кабаклары кызарган, шешенгән.

— Энекәшне җирләп килдем.

Күңелебез алдан сизенсә дә, таштай катып калдык.

* * *

Бүлнис һавасыннан, бүлнис мохитеннән тәмам туеп, эч пошып йөргән көннәребезнең берсендә Нияз палатага тычкан артыннан чапкан мәче кебек атылып килеп керде:

— Чыгыгыз әле, чыгыгыз тизрәк, бернәрсә күрсәтәм. — Малай һөмай кошы тотканмыни, борын тишекләре киңәйгән, зур, якты күзләре акайган.

Бүлниснең дүрт яктагы дүрт салкын диварыннан гайре әйбер күрмәгән халкын Ниязның тәкъдиме ымсындырып, алгысытып куйды. Дәррәү кузгалдык. Бу бәхеттән мәхрүм булган Гадел белән Ардуан артыбыздан каерыла-каерыла, тилмереп карап калдылар.

Күңеле ярсулы ашкыну, җилкенү белән тулган Нияз күрше палатадагыларны да куптарды. Барыбыз да Жаншетка иярдек. Теге әзмәверләр дә иярде. Малай вәгъдә иткән кызыктан алар каламыни. Десантник абзый гына калды, чөнки таягын икенче каттан кемгәдер күрсәтергә алып торганнар.

Белмим инде, бүлнис бит бу, шулай шаккатарлык нинди хикмәт булырга мөмкин икән монда?

Нияз безне коридорның теге башына ук алып китте. Син, шайтан малай, туп-туры операция залына алып барасың түгелме соң?! Шөкер, анда кермәдек. Малай барыбызны да баскычка алып чыкты. Монда урам як дивар тоташ пыяладан гына тора. Бөтен җирдә — кояш. Нияз безне әнә шул урамга караган пыяла дивар каршына тезеп куйды.

— Карагыз әле урамга. Урамга карагыз!

— Карыйбыз. Йә, шуннан?..

— Күрмисезмени?!

Бик матур көн. Күк чалт аяз... Өйләр, бакчалар, агачлар, коймалар, койма баганасы башындагы җирән мәче, апрельнең юмарт кояшы җылысына талып, яз җырын, җир җырын тыңлыйлар.

Кемдер Нияздан сорап куйды:

— Багана башындагы теге мәчене күрсәтмәкче буласың мәллә? Эт-мәчене күргән бар ла.

— Әйбәтләп карагыз!

Бер әби мәтәлә-кадала каядыр чаба. Аны күрсәтергә алып чыкмады бит инде безне Нияз, чөнки ул кортка әле генә пәйда булды. Әнисе янәшәсендә бер сабый бара. Әле яңа тәпи йөри башлаган, күрәсең, тырышып, хасиятләнеп атлый. Өстендә — алагаем калын комбинезон. Нәкъ космонавт инде. Чү, күз тидердек бугай үзенә — егылды. Егылгач, кулларын як-якка шундый матур итеп җәеп ятты ки, гүя Җир шарын кочаклап ятамыни. И сабый! Тик Ниязның нәни «космонавт»ка да исе китмәде.

— Нүҗәли күрмисез?

— Юк, күрмибез.

— Үлән чыккан бит. Үлән! Күрмисезмени?!

— Ниткән үлән күрәсең син анда? Койма буйларында әле кар эреп бетмәгән.

Кызык-тамаша карарга дип өметләнеп чыккан халык Ниязны эттән алып иткә салды. Теге хөрәсәннәр аеруча тузынды.

Зур күзләрен тутырып урамга баккан Нияз баскычта берүзе басып калды.

* * *

Бүген Гаделне чыгаралар. Кичә аның аягын «чылбырдан ычкындырдылар». Ычкындырдылар да «ташкапчыкка ябып куйдылар». Гипсладылар. Бер ай-ай ярымнан гипсын алдырырга тагын киләчәк.

Их, менә ул бәхет. Хәзер уңга-сулга борылып ятарга була. Утырып торырга, бер аякта басып торырга була. Хәер, басып торырга иртәрәктер әле — башы әйләнә.

Бәхетнең иң зурысы исә — Гадел бүген өенә кайтачак. Пропискасы булмаса да, Киров урамындагы 9 квадрат метрлы бүлмә аның өчен барыбер өй бит инде.

Табиб белешмәләре, кирәкле кәгазь-мәгазьләр әзер. Урын-җир тапшырылган. Нияз коридорның теге башында торган колясканы палатага ук алып кереп куйды. Гаделне шуңа утыртып алып чыгачакбыз. Тик менә машина гына никтер килеп җитә алмый. Шофер уникегә килеп җитәргә вәгъдә биргән иде. Сәгать икенче китте бит инде. Төенчек өстендә көтеп утырабыз. Безнең көтеп утыру нәрсә ул?! Гадел нишләргә белми. Ике айга якын сабыр гына яткан малайның бу минутларда тәкате тәмам төкәнде. Безгә минут саен урамга карарга куша. И Гадел, Гадел, язмыш бүлнистән чыкканда да сыный бит сине. Хәерлегә булсын!

Машинаны урамга чыгып тотудан башка чара юк.

— 30 сумга алып кайтырлар бит инде, име, — диде Гаҗилә.

— Акчасы өчен борчылма. Җайларбыз. — Өстемә куртка740 элдем дә урамга чаптым.

Машинаны бүлнис тирәсеннән эзләү — файдасыз. Монда барысының да үз кайгысы. Соцгородтан шәһәр үзәгенә бара торган олы юлга чыктым. Көньяк кешесенә охшаган кара-чутыр бер адәм туктады.

— Рубль, — ди.

Безнеңчә 100 сум була инде. Күп сорый, билгеле. Гаҗилә кебекләр бу акчаны алыр өчен өч көн иртәдән кичкә кадәр базарда басып торырга мәҗбүр. 100 сумына да риза булыр идең аның, бүлнистән аягы имгәнгән бер малайны алып чыгарга кирәклеген белгәч, шофер 150 гә менде.

— Сабыйның бәлагә дучар булуыннан акча эшләмиләр. Хәерле юл!

Икенче машинаны туктатам. Шоферы гади генә егеткә охшаган. Авылдан-мазардан түгел микән. Хәлне аңлатам.

— Күпме сорыйсың?

— Күпме дип инде, абый... Бер тиен дә алмыйм. Барыбер шул якка барам ич инде мин. Күптән түгел генә үземнең малай кулын сындырып шул бүлнистә ятып чыкты. Урамда бер малай белән басып торалар икән, күрше йорттан мужик чыккан да боларны сугышырга котырткан. Олы тиле. Ә теге малай минекеннән ике яшькә зуррак.

Бүлнискә килсәк, машинаны урамга ук чыгып көтеп торалар иде инде. Гаделне озатырга бөтен палата чыккан (Ардуан гына чыгалмый). Әнә бер төркем булып киләләр. Иң алда, Гадел утырган колясканы этеп, Нияз бара.

Машинага Гаҗилә сөенде. Иң сөенгәне, әлбәттә, Гадел иде. Алар машина чаттан борылып күздән югалганчы безгә кул болгап бардылар.

Хуш, Гадел!

Хуш, Гаҗилә!

Язмыш!.. Гаҗиләне дә әнә гел сынап кына тора. Улының ул аягы белән ниләр булып бетәсен дә Алла гына беләдер. Гарип кала күрмәсен иде инде, бичаракай.

Түз, Гаҗилә!

Сиңа тормышның карасын-пычрагын байтак күрергә туры килгән. Пычрак дигәннән, минем әти колхозда инженер-механик иде. Эштән кайтканда кулы еш кына мазутка-майга баткан була. Ул нишли, кулын ишегалдындагы балчык белән ышкый. Бүген безнең дә тормышның шул карасында, дөньяның шул пычрагында күңелләребезне юасы, җаннарыбызны чайкыйсы бар!

* * *

Нишләп әле бу Нияз коридор буйлап чатыр чабып йөрүләрен туктатты, нишләп әле әбиләр яткан уң яктагы палата ишеге төбендә генә чуала башлады дисәм, әһә, хикмәте бар икән. Без бүлнис — эш, бүлнис — өй арасында матавыкланып йөргәндә бер әбине чыгарганнар да аның

урынына 7–8 яшьләр тирәсендәге бер кызны салганнар. Гипсланган кулын муенына аскан түп-түгәрәк йөзле, бөдрәләнеп торган көрәнсу-саргылт чәчле бу кыз баштарак әллә ни күзгә-башка чалынмады. Әллә инде палатадагы эчпошыргыч бертөрлелек туйдыра башлады, әллә инде Ниязның алар ишеге төбендә еш пәйда булуы ымсындырып куйды үзен, соңгы вакытта Бөдрәчәч коридорга чыккалый башлады. Үткән-сүткәндә безнең палатага күз салып үтә. Нияз хәзер вермишель пешергәндә ишекне ябып тора. Шулай читтән генә күзәтеп-өйрәнеп йөри торгач, көннәрдән бер көнне бу Бөдрәчәч малайлар палатасына якынрак килеп карап торды. Иртәгесен йөрәксенеп ишек яңагына ук терәлеп баскан иде. Күзе күбрәк Ниязда. Күренеп тора, үзе ояла, ятсына-читенсенә. Нияз да сер бирми, кызга игътибар итмәгән була. Йә китап укый шунда, йә нишли. Үзе, безгә бик сиздермәскә тырышып, ара-тирә ишек ягына күз салып ала. Карашлары очрашканда икесе дә кызарып чыгалар. Бер-ике көн кызарып йөри торгач, Нияз миннән читенсенеп кенә сорап куйды: «Кудрявый татарча ничек була ул?» Минем җавапны ишеткәч, малай уйга калды. «Әһә, — дип уйлап куям эчтән генә, — өр-яңа шигырь туарга тора түгелме соң?»

Малайлар үзләре генә калгач, ниһаять, Бөдрәчәч кунакка кергән. Мине күргәч, Нияз караваты янындагы урындыктан җәлт кенә сикереп торды ул. «Утыр, утыр, — минәйтәм, — хәзер чыгып китәм, врачлар бүлмәсенә барып киләсем бар», — дигән булам. Кыз кыяр-кыймас кына утырды. Икесенең дә кулында китаплар. Нияз укыган әсәрләреннән алган тәэсирләре белән уртаклашкан, күрәсең. Минем алда алар мәчеләр турында сөйләшә башладылар. Пакеттагы әйберләрне бушаткан арада колакка чалынып киткән саран җөмләләреннән шуны искәрдем: малай да, кыз да мәчеләрне үлеп яраталар. Тик икесенең дә өйләрендә песи тотарга рөхсәт юк. Бөдрәчәч — аның исеме Элина икән — әбисенең өендәге мәчесе турында сөйли. Бу песи шулкадәр матур, йомшак, акыллы икән ки, аның турында сөйләгәндә Элина үзе дә сизмәстән кабынып, хисләнеп, дәртләнеп китте.

Мин дә палатадан чыгып югалып торырга өлгерә алмадым, мәче турындагы әңгәмә дә кырт өзелде.

Палатага атылып-бәрелеп Элинаның әнисе килеп керде:

— Кем кушты сиңа монда керергә?! Әллә ниткән хулиган малайлар янына кереп йөрисең. Марш бүлмәңә! — Ачуыннан шартлардай булган хатын күзен чайпалдырып Ниязга карап куйды һәм Элинаны җилтерәтеп алып чыгып та китте.

Палатаны авыр тынлык басты.

Шигырь тумас борын үлде.

* * *

Палатада Ардуан белән Нияз икесе генә калдылар. Азат белән Алеша да, сөякләрне урынына урнаштырып-тазартып, өйләренә кайтып киттеләр.

Улым аягына баса башлады. Тик менә ара-тирә башы чатнап, күз аллары караңгыланып китә аның. Хәзер үзен көне-төне саклап ятмыйбыз. Көнгә шул бер тапкыр хәлен белеп китәбез инде. Рәхмәт Ниязга, без югында Ардуанга тегене-моны алып килеп бирәсе булса, булышкалап тора. Артист Равил Шәрәфиев тә, монда дәваланып ятучы апасы янына килгәндә, бу палатага да сугылып, малайларның хәлләрен белешеп чыккалый. Ике малай бер палатада матур гына яшәп яталар. Ардуан рәсем ясый. Нияз йотылып китап укый, аз-маз кәгазь тырмаштыргалый, бөтен шартын китереп, хасиятләп вермишель пешерә. Мин килсәм, янымнан китми. Сөйләшеп утырырга ярата.

— Нияз, — минәйтәм, — «умыртка сөягеңнең беренчесе, икенчесе, дүртенчесе хөрест» дисең, өченчесе ничек «хөрест» булмаган соң аның?

— Белмим. — Нияз җилкәләрен куырып, башын чайкап ала. Башын чайкаганда чырае сытылып китүен искәрдем. Чана шуганда ясаган «сальто» үзен һаман сиздерә әле, күрәсең. Шагыйрь әйтмешли, әрни әле, әрни ул яра.

— Бу муенчагыңны юарга кирәк инде.

— Юган идем мин аны. Кичә тагын пычранды. Елаганда күзне сөрттем мин аның белән.

— Елаганда?! Нигә еладың соң әле син?
— Юк, еламадым.
— Елагансың, яшермә. Кем дә булса кыерсытты мәллә үзеңне?
— Юк, үземнең елыйсы килде.
— Нияз, әйт дөресен!..
— Нәрсә, миңа бер тапкыр еларга ярамый мәллә. Мин дә кеше бит. Тик торганда тоттым да еладым.
...Малайлар янында озак утырдым. Кичкә кырын гына киттем бүлнистән. Ардуан белән Ниязның мине һич кенә дә җибәрәселәре килмәде.
Кайтканда уйлап куйдым: нигә җибәрәселәре килмәде икән соң? Нигә алар бүген боек, кәефсез иде? Нияз нигә елады икән?
Нигә?

* * *

Самолет төзүчеләр шәһәрчеген узып, бүлнискә кереп барам. Күк тулы, кала тулы, җир тулы кояш. Кояш бер бинадан икенчесенә тыз-быз чабып йөрүче бүлнис персоналының ак халатларында, кулларындагы эмаль чәйнек, чиләк, кәстрүлләрендә. Абау... Хәтта морг тәрәзәсендә, морг диварларында да кояш. Мондый көндә аягына басарлык хәле булган кеше тынчу палатада ятамы?! Күбесе — ишегалдында. Станокка кулын кыстырган теге хатын да чыккан. Ул кулын нишләтергә белми, селкеп карый, күкрәгенә куеп торып карый. Тукта әле, миңа таба килә, миңа дәшә түгелме ул:
— Сез җиденче палатада яткан малайның әтисе бит.
— Әйе. — Үзем хатынның яралы кулына карыйм, ул бинт белән чорный-чорный утын пүләне хәтле булса да, кан барыбер тибеп чыккан. — Әйе, Ардуан атлысының әтисе булам.
— Беләсезме нәрсә? Аларны кичә кыйнадылар.
— Кыйнадылар?! Ничек инде кыйнадылар?..
— Әйе, кыйнадылар.
Мин берни аңламыйм. Кайда диген — бүлнистә, кемне диген — бәлагә дучар булып имгәнгән ярты-йорты балаларны кыйнап буламы?
— Кемнәр кыйнады?
— Күрше палатада яшь егетләр ята. Шулар.
Әһә, аңладым. Теге шакаллар. Бөтен гәүдәм травматология бүлегенә атылды. Аяклар баскычка әллә тия, әллә юк. Туп-туры тегеләр палатасына бәреп кердем. Керсәм, палатада өлкән яшьтәге ике абзый гына ята. Калган караватлар буш.
— Кайда бу кабахәтләр?
— Аларны бүген иртән «выписывать» иттеләр.
Гадәттә, бүлнистән чыгасы кешене «обход»тан соң төш турыларында гына чыгаралар. Табиблар кара тавыш чыгасын сизгән, тегеләрне иртән-иртүк олактырганнар.
Нияз белән Ардуан коридордагы һәм күрше палатадагы авыруларның сөйләгәннәреннән кичәге хәлләрне күзалларга була.
Ардуан белән Нияз икесе генә калгач, кичләрен теге бәдбәхетләр җиденче палатага ияләшеп китә. Ишекне ябып куялар да, малайларның канын катырып, кәрт сугалар. Өстәлнең түрендә — Утлыкүз.
Икенче көнне дә кереп кәрт сугалар һәм... Ниязга «үлән» күрсәтәләр. Син безгә күрсәттең, хәзер без сиңа күрсәтәбез ул үләнне, бәйрәм ашы — кара-каршы, имеш. Малайны, ике кул белән башыннан кысып, өскә күтәрәләр. Болай да муенын көч-хәл белән борган Нияз авыртуга түзә алмыйча елый. Шыпырт кына елый. Тегеләр дә шыпырт кына чыгып тая.
Кичә алар монда үзләрен хуҗа кебек тоталар. «Отбой»дан соң шәфкать туташы куып чыгаргач та, әле йокларга ятмыйлар. Утлар сүндерелгәч, коридор тәмам тынып калгач, ач күселәр кебек, шыпан-шыпан тагын кереп тулалар. Шалт та шолт. Өстәл өстенә тагын карталар куна башлый. Тамак кипсә, малайларның тумбочкасы өстендә тәмле су. Аны эчәләр. «Миңа да калдырыгыз», —

ди Ардуан. «Калдырабыз, калдырабыз, әле өстәп тә куябыз», — ди сары ыштанлы Арышбаш һәм малайның төнгә дигән суына лач итеп төкерә.

Баштарак коридор һәм күрше палатадагы авыруларга комачауламый, зыян салмый гына утырсалар, тора-бара бу явызлар үзләрен бәйдән ычкынган этләр кебек хис итә башлыйлар. Ниязның: «Суга төкерергә ярамый», — дигән сүзләренә үч итеп, тагын үлән күрсәтмәкче булалар «Тимәгез аңа!» — дип кычкыра Ардуан. «Ә сиңа хәзер йолдыз күрсәтәбез», — ди бая суга төкергәне һәм бүлниснең киезләнеп беткән каты мендәре белән бар көченә Ардуанның башына суга. Кая сугасын беләләр — авырткан җиргә. Өстәл янында дәшми-нитми тын гына утырган Утлыкүз ошбу «тамаша»дан татлы ләззәт кичерә. Тегеләр исә чибәркәйнең күңелен күрә алуларына шатланып туя алмыйлар, нишләргә белмиләр.

Балаларның әче тавышына палатага беренче булып «станокчы» хатын атылып керә. Керә дә Ардуанга тагын сугарга дип мендәрен өскә күтәргән «йолдыз күрсәтүче»нең сыңар кул белән бугазына ябыша. Көтелмәгән һөҗүмнән теге каушап кала. Утлыкүз мыштым гына юкка чыга. Ул арада кизү торучы шәфкать туташлары йөгереп килеп җитә. Коридордагылар куба. Равил Шәрәфиевнең апасы күтәрелә. Тегеләр аңа, башыңа каплыйбыз, дип, өстәл өстендә торган кайнар чәйнек белән киләләр. Апабыз курыккандыр дисезме? Куркытырсың, бар. Бергәләп явызларның иманнарын кияләр. Десант та, таягын тотып, нәкъ вакытында, нәкъ урынында пәйда була. Таяк эшкә җигелә.

Өченче көн Ниязның нигә елавын да, кичә малайларның мине ни өчен җибәрәсе килмәүләрен дә аңладым хәзер. Их, элек без булмаганда да Гаҗилә була торган иде бит бу палатада. Аның «Тихий час! Барыгызга да йокларга!» дигән сүзләрен сагынып куйдым.

...Сәгатькә карыйм, бәй, эшкә кайтырга вакыт. Бирәсе әйберләрне биреп, аласын алып, малайларны тынычландырып кузгалдым. Коридордан үткәндә күрәм: яңа йөзләр, яңа авырулар. И Ходаем, бәла агач башыннан йөрми, кеше башыннан йөри шул. Диварга сөялеп торган егетнең үз кайгысы. Хатыны аягын сындырып ята икән. Шуның хәлен белергә килгән. Кеп-кечкенә ике баласын да иярткән. Үзе ләх исерек, аягында чүт басып тора, үзе сукрана. Табиблар балаларын алып калганнар. Десантнигыбыз да, таягы белән тук-тук килеп, тартырга чыгып бара.

— Дөрес әйткәнсез сез. Таягыгызның кирәге чыккан бит. Тик кундыргач-кундыргач, нишләп башларына кундырмадыгыз ул кансызларның.

— Зираттагы урын жалкы, энекәш.

Коридорны үтеп ишекне ачам дигәндә, колакка таныш сүзләр чалынып китте: «Операциядән курыкмагыз. Курыкмагыз сез операциядән!» Абзыебыз авыруларга киңәш бирүен дәвам иттерә.

Ул арада мине күреп алды:

— Карале, сиңа бер сирьюзный сүзем бар. Улыңның хәле ничек?

— Әйбәт.

— Их, тәки ясаттырмады шул операцияне. Курыкты. Әйт әле, курыкмасын әле.

Тышка чыгуга кояш нурларыннан күзләрем чагылды. Башны аска иеп барам. Үләм-бетәм, ни күрим — үлән! Юк, кичә-бүген генә борын төрткән үлән түгел бу. Урамда әле апрель генә булуга карамастан, хәйран гына калкып өлгергән. Ялтырап торган яшел нәфис кыяклар, бер-берсенә чат ябышып, җил искәндә җиргә елышып, язның тыгыз, җылы һавасын мес-мес сулап, үсәргә, яшәргә тырышалар. Яшәүләре исә үләнгә дә җиңел түгел. Апрель җылы, хәтта эссе килде. Әйтүләренә караганда, май салкын булмагае. Алда — сука суыклары, шомырт салкыннары. Аларына түзәргә була. Тик менә юл кырыендагы бу үләннәрне дә машиналар таптап китмәсен иде инде.

Яшә, яшел ямь!

Ә син, Нияз, безне гафу ит. Без бит берни күрмибез. Сукырлар без. Дөресрәге, күзле бүкәннәр без.

Карашымны үләннәрдән алып бүлнис бинасына төбим. Тәрәзәдән Нияз карап тора. Башы иелгән, йөзе сагышлы.

**ХИКӘЯЛӘР**

# Балачакның күге биегрәк

## Матуркай

*Бу хикәяне әниемә багышлыйм*

Каз үстерү, каз симертү буенча иң оста булган ике хатынны беләм мин Кесмәс буенда. Аның берсе — минем әни, икенчесе — Нәкыя.

*М. Мәһдиев*

*(Сүз әдипнең сабакташы, минем әни, Арча районы Сеҗе авылында яшәүче, гомеренең 45 елын балаларга белем бирүгә багышлаган педагог Нәкыя Абдуллина турында бара. — В.Н.)*

Айгөл — Казан кызы. Һәр җәйне авылда дәү әнисе янында үткәрә. Авылда кызык. Анда сыер, сарыклар, тавыклар, песи һәм казлар бар. Казларны бигрәк ярата инде Айгөл. Һәр елны ул кайтышка бәбкәләр чыккан була. Аларны беренче тапкыр күргәндә Айгөлгә бер яшь тә өч ай гына иде әле. Дәү әнисе аны чирәмлеккә биби сакларга алып килде. Яшел келәмгә сибелгән сап-сары йомгакларны күргәч и-и-и сөенде инде сабый. Ул алардан сәгатьләр буена күзен ала алмады. Шул вакыт урман ягыннан кара, ямьсез болыт чыкты. Күңелне шомландырып давыл җиле исеп куйды. Бибиләрне өйгә алып кайтырга кирәк. Дәү әнисе, уң кулына Айгөлне күтәреп, сул кулына чүпрәк-чапрак бәйләгән таяк тотып, бәбкәләрне куа башлады. Тик үләнгә ябышкан бибиләрнең һич кенә дә кайтыр исәпләре юк. Ул арада каяндыр ике яшь тай килеп чыкты. Бер-берсен куышып йөргән бу тайлар томырылып бибиләр өстенә киләләр. И шунда курыкканнары Айгөлнең. Ул дәү әнисен кысып кочаклады. Ә гамьсез бәбкәләрнең тайларда да, давылда да эше юк. Үҗәтләнеп үлән йолкуларын беләләр. Һич кенә дә кубарып алалмассың. Дәү әнисенә Айгөлне тиз генә өйгә кайтарып, бибиләрне тутырырга әрҗә алып килми чара юк. Тик менә Айгөл өйдә үзе генә калырмы соң? Елар, акырыр бит инде. Юк, еламады кызчык. Өйгә кайтып керүгә дәү әнисен үзе куа башлады ул.

— Әббә, би-би, би-би, — дип, нәни куллары белән әбисен этәргә тотынды. Кеп-кечкенә сабый күңеленең бибиләр үзләре генә калганга борчылуы, аларга хәвеф янаганга эче пошуы йөзендә чагылып тора иде.

Ә икенче җәйдә Айгөл кайтканда бәбкәләрнең икесе генә чыккан иде. Казлар әлегә утыра. Шуңа күрә дәү әнисе бибиләрне өйдә тота. Айгөлгә тагын бер тамаша инде. Ул көннәр буена алар яныннан китә алмый. Бигрәк матурлар бит. Күзләре — шомырт, очы саргайган кара-кучкыл томшыклары ялтырап тора. Нәфис канатлары исә өрсәң очып китәр кебек. Ә тавышлары: «чи-пи-пи» дә «чи-пи-пи». Айгөл сарыкайларга кулын бирә. Тегеләр аның нәни нәфис бармакларын, уч төбен чукып кытыклыйлар. Бибиләр җырына нарасыйның кычкырып көлү авазлары кушыла.

Ә беркөнне дәү әнисе килеп керсә, Айгөл кулына әтисенең балачакта уйнап үскән атын тотып утыра, үзе елый-елый шешенеп беткән.

— Ни булды? Ник елыйсың, балакаем? — Әбисе оныгының башыннан сыйпап алды.

— Бел биби үлле. — Айгөл инде үкереп елый башлады.

Дәү әнисе әрҗәне ачып караса, чыннан да, бәбкәләрнең берсе тәгәрәп ята. Тиктормас бу бибинең кинәт кенә шулай булып куюы өйдәгеләрнең барысын да аптыраашта калдырды. Ни булды соң? Нәрсә ярамады? Үлеменең сере нидә?

Серне бер-ике көннән Айгөл үзе чиште:

— Их, жалкы ул биби. Атка утылып йөлелгә өйләнгәч кенә үлле.

9 яше тулган елны Айгөл бибиләрне үзе генә саклады. Бераз калыккач, су буена бәбкәләрнең үзләрен генә җибәрделәр. Һәм шул көнне үк бер биби кайтмады. Аны каян гына эзләмәделәр. Су буйлары, ындыр артлары, иске әвеслек тирәләре — берсе дә калмады. Юк биби. «Хәерле каза

булсын», — диде дәү әнисе. Инде утны сүндереп йокларга ятканнар иде — ишек шакыдылар. Арткы урамнан конюх Габдрахман абзый икән.

— Карале, Нәкыя, с-с-сезнең бер биби югалган дип ишеттем. Менә бу түгелме ул. С-с-сенаж чокырында ята иде. Аны тилгән талаган булса кирәк.

Каз бәбкәсен күргәч, Айгөлнең эче жу итеп куйды. Биби димәсәң, хәтере калыр, алар алдында бер күзе чукып алынган, бер канаты өзелгән, йоны коелган, сырты канаган, пычранып беткән ямьсез-котсыз бер җан иясе ята. Әйе, ята. Ул башын да күтәрә алмый, тәпиенә дә баса алмый. Әйе, әлеге табылдык Айгөлләрнеке иде. Сыңар канатындагы тамганы — зәңгәр буяуны шәйләп була. Их, мескен каз бәбкәсе! Нинди бәхетсезлеккә дучар булгансың бит. Бибине абзарга яптылар. «Таң атканчы тора алмас, үләр ул», — диде дәү әнисе.

Иртән йокыдан торуга, Айгөл лапаска чапты. Юк, үлмәгән әле каз бәбкәсе. Тавыш-тынсыз, сабыр гына соңгы сәгате сукканны көтеп ята. Алдына куелган табактагы суда да, суда изеп җебетелгән ипидә дә нәфесе юк. Хәер, җыяр ризыгы бетмәгән икән әле үзенең. Икенче көнне Айгөл бибинең суга сузылырга маташуын искәреп алды. «Эчәсең киләдер шул, матурым». — Кыз табакны якынрак китерде. Тик биби иелә алмый. Томшыгы да ачылмый. Аннары Айгөл яралы каз бәбкәсенең томшыгын иплэп кенә үзе ачты һәм уң кулының учы белән бер йотым су салды. Биби чыннан да сусаган. Тик күпме генә азапланса да, су бугазыннан үтмәде. Кире чыкты. Айгөл тагын салды суны. Бәбкә артка мәтәлде, шулай да суны азмы-күпме йота алды. Бераздан, интегә-интегә булса да, тагын бер-ике йотым капты. Әйе, кызганыч, бик кызганыч иде сыңар күзле, сыңар канатлы, ярым-йорты башлы, сырты канап, кутырланып беткән бу гарип каз бәбкәсе.

Айгөл бу көннәрдә абзардан чыкмады диярлек. Ике көн су гына йоткалап торган биби ипигә ымсынып караган күк булды. Кунак кыз да бик кыстагач, сөткә изелгән күмәчне капты. Кабуын капты, әмма бугазындагы сәер төер тагын ризыкның юлына аркылы төште. Айгөлнең Матуркае (кыз бибигә гел шулай дип эндәшә башлады) тончыкты. Башын чайкый-чайкый артка ауды. Янында кызчык булмаса, түшенә ничекләр әйләнеп ятар иде ул. Бибинең тәпиләре дә шулкадәр хәлсез ки, ул әле уңга, әле сулга авып-түнеп китә. Уңга ауганда ярый әле, үзен сыңар канаты белән этеп торгыза. Ә сулга ауганда эш харап. Айгөл кереп булышмаса, нишләмәк кирәк. Хәер, иртән торып абзарга кергәндә кызның үзенең дә хәле китә. Тез буыннары калтырый. Матуркай нихәл? Исән микән?

Ә нишләп караңгы тынчу абзарда ята соң әле ул? Тилгән тырнагы астында вәхшиләрчә ботарлануы җитмәгән, инде зинданда газап чигәме? Аның да көн яктысына чыгасы, кояшны күрәсе килмимени? Ишегалдына алып чыгарга кирәк үзен. Юк, тәкәббер әтәч белән әрсез тавыклар саруын кайнатып йөрмәсеннәр әле. Айгөл Матуркайны иплэп-җайлап кына күтәрде һәм өй каршындагы кура бакчасының тыныч-аулак почмагына кертеп урнаштырды. «Барыбер яши алмас ул, кызым. Бигрәк начар бит», — диде дәү әнисе.

Бакчага чыгарып куйгач, Матуркай тагын да начарланган кебек булды. Юк, җылы җирне, кайнар кояшны тансыклап өлгергән, күрәсең. Шуңа муенын сузып, үзенә күрә ләззәтләнеп яткан, ахры. Кичкә бераз рәтләнде.

Икенче көнне Айгөл бакчага чыкканда, «үлем түшәгендәге» биби кура куагы төбендә үскән үлән кыягын йолкырга маташа иде. И-и-и, үләндә нәфесе булгач, Айгөл аны бу сыйдан мәхрүм итәмени соң инде! Хәзер үк су буена төшеп бер кочак үлән йолкып менә ул сиңа, Матуркай.

Кыз яшел күчтәнәчне биби алдына тигез итеп таратып-түшәп салды. Аша, Матуркай, аша! Биби азмы-күпме чемченгәндәй итте. Ә менә Айгөл кулында ябышып калган бер яфракны чукып алып, шундук кабып йотты.

Айгөл чишмә янында үлән йолыкканда шуны искәрде: су буе тулы каз. Йөзәләр, чумалар, рәхәтләнәләр. Матуркайны алып төшеп карасаң, ни булыр икән?

Бу газаплар башлануга атна-ун көн дигәндә, әрнү-сызланулары әллә ни кимемәсә дә, Ходайның рәхмәте, бибинең күңеле үсә башлады.

Алар су буена төшеп киттеләр. Су буе! Ходай Тәгалә сине казлар өчен генә яраткандыр. Җәй. Эссе. Айгөл Матуркайны суның иң сай җиренә куйды.

Аллага шөкер. Су буена төшеп, инешчектән үзең иелеп су эчәсе көннәрең дә булган икән әле, Матуркай. Биби эчте. Бугазындагы төер дә хәзер әллә ни комачауламый. Эчте дә томшыгы белән су астындагы ком-ташны барлый башлады.

Отыры башы күтәрелде, күңеле хушланды, исән калган сыңар күзендә гамь уянды. Ул самими карашын инешне бөяп ясалган зур суга, аның ярларында үскән кәкре-бөкре талларга төбәде. Чишмә чылтыравын тыңлады.

Алар су буена көн саен төшә башладылар. Тиздән кыз бәбкәне зур суга җибәрде. Күр әле син, күр, ничә көн түш кыздырып яткан биби тавыш-тын чыгармый шыпырт кына суның уртасына шуып китте. Афәрин, Матуркай, болай булгач яшисең. Яшисең, Алла боерса. Ә берничә көннән ул инде чума, борыны белән суны шапырдата-чупырдата башлады.

Хәзер инде аны күтәрәсе дә юк. Үзе йөри. Айгөлгә ияреп су буена бара, кайта. Тау төшкәндә генә кыз бибине кулга ала. Һәр көнне сәгать 10–11ләр тирәсендә су буена сап-сары чәчле, кара күзле, почык борынлы бер матур кыз төшә. Аңа әүпән-тәүпән килеп кәкре-бөкре (тилгән сырт сөяген дә имгәткән булып чыкты) биби ияргән.

Хәвеф, бәла-каза бер килсә килә бит инде. Тилгән тырнагыннан да, үлем тырнагыннан да исән калып, тернәкләнеп-куанып йөргән көннәрнең берсендә Матуркай тагын бер һөҗүмгә дучар булды. Төш турыларында Айгөл тау башына чәчәк җыярга менеп киткән иде. Шул вакыт суга әвеслек ягыннан бер көтү каз төште. Бәй, болар Матуркайның әнкәсе, әткәсе, туганнары бит. Ялгыз бәбкә алар янына йөзеп килде: «Сәлам сезгә. Мин исән-сау бит, күрәсезме?!» Әмма казлар аны танымады. Алай гына түгел, шушы кыйшык-мыйшык каз бәбкәсенең алар суында йөзеп йөрүен һич кенә өнәмәделәр. «С-с-с-с» килеп һөҗүмгә ташландылар. Әүвәл аны мактаныша-мактаныша ярга кысрыкладылар һәм дәррәү чукый-талый башладылар. Таудан Айгөл йөгереп төшеп коткармаса, эш харап иде.

Матуркай тагын боегып калды. Сыртыннан тибеп чыккан бер-ике тамчы канны исәпкә алмаганда, туганнары әллә ни зыян сала алмады алуын. Әмма ул еламадымы? Аның йөрәге еламады дисезме? Тән ярасы төзәлә ул. Ә менә җан ярасына түзеп кара. Әткәң-әнкәң, туганнарың шулай хыянәт итсен әле. Хәер, нигә әле аларга үпкәләргә, өтек-сөтек бибине ничек танысыннар инде алар. Әйдә, танымасалар танымасыннарсана. Аның каравы тугрылыклы дусты, Айгөле янәшәсендә. Шул көннән башлап ул кыздан бер адым да калмас булды.

Җәйләр үтте. Матуркай тернәкләнде. Хәтта көрәя башлады. Ә Айгөлне Казанга алып киттеләр. Ул киткәч, Матуркайның тагын бер канатын каерып алдылармыни. Ашамас-эчмәс булды. Аптырагач, авылның аргы ягында яшәүче Хәнифә әбигә биреп җибәрделәр үзен. «Асрасаң — асрарсың, асрамасаң — үзең карарсың», — диде Айгөлнең әбисе. Ә беркөнне урамнан кычкырган каз тавышына уянып китте ул. Таң беленер-беленмәс кенә иде әле. Чыгып караса — Матуркай. Качып кайткан. Ничәмә-ничә урам үтәргә кирәк, ничек кайткандыр ул. Аны тагын озаттылар. Ул тагын кайтты. Бүтән беркая да җибәрмәделәр инде. Хәнифә әби үзе дә сорамады.

Карлыккан, дәртсез тавыш белән каз кычкыра. Көндез дә, төнлә дә кычкыра ул. Матуркай Айгөлне сагына. Ул үләннәрдән, су буйларыннан һәм, әлбәттә, кунак кызының шифалы кулларыннан тәненә дәва тапты. Ә менә сагынуга дәва югын белми шул инде ул, белми.

## Соңгы йөреш

Ул көнне Сеҗе балалары да, Мөрәленекеләр дә әче таңнан торып чыктылар. Автобус тукталышында түгәрәкләнделәр. Болар — Арчага район беренчелегенә үткәрелгән шахмат ярышына баручылар.

Авыл әле уянып кына килә. Морҗалардан чыккан горур төтен баганалары төн юрганын күтәргәннән-күтәрә бара. Яктыра. Тынлык. Лампочкалы багана төбендә әвәрә килгән урам этләре дә, төнге аудан биһуш булып кайтып килгән җирән мәче дә, аяк астындагы карның тансык шыгырдавы да бу тынлыкны боза алмый. Илаһи, серле, мәгънәле тынлык.

Таң ата.

Ак җиһанның пакь таңы!

Авыл гүя кар диңгезендәге бер утрау. Бераз арырак китеп аны әйләндереп алган урман гүя шул диңгезнең ярлары.

Мондый иртәләрдә юлга чыкканда күңел кыршауларын ычкындырасы, хисләрне уртаклашасы, кабынасы, яшисе килә.

Малайларның, кызларның очкынлы күзләре өлкән яшьтәге бер агайга төбәлгән. Абзыйның рәвеш-кыяфәт шәп: мәһабәт гәүдә, төз буй-сын, элеккеге мәшһүр артист, рәссам, язучылар йөрткән, почти зәһәр дип әйтерлек, карау һәм тәрбия күреп торган чал мыек. Аскысы эчкәрәк баткан, өскесе алгарак чыгып уйнап торган көчле иреннәр. Һәр сүзен уйлап, ашыкмыйча, ипләп-җайлап, сеңдереп әйтә. Балалар аны суламыйча тыңлый.

— Синең кәефләр ничек соң, Илнур? — дип сорап куя ул, бер малайның җилкәсенә кулын салып.

— Әйбәт!

Остазның бу шәкертенә игътибарны күбрәк бирүенең хикмәте бар. Илнур — бик хисле малай. Юкка-барга да борчыла, яна, көя. Җиңелүне күңеленә бик авыр ала. Үзбәк абыйны иң куркытканы — малайның йөрәге шәптән түгел. Әйе, балалар тренерының тормышы ярышлардан гына тормый. Аңа һәр шәкертнең сәламәтлеген дә, йөрәген дә кайгыртасы...

Абзый белән якыннанрак таныштырыйм әле үзегезне. Гомере буена туган авылы мәктәбендә балалар укыткан, сигез дистәне тутырып килүче Үзбәк Кәрим улы Яхин ул. Бүген шахмат ярышына баручы команданың остазы, тренеры. Инде күптән лаеклы ялда булса да, егерме елдан артык түгәрәк җитәкчесе буларак, ул балаларны шахмат уйнарга өйрәтә. Үзе дә дөньякүләм танылган шахматчы Рәшит Нәҗметдиновның шәкерте бит ул, уенның бөтен кагыйдәләрен үзләштергән бер дигән шахматчы. Хәер, шахматчы гынамы соң?! Ходай Тәгалә акыл-сәләт өләшкәндә капчыкны тутырып биргән Үзбәк агага. Нинди эшкә тотынса да, кулыннан гөл тама. Ул — бер дигән рәссам. Аның кулындагы кыл-каләмнән гаҗәеп картиналар туа. Казанда үткәрелгән күргәзмәдә дә катнашып, Татарстан Мәдәният министрлыгының дипломнарына лаек булды. Бактың исә, аның бу сәләте балачактан ук килә икән. Без Үзбәк аганың «Яшь ленинчы» гәзитендә басылган рәсемнәрен бертуган сеңлесе — язучы Гөлчәчәк ханым Галиева һәм аның ире — техник фәннәр докторы, академик Әхмәт ага Галиев белән карап утырдык. Узган гасырның 30 нчы елларында басылып чыккан бу рәсемнәрне кечкенә рәссам, альбом битләренә көнен-елын күрсәтеп, бик пөхтә ябыштырып барган. Беренче биттә — Сталин рәсеме. Шушы дәһшәтле елларда «халыклар атасы»н ясатырга әтисе ничек риза булгандыр? Болай да имам-хатип Бәдретдин угълы буларак һаман тырнак астыннан кер эзләргә торалар. Кәрим ага үзе дә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаган шәхес бит. Өстәвенә ике ел Казанның Күлбуе мәдрәсәсендә мөгаллим. Рәсемнең берәр кыегы булса, башың белән җавап бирергә тиешсең бит. Улының сәләтенә нык ышанган, күрәсең.

Еллар узу белән бераз саргая төшкән рәсемнәргә карыйсың да уйлап куясың, балалар кайчан да балалар шул. Ул чорда да алар үзләре ачлы-туклы булганнардыр инде — чана-чаңгы шуганнар, урманнарга барганнар, су кергәннәр, табигатьнең матурлыгы белән хозурланганнар. Рәсемнәр шулкадәр осталык белән ясалган ки, аларда бернинди артык сызык юк, һәрнәрсә үз урынында.

Бу альбом — үзе бер тарих. Анда Үзбәк Яхинның «Яшь ленинчы»да басылган мәкаләләре дә, редакциядән килгән хатлар да урын алган. Үзбәк ага хәбәрче буларак та каләменә гомере буена тугры калды. Район, республика гәзитләрендә килештереп язган матур-матур мәкаләләре басылып тора.

Үзбәк Кәрим улы нинди эшкә тотынса да булдыра. Мандолина, думбра кылларына да бик оста чиртә, кулы агач эшенә дә ябыша. Ул — бер дигән бакчачы, умартачы. Ходай биргән сәләтен гомере буена балалар белән уртаклашты. Мин үзем дә Укытучым, Остазым дәресләрен сагынып искә алам. Безнең күңелләр аның ярдәмендә сәнгать дигән бөек тылсымлы дөньяга орынды, Репин, Левитан, Шишкин, Урманче, Якупов, Фәттаховлар белән сөйләште.

Аның әтисе Кәрим Яхин да — үз заманында акыллы, зирәк мөгаллим, алай гына түгел, чын мәгънәсендә мәгърифәтче. Бөтен гомерен авылдашларына, шул исәптән балаларга гыйлем, тәрбия бирүгә багышлый. Шушы юлда сәламәтлеген җуя. Салкын көздә Казаннан авылга, мәктәпкә китаплар, күргәзмә әсбаплар алып кайтканда авырый башлый. Мөгаллимнең тәне яна, күз аллары караңгылана, хәле китә. Курса стансасында поездан төшә. Авылга тагын җиде чакрым җәяүләп кайтасы. Авыру кешегә бу араны үтү җиңелме?! Йөге дә бар бит әле. Аптырагач берәүләрдән бала арбасы алып тора. Китапларны, күргәзмә әсбапларны шуңа салып алып кайта. Кайтуга егыла. Бүтән тормый. Кәрим ага үпкәсенә салкын тидереп үлем түшәгенә яткан булып чыга. Ни кызганыч, үзенең фидакарь хезмәте өчен Кызыл байрак ордены белән бүләкләнүен дә ишетергә өлгермичә гүр иясе була.

...Тукта әле, сүзем балаларның Арчага шахмат ярышына барулары турында иде бит әле. Тукталышта сөйләшеп торганда Үзбәк ага да, балалар да ара-тирә юлга карап ала. Автобус күренмиме? Килә генә күрсен иде инде. Югыйсә эш харап. Харап булмый ни, елның елында чемпион булган команда ярышта күренмәсен әле?! Автобус аркасында килә алмаганнар дип уйламаслар. «Беткәннәр болар, шуңа күрә ярышка килергә дә курыктылар. Хәчтерүшләр», — дип әйтәчәкләр. Белмәсләр алар Үзбәк аганың 30–35 градус салкында күрше Мөрәле авылына үзе барып, клубның ачкычын үзе эзләп табып, үзе ачып, шахматчы балалар белән күнегүләр уздырып йөрүен.

Бер уйласаң, автобусның килми калуы да ихтимал бит. Юлда ни булмас?! Өлкән шахматчы шунысын да уйлап куя.

Тормыш үзе дә нәкъ шахмат уены бит ул. Йөрешләрдән, җиңү-җиңелүләрдән гыйбарәт. Бу хакта Үзбәк ага балаларга гел искәртеп тора. Менә бүген автобус килмәде ди. Сиңа каршы йөреш булды ди бу. Ә син аңа ничек җавап бирәсең. Запас вариант бармы? Бар! Ул вакытта 5 чакрымны җәяүләп булса да, стансага, поездга китәргә туры килә.

Үзе ул тормышта акыллы, мәгънәле йөрешләр генә ясарга тырышты. Хатыны Әлфия ханым белән бергә берсеннән-берсе чибәр, берсеннән-берсе уңган биш бала тәрбияләп үстерделәр. Икенче улы Айдар да әтисе юлыннан китте. Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлап, бер дигән рәссам булды.

Каян килә мондый сәләт? Үзбәк аганың Камилә әбисеннән түгел микән. Ул картиналар да ясаган, көмештән, тимердән менә дигән сәнгать әсәрләре тудырган, агач эшенә дә кулы ябышкан. Бу сәләт Үзбәк аганың сеңлесе Гөлчәчәк апаның улы Булатта да ярылып ята.

Хәлбуки язмышның ачы сынаулары, рәхимсез йөрешләре Үзбәк ага тормышында да булды. Армия, сугыш, умыртка сөяген имгәтү аркасында бер селкенмичә еллар буена гипста яту, аның картиналары куелган күргәзмә бинасында янгын чыгу, күпме хезмәтнең көлгә әверелүе... Боларга каршы Үзбәк Яхин бер генә йөреш белән җавап бирде — сабырлык. Фәкать сабырлык! Тормыштагы йөрешләр тактадагы фигураны шудыру гына түгел шул. Алар рәхимсез булырга, бәгыреңә тияргә, хәтта йөрәгеңә ук булып кадалырга мөмкин.

Шулай уйланып торганда, тау итәгеннән ут көлтәсе сузылды. Ул уңга-сулга, аска-өскә тибрәлә-чайкала алга бара.

Тренерның да, балаларның да эченә җылы йөгерде.

Килә!

Автобус килә!!!

Юлның сикертмәләрендә, чокыр-чакырларда чайкала-чайкала, автобус килеп тә җитте. Ишекнең пошт итеп ачылуы булды, халык ни арада автобус эченә агып кереп тулды. Автобуска кеше утырганда булып ала торган ыгы-зыгы әллә ни озакка бармады, пассажирлар кайсы кая урнашып бетте. Сумкалар, капчык-копчыклар, пакет-макетларның байтагы тез өстенә менеп кунаклады, байтагы идәнгә утыргыч астына посты.

Китәсе юл үргә каршы булганлыктан, машина авырлык белән, көчәнеп кузгалды. Аның артыннан авылның саф һавасына зәңгәр-кучкыл, тыгыз төтен бөркелеп калды. Бераз көчәнгәч, автобус хут алды, отыры бер көйгә генә чаба башлады.

Үзбәк ага тәрәзә буена утырды. Рәссамның исәбе күңеленең капкаларын табигатькә ачып куеп, кышкы таңның матурлыгын, җанга хозур күренешләрне карап-күзәтеп бару иде.

Хәзер инде борчыласы юк. Автобус килде, балалар утырды-урнашты. Илнур да үзенә җайлы гына урын эләктергән. Җан тыныч. Табигатьнең кабатланмас манзарасын күңел полотносына яз да бар. Әмма тренерга һәм шахматчы балаларга каршы йөреш автобусның үзендә көтеп торган икән. Кайбер йөрешләр йөрәккә ук булып кадалырга мөмкин, дигән идек. Менә шундый укларның берсе бүген автобуста атылды.

Бераздан кондукторның көр тавышы яңгырады:

— Тәк, балалар, билет алабыз.

Үзбәк ага сискәнеп китте, әсәренеп куйды:

— Бу балалар Арчага ярышка бара. Шахматчылар болар. Ярышларга, олимпиадаларга баручы укучылар юл өчен түләми. Хакимиятнең карары бар.

— Тәк, алайса, справкагызны күрсәтегез. Менә бу балалар ярышка бара дигән справкагызны.

Үзбәк ага кесәләрен актара башлады. Тукта, кайда соң әле ул справка? Юк. Бер кесәдә дә юк. Бар иде бит, алган иде бит ул аны. Справка да, башка документлар да өйдә онытылып калган. Кичтән барысын да әзерләп куйган иде югыйсә. Ветеран каушады. Төне бик борчулы булды шул аның. Остаз таң атканчы керфек какмады. Тәрәзәдән тәрәзәгә йөрде. Көн бозылмасмы? Буран чыкмасмы? Балалар уяна алырмы? Күрше авылныкылар җыенып килеп җитә алырмы? Автобуска соңга калмаслармы? Район чемпионы исемен быел да саклап калып булырмы?

— Справка өйдә калган бит, черт побери...

— Башыгыз калмаганмы?

— Баш та калган. Паспортта фоторәсемдәге баш минем баш бит инде ул. — Үзбәк ага киеренкелекне бераз гына булса да юмор белән йомшартмакчы булды.

— Тәк, справкагыз юк икән, юл хакын түлисез!

— Юк, сез бу балаларның ярышка баруына ышанасыздыр бит инде. Шахмат ярышына бара алар. Югыйсә таң тишегеннән торып чыкмаслар иде.

— Знать не знаю. Түлисез, бетте-китте.

Үзбәк аганың башында уйлар өермә булып кайный башлады. «Син — фронтовик. Илеңне яклап сугышка киткән кеше. Син — укытучы. Хакыйкатьне яклап яшәгән кеше. Син — рәссам. Матурлыкны яклап тезләнгән кеше. Бүген биш-алты бөртек баланы яклый алмыйсың. Күр әле бу кондукторны да. Бигрәк үҗәт. Акча, акча, дип дәһшәт чәчә, йөрәккә басып тора».

— Документлар дип, справка дип кире өйгә кайтып булмый бит инде хәзер. Аңлагыз инде мине.

— Аңламыйм да, аңларга теләмим дә. Ә син, абзый, үзең дә билет алмадың бит әле.

— Мин — фронтовик.

— Каян белим мин синең фронтовик икәнеңне? Маңгаеңа язылмаган.

«Нишләп язылмасын. Язылган шул. Маңгаема кыеклап тарап төшерелгән чәчләр арасында сугыш агарткан чәчләр юкмыни?! Маңгаемдагы җыерчыклар арасында сугыш сызганнары юкмыни?!» Үзбәк ага уйларыннан бүленергә, җанына тынычлык табарга теләп тәрәзәгә күз салды. Автобус тизлекне тагын да арттырды бугай. Юл буендагы ак бәс сарган агач-куаклар, электр баганалары выжт та выжт артка атылып калалар. Алар белән бергә ак кар астындагы курпы арасыннан баш сузган, шушы ак иртә күренешенә ятып бетмәгән әрсез әрем, котсыз шайтан таяклары да сикереп кала.

Кондукторның бөереннән чыккан тавышы рәссамны бу күренештән аерылырга мәҗбүр итте.

— Билет аласызмы сез, юкмы? Югыйсә хәзер автобусны туктатабыз, үзегезне төшереп калдырабыз. Башта үзеңә ал, абзый!

Үзбәк аганың йөрәге кысылып куйды. «Балаларны түгел, әллә үзеңне дә яклый алмыйсың инде син, ветеран», — дип эндәште аңа күңеле. Шахмат тактасындагы бөтен фигуралар дәррәү һөҗүмгә ташланган кебек тоелды. Ул отылган пешка хәлендә.

— Билет ал!

Үзбәк ага дәшмәде.

— Билет!!!

Кондуктор талпан кебек кадалды.

Киеренкелек тагын күпме дәвам иткән булыр иде икән. Ярый әле автобустагы авылдашлар дәррәү күтәрелеп чыкты:

— Сугыш ветераны бит ул, ник бәйләнәсез аңа?

— Гомере буена балалар укытты. Гадел, намуслы кеше.

— Ярышка баралар алар. Авыл данын, мәктәп данын якларга. Тимәгез аларга!

Шушы сүзләрне ишеткәч, кондуктор, ниһаять, тынычлангандай булды. Әмма ветеранның йөрәгенә кан сава башлаган иде инде. Отыры аның тыны кысыла, һава җитми башлады. «Автобусны туктатып, ишекне ачтырырга мәллә. Бераз һава керер иде» дип тә уйлаган иде. Күреп тора бит. Кешеләр ашыга. Кайсысы эшкә, кайсысы укуга. Машинаны туктаттырмады. Уңайсызланды. Сабыр гына түзеп утырды.

Арчага көч-хәл белән килеп җитте ул.

Стансадан район үзәгенә менәр өчен тагын автобуска утырасы. Монысыннан да гайрәте чигеп, җаны бизеп калган Үзбәк абый һәм балалар утырамы соң?! Җәяүләп менәргә булдылар. Җитмәсә, җиле дә каршы. Авыру йөрәккә тауга каршы, җилгә каршы бару җиңел дисезме?! Күпне күргән, байтак фаҗигаләрнең шаһиты булган текә Арча тавы бит әле ул.

Тын һаман кысыла. Күкрәк — таш. Маңгайга салкын тир бәреп тора.

Ничек кенә булса да, Үзбәк ага балаларны ярышка вакытында, исән-имин китереп җиткерде.

Ә үзе...

Йөрәк!..

Шул вакыт бер малай аның өстенә капланды. Ул идәндә чалкан яткан Үзбәк аганың күкрәгенә баса, аның авызына кайнар сулышын өрә башлады. Малай шулкадәр тырыша ки, аның маңгаеннан шабыр тир ага.

Остазына җан өрергә маташучы бу малай... Илнур иде.

Йөрәк!..

И син, йөрәк! Өзгәләнгән йөрәк!!! Телем-телем йөрәк!!!

Балаларның күз алдында…

Барысы да таштай катып калды.

Шул арада Үзбәк аганың Арчада яшәүче улы Айдар да килеп җитте. Ул да үзенең шәкертләре белән бүгенге ярышта катнашасы икән бит.

Ярышырга, көч сынашырга дип ашкынулы-ярсулы йөрәк, җилкенгән күңел белән кил дә җан биреп яткан газиз әткәңә тап бул инде.

Хәзер укучыларда ярыш кайгысымы?!

Шулай да шахмат тактасы янына утырырга үзләрендә көч тапты алар. Алай гына түгел, Үзбәк абыйлары үзләренә рәнҗеп китмәсен, аның рухы — ул шушында, ярыш үткәрелә торган залдадыр — сөенсен өчен җиңәргә, ничек кенә булса да җиңәргә сүз бирделәр.

Нәтиҗәдә, Сеҗе мәктәбе укучылары тагын район чемпионнары!

Ни кызганыч, бу шатлыкны уртаклашырга яннарында Укытучы, Остаз юк шул инде.

Юк шул...

## Кыйгак

Безнең балачак каз көтүе көтеп үтте. Әнә су буе — каз туе. Ул «кызыл тәпиләр»гә рәхәт. Көн буена коеналар, үлән ашыйлар, суны чупырдатып уйныйлар. Ә мин — постта. Тау башындагы арыш кырын саклыйм. Казлар басуга керсә — эш харап. Амбар мөдире Фәрт абыйның күзе очлы. Шунда ук килеп җитә дә казларны «кулга ала» һәм тәрәзәләре томаланган караңгы сарайга яба. И җәллим дә инде шунда эләккән казларны. Дөм караңгыда кичкә кадәр суга тилмереп, ачка интегеп ятарга мәҗбүр ул бичаракайлар. Ә кичен иреккә чыгарылган каз тәмам миңгерәгән була.

Аның күзе күрми. Ул кая барасын да белми. Авылны яңгыратып әле тегендә, әле монда адашып калган ялгыз каз кычкыра. Үзәкләр өзелә. Ә бер тапкыр минем аркада япты аларны Фәрт абый.

Безнең казлар ишле булып, мин көтү чиратына 5–6 көн рәттән чыгарга мәҗбүр. Соңгы көнне, күңелем ымсынып, елганың теге ягындагы болынга җир җиләге җыярга чыктым. Кып-кызыл, эре-эре җиләкләрдән аерылып буламыни. Мавыгып киткәнмен. Кояш кыздыра, эссегә чыдар хәл юк. Берочтан су коенып алдым. Казлар кычкырган тавышка сискәнеп башымны күтәрсәм, Фәрт абый эшкә керешкән. Чаптым. Аякларым җиргә әллә тия, әллә юк. Казларны коткарам, имеш. Ни ялындым, ни ялвардым Фәрт абыйга. Юк, тәки япты мескенкәйләрне. Сарай ишеген бикләгәндә, казларның тилмереп каңгылдаулары бәгырьне телгәләде. Бер-ике башак өчен... Нинди җәза!..

Хәзер инде авылда казлар ишле түгел. Бер ояда — бер-ике бәбкә. Нишләптер авылның «кулы китте». Болынны да сукаладылар. Елга да кипте. Теге сарай да җимерелде. Фәрт абый да юк. Тагын бик күп нәрсә юк авылда. Җыярга — җиләк, коенырга су юк. Минем кебек каз көтүче борынына-битенә мул итеп сипкел сибелгән почык борынлы малайлар да юк. Ә менә кайчандыр гөнаһсыз казларның тилмереп карауларына, ачыргаланып кычкыруларына савылып калган газиз йөрәк бар. Ул тибә...

## Ачуланма инде, Илһам!..

Авылда печән өсте бәйрәм кебек. Малайлар велосипедларына утыралар да урманга печән чабарга элдерәләр. Шулкадәр рәхәт ул иртәнге урман юлыннан велосипедта баруы! Чыклы үлән, җиләк исе, рульгә эленгән сумкадагы иртән генә савылган җылы сөт исе борынны кытыклый. Урманның борма-борма юлын әйт әле син!

Каеннар кочагыннан чыгасың да нарат арасына кереп югаласың.

«Их!» — Рәшит бүген велосипедлы малайларга кызыгып кына кала инде. Кичә үзенекенең көпчәген тишеп кайтты. Ямый да алмады — бик арыткан иде. Бүген дә вакыты юк. Уттай кызу печән өстендә көтү куганчы чыгып ычкынмасаң — көләрләр. «Йоклап калган», — дип уйларлар. «Велосипедны кемнән дә булса сорап торсаң гына инде. Хәер, мондый эш вакытында кем бирсен инде аны. Бирсә, бәлки, Илһам гына бирер. Ул бүген көтү чиратында».

Илһам, чыннан да, каршы килмәде. «Алып тор», — диде. Башка малайлар кебек: «Карап кына йөр! Вата күрмә!» — дип арттан сөйләнеп тә калмады.

Шулай итеп, Рәшит иртәнге урманның велосипедлы малайларга бирә торган рәхәтен, ләззәтен бүген дә тойды.

Ә кайтканда... Малайларның кайсыдыр: «Әйдәгез, авылга кадәр ярышып кайтабыз!» — дип кычкырды. (Кирәк бит!) Велосипедларның тизлеге шунда ук үзгәрде. Урман юлы өстендә тузан болыты күтәрелде. Рәшит бирешергә теләмәде — педальләргә бар көченә басты. Тик... Авылга кайтып җиткәндә генә велосипедның чылбыры ычкынды. Аны гына киертеп куеп була, билгеле. Урта күчәрнең подшипнигы ук таралганын күргәч, Рәшит аптырашта калды. «Нишләргә инде?! Кеше велосипеды бит!» — дип уйлады ул һәм авыл ягына күз салды. Ә малайлар инде таудан төшеп югалганнар иде. Барысының да җиңү теләге бик көчле булды бугай — ярышта катнашучылардан берсенең сафтан чыгуын бәрәү дә сизмәде.

Рәшит башта велосипедны төзәтмәкче булып карады. Ләкин кая ул төзәтү... Яңа подшипник кирәк. Малай башын аска иеп юл буендагы чирәмлеккә килеп утырды. Тик монда утырып та эш майтарып булмый. «Иң яхшысы — велосипедны Илһамнарның ишегалдына кертергә дә куярга. Аның ватык булуы турында әйтеп тормаска!» — дип уйлады ул. Һәм шулай эшләде дә.

* * *

Рәшит йоклый алмады ул төнне. Әле бер ягына әйләнде, әле икенчесенә... «Үзеңә яхшылык эшләгән кешене алдау булды бит инде бу». — Шушы уй аның башыннан бер генә минутка да чыкмады. — Дөресен әйтергә дә бик авыр. Илһам ачуланыр, үпкәләр».

Ул ишегалдына чыкты. Әнисенең уятуы да кирәк булмады бүген. Бик иртә булса да, тышта якты иде инде. «Әнә урман тавы. Бераздан анда тагын велосипедлы малайлар күренер. Ә Илһам!.. Ул нишләр инде? Их, минем аркада...» Рәшитнең уйларын чүкеч тавышы бүлде.

Күршесе Кәбир абый икән. Машинасы тирәсендә кайнаша:

— Ватылдыңмы әллә, Кәбир абый? — Рәшит бу сорауны үзен бераз тынычландырыр өчен бирде бугай.

— Техника ватылгалап ала инде ул, күрше. Нишләп болай бик иртә тордың? Йокларга иде әле.

Рәшит күрше абыйсының соңгы сүзләрен ишетеп тә җиткермәде, күзен бер ноктага төбәп бераз карап торды да йөгереп өенә кереп китте. Шул арада мунча чормасыннан мазутка, майга буялган төргәк табып алды ул. Аны ашыга-ашыга актарды. Нәрсәләрнедер табып чалбар кесәсенә тутырды һәм түбән очка төшеп китте. Рәшитнең Илһамнарга таба бернинди икеләнүсез баруы иде бу.

Дуслар болдырда күрештеләр.

— Илһам, син миңа ачуланма инде, дускай. Мин кичә синең велосипедыңны ваттым бит. Менә яңа подшипник алып килдем. Хәзер үзем төзәтәм.

Илһам велосипедының ватык булуын кичә үк белгән иде инде. Дөрес, Рәшиткә бик нык ачуы килгән иде аның. Ә бүген Илһамның тавышы да үзгәрмәде:

— Хәзер бергә төзәтәбез, Рәшит. Әйдә башта өйгә кереп чәй эчеп чыгыйк. Кичә көтүдән каен җиләге җыеп алып кайткан идем.

## Киек Каз Юлы

Марат өйләрендәге зур бәллүр вазаны ватты. Ватты да урамга ычкынды һәм караңгы төшкәнче өенә кайтмады. Дөресрәге, кайтырга курыкты. Кирәген бирәчәк, күрмәгәнен күрсәтәчәк бит аңа әтисе әлеге ваза өчен.

Әнә ул урамда берүзе басып тора. Шул вакыт аның баш очында зур гына яктылык пәйда булды. Әнә ул җиргә якынлаша. Бәй, оча торган тәлинкә ич бу. Менә төшеп тә утырды. Люк ачылды.

Көмеш каска кигән бер матур абзыйның башы калыкты.

— Нихәл, Марат? Ваза өчен борчылма. Әйдә безнең белән Эта Кассиопеи йолдызына. Без сиңа вазаның тагын да матуррагын бүләк итәрбез.

Хәлбуки ул көнне күктән берни дә төшмәде. Әлеге очрашу малайның хыялы, фантазиясе иде. Әтисенең каешыннан әнә шулай котылырга теләде ул. Ә чит планетадан килүчеләр җирдә яшәүчеләрнең бөтен уй-гамәлләрен күреп-белеп торалар, имеш. Эта Кассиопеи йолдызы турында исә малай китаптан укыган иде. 1955 елда Американың Кентукки шәһәре янындагы бер фермага «тегеләр» бишәүләп киләләр. Аларга атып карыйлар. Берни дә булмый, тик тимер чыңы гына ишетелеп кала. Фермерларның сөйләвенә караганда, «чакырылмаган кунаклар» нечкә билле, киң күкрәкле, зур күзле һәм зур колаклы. Ә менә 1968 елда Испаниянең Зафра шәһәре янында күренгән «кунак» озын буйлы, озын куллы, янып торган яшел киемнән була.

НЛОлар каян килә соң? Марат күккә карады. Аңа бихисап йолдызлар күз кыса. Бу — Киек Каз Юлы. Ул галәмдәге миллионнарча галактиканың берсе генә булырга мөмкин икән. Димәк, НЛО хуҗаларының кайсыдыр бер йолдызда яшәп ятулары бик ихтимал. Ә Эта Кассиопеи йолдызы — шул фаразларның берсе. Ул кояшка охшаган, аның 480 елга бер әйләнеш ясый торган кечкенә генә иярчене бар, дип язганнар иде. Их, китәргә иде шунда, китәргә иде. Ваза...

— Улым, нишләп йөрисең? Кич бит инде.

Марат әтисенең тавышыннан куркып китте. Әтисенең исә эштән кайтып килеше икән.

— Әти, синең кечкенә вакытта өегездәге берәр әйберне ватканың булдымы?

— Мин ватмаган әйбер калмагандыр, улым. Бик шук идем.

— Әти, мин дә вазаны ваттым бит. Ялгыш ваттым. Син ачуланасың инде мине?

— Нишләп ачуланыйм! Баш ярылмаган, күз чыкмаган...

Әтиле-уллы бергә атладылар. Могҗизалы, серле Киек Каз Юлы яктысы аларны өйләренә кадәр иркәләп-назлап озата барды.

**ЮМОРИСТИК ХИКӘЯЛӘР**

## Ашыгудан ни файда?

Ай-һай тиз дә үтте соң бу җәйге каникул! Әле кайчан гына тышына «Ну, погоди!» төшерелгән капчыкны асып авылга кайткан идем. Инде менә шушы капчыкны асып китеп тә барам, һәр елны каникулны авылда үткәрәм. Әби янында. Әби әйбәт минем. Бая да ул: «И улым, стансага кадәр дистә чакрымнан да күбрәк, шәй. Бара-бара арырсың инде», — дип калды. «Арымам әле», — дигән идем дә, арымассың, көчкә атлыйм.

Нишләптер минем әби кыбырсык җан. Артыннан куалармыни — ашыга. Мин үзем бер дә ашыкмыйм. Ашыгудан ни файда?

Авылга кайту белән үк ул: «Кыяр утыртасы бар иде, улым. Мунча бакчасындагы калган урынны тирес салып китмәнләп бир әле», — диде.

— Ашыкма, әби, — дим, — утыртырбыз.

Юк, әби үзенекен итте, иртәгесен дә шул кыяр, өч көннән соң да шул кыяр, атна буена кыяр дип үзәккә үтте. Алҗыта торгач, ике атнадан соң китмәнләдем теге урынны. Дөрес, ул вакытта кешенең кыяры чәчәк ата башлаган иде инде. Аның каравы, кеше тозлы кыяр ашаганда, без яшел кыяр ашадык. Әби әле, «сбижий кыяр» дип, күршеләрне дә сыйлап йөргән.

Бакчаны гына китмәнләп бер-ике көн үтүгә, әби:

— Ызандагы печәнне чап, улым, — дип теңкәгә тия башлады. Имеш, күрше малайлары Мәүлетҗан белән Тукран-Генрих кушаматлы Насих үзләренекен чабып та куйганнар.

— Ашыкма, әби, — дим, — чабарбыз.

Чаптым. Тик тегеләр кебек җәй буена ике-өч кат түгел, бер кат кына. Күп чабуга карап печән артмый бит, чөнки үлән шулкадәр кыскарак була. Дөрес, әби: «Картайган инде хәзер безнең печән», — дигән булды. Картайса соң... Карт кәҗәгә карт печән дә ярый ла. Аннары карт печән — экономия ул. Яшь печәнне мал хәзер ашап бетерә. Ә монысын озак чәйни. Печән дә тиз генә бетми.

Кәҗә дигәннән, көн авышып, кояш Артыш тавы битендәге корыган өянке очына кадәр тәгәрәп төштеме — әби көн саен башны әйләндерә. «Көтү каршына бар да, көтү каршына бар, зинһар, алып кайт шул кәҗәне дә, зинһар, лапаска яп».

— Ашыкма, әби, — дим, — алып кайтырмын, ябармын.

Беләм ул кәҗәнең гадәтен: көтү кайткач, су буена элдертсә, тегермән бинасының үткән гасыр бүрәнәләренә ышкынып кашынмаса һәм бил тиңентен әрекмән арасында чемченеп йөрмәсә, күңеле булмый аның. Кешеләрнең бакчасына кереп кунак булып та чыга. Караңгы төшә башлагач кына барып алып кайтам үзен. Дөрес, әби саварга соңга кала. Аның каравы башка кәҗәләрнекенә караганда сөте күбрәк була, тамагы туя. Минем ашыкмаудан файдамы? Файда!

Әби беркөнне иртәнге сәгать дүрттә үк күрше Сәлим абыйның машинасына утырып районга китте. Кәҗәне көтүгә куарга миңа кушты: «Сәгать челтерәгәч тә торырсың, улым, яме», — дигән булды. Челтерәде будильник. Юрганнан башны да чыгармыйча, кул белән генә мендәр янындагы урындыктан капшана-капшана эзләп таптым аны, төймәсенә басып авызын томаладым. Икенче якка борылдым да тагын йокыга киттем, нигә ашыгырга? Йокыдан сәгать унда гына уяндым. Дөрес, кәҗәм көтүдән калды калуын. Аның каравы үзен кич белән алып кайтасы булмады.

Күрәсезме, ашыкмаудан гел файда! Тик менә каникул гына ашыкты — тиз үтте. Иртәгә Беренче сентябрь икән бит. Шуңа күрә бүген китәм. Казанда әни каршы алырга тиеш. Әнә станция дә күренде инде. Тагын бер чакрым чамасы атлыйсы калгандыр. Чү!.. Минем поезд килеп туктаган да түгелме соң? Әллә инде кузгалып та бара? Кузгалды шул. Китә бит, китә. Китте, китте-е-е. Бетте баш. Бүген башка поезд юк бит инде. Их!..

Үзем ашыгып атлаган булдым бит әле. Ашыга-ашыга шабыр тиргә баттым. Тик ни файда соң?! Үзегез күреп торасыз — ашыгудан файда юк.

## Әкрәм законы

Әкрәм Ньютонның беренче законыннан «2»ле алды.

«Кеше законыннан «2»ле алып йөргәнче, үзең бер закон ачсаң иде бу дөньяда, — дип уйлады ул. — Вәйт шәп булыр иде. Күкләргә чөеп мактарлар иде үземне. Рәсемемне зур итеп газеталарда, журналларда чыгарырлар иде. Портретымны үзебезнең физика кабинетына Ньютон портреты янына элеп куярлар иде.

Их, ачарга иде, ничек кенә булса да ачарга иде бер яңа закон. Малай-шалайларның исе китәр иде. Аннары физика дәресендә Ньютон, Ом, Паскаль законнары белән бергә Әкрәм законын да өйрәнерләр иде. Күпме ялкау «2»ле алыр, күпме адәм «1»ле алыр иде. Теше үтмәстәйләр чәчләре белән җир себерә-себерә өйрәнерләр иде законымны.

Тукта әле, Ньютон җирнең тарту көчен алмагач төбендә ял итеп ятканда ачкан, ди. Бер алманың җиргә килеп төшүе шушы законны ачтырган, ди».

Әкрәм бакчага чыгып алмагач төбенә сузылып ятты. Биш минут ятты, ун минут... Алма да төшми, өй дә ишелми. Тынлык. Вәйт чыгарып кара закон! Башын чак кына күтәрде, күзләрен тагын да очландыра төште ул. «Мәче йөри инде ак мыегын тырпайтып. Кара, каһәр, юл тапкан үзенә, бакча киртәсенең бер тактасы сынган, шуннан гына чыгып китте. Ничек сынды соң әле ул такта? Ә-әә! Мин велосипед белән килеп бәрелдем бит. Ыжгырып килеп, кинәт туктатыйм дигән идем... «Кәҗәмнең» ал тәгәрмәче бакчага кереп китмәсенме... Такта сынды, тәгәрмәч сыгылды. Шулай да зыян юк. Каюм әле төнлә кыяр урларга баргач, колхоз бакчасының коймасына бәрелеп, мөгезле дә булды. Карагыз әле, мин дә коймага бәрелдем, Каюм да. Әллә инде ул койманың бер-бер хикмәте бар микән? Ур-р-ра-а! Таптым. Закон ачтым! Койманың тарту көче бар, дуслар. Менә шул көч суырып кына ала кешеләрне, тәгәрмәчләрне сигезлегә бөгә, үзеңнән Шүрәле ясый.

Ах бу мәчене, чоланга да ватык тәрәзәдән генә керә. Башы эшли — ишек ачылганын көтеп утырмый. Миңа рәхмәт укысын инде — тәрәзәсен дә мин ваттым бит. Тупны тибеп җибәрүем булды... О-о-о... Портретымны бүген үк элеп куегыз. Тагын бер закон ачтым. Тәрәзәнең тупны тарту көче бар. Менә монысы закон дисәң дә закон. Физика укытучысы Хәй Хәеровичның койманың тарту көченә шикләнүе дә мөмкин әле. Ә менә монысына берсүзсез риза булачак. Чөнки күптән түгел генә мәктәп ишегалдындагы тупны тибеп җибәреп, нәкъ менә физика кабинетының тәрәзәсен койган кеше дә бит әле мин.

Ур-р-р-а! Берьюлы ике закон!»

Әкрәм шатлыгыннан нишләргә дә белмәде. Башын — артка, кулларын як-якка атып ятты. Аннары, булды бу дигәндәй, йодрыгы белән алмагачка китереп сукты. Шул вакыт зур гына бер алма аның борынына ук килеп төште.

— О-о-о... Монысы өченче закон. Борынның тарту көче, — диде ул. Аннары күзләреннән бәреп чыккан яшьләрен сөртте һәм авызын түгәрәкләндереп, иреннәрен өскә күтәреп үзенең юеш борынын тарту көче белән тартып куйды.

## Бер җәйдә... алтмыш рәхмәт

*(Нотык)*

Тимурчылар отрядының бу елдагы егерме җиденче җыелышын ачык дип белдерәм. Әһем... әһем... Беренче сүз — командирга, ягъни үземә. Начар эшләмәдек, дуслар. Әйбәт эшләдек! Ай-яй шәп эшләдек тә инде үткән уку елында!!! Әби-бабайларга кибеттән туксан биш тапкыр сөт алып кайтып бирергә тиеш идек. Туксан җиде мәртәбә алып кайттык! Аптекадан дару ташу планын ике

тапкырга арттырып үтәдек. Инде килеп, таеп егылган өч әбине кулыннан өстерәп торгызу дисеңме... Бер бабай белән биш әбине урам аша чыгарып атумы... У-у-у, саный китсәң, күп инде алар — без эшләгән эшләр. *(Кул чабулар.)*

Дөрес, таеп егылган әби-бабайларны тартып торгызу планы үтәлеп җитмәде. Әмма безнең монда тырнак очы кадәр дә гаебебез юк. Чат башына басып, кайсы әбинең кайчан таеп егылуын көтеп торып булмый лабаса?! Аяз күктән яңгыр көтү белән бер бу. Ярый, егылсын да ди әбиең. Син кулыңны сузып килеп җиткәнче аның җәһәт кенә сикереп торып шылуы да ихтимал ич әле. Егылса да зыян юк. Чиләк-чиләк комны егылырга йомшак булсын дип сиптек ләса.

Шулай да, шулай да... Эһем... эһем... эһем... Борын чөяргә ашыкмыйк. Бу айда көймәбез комга терәлергә тора. План өзелә. Сөтне генә алыйк. Кемгә ташырбыз без аны хәзер? Их, Камалия әбиебез!.. Китеп барды бит, эһ... эһ... эһем... эһем... Ташкентка, улы янына кунакка. Бу айда кайтмавы да ихтимал. Мәчтүрәттәй дә савыгып урыныннан торган, ди. Хәзер дару ни дә, башка ни аңа.

Эш харап! Нишлибез соң? Сентябрьдә отчет каерачаклар бездән. Эһ-эһ... Кул кушырып тик торыйкмы? Тик торучы тимурчы булмый бит инде. Хәер, ник булмасын?! Тик торучы түгел, тик утыручы тимурчы да була әле. Әнә Әкрәм! Төнәгеен кичкырын трамвайда бара икән. Киерелеп утырган, ди. Күзе — тәрәзәдә. Шәһәр. Манзара. Төсле утлар: «Обувь», «Аяк киеме», «Пәри... махерская», «Шапки», «Бүре...ләр», «Мороженое»... Әкрәм телен йотардай булып сикереп торган. Ишеккә ташланыйм дисә, трамвайда энә төртерлек тә урын юк икән. Төшеп тормаган, шап итеп кире урынына утырган да борынын тагын тәрәзәгә төрткән. Бераз баргач, беләсезме нишләгән? Янында көч-хәл белән басып баручы ике әбигә үзенең урынын тәкъдим иткән. Дөрес, әбиләрнең берсе дә утырырга кыймаган. Ник дисәң, трамвай соңгы тукталышка килеп җиткән булган. Аның каравы әбиләрнең икесе дә Әкрәмгә рәхмәт әйтеп төшеп киткән.

О-о-о! Бу җәйдә ике «рәхмәт» эшләгәнбез бит инде. Моны рапорт дәфтәренә төртеп куярга кирәк. Ә бер рәхмәт мең бәладән коткара, ди. Тәк-тәк. Без — утыз тимурчы, һәркем Әкрәм кебек ике «рәхмәт» ишетсәме?.. Алтмыш «рәхмәт» була. Бик хуп! Тышына «җәйгә план» дип язылган кенәгәнең беренче битенә кызыл белән сырлап куям мин бу алтмышны.

Үтәп булырмы? Була, әлбәттә. Әйе, ярты айда ук үтибез без аны. Ун көндә дә була. Шулай! Дөрес әйтәсез. Биш көндә дә була. Әйе! Өч көндә дә. Була, әлбәттә! Хәтта бер көндә дә үтәргә була моны. Бүген үк. Менә хәзер, Каравайга барып, барыбыз да буш трамвайга утырабыз да кичкә кадәр дыңгыр-дыңгыр йөрибез. Вагонга алтмышынчы әби кереп, беребез аңа торып урын биргәч кенә бушатабыз трамвайны.

Эһем... эһем... Чыгышымны йомгаклап шуны әйтәсем килә: без, яулаган үрләребез, бихисап уңышларыбыз белән рухланган хәлдә, җәйге каникулда да яңа калкулыкларга менәргә тиешбез. Эһем... Әби-бабайларга күптин-күп шатлыклар китерер өчен, алтмыш «рәхмәт» ишетер өчен — алга! Каравайга! *(Көчле кул чабулар.)*

## Инша

Класс инша яза. Әкрәм генә язмый. Ручкасын чәйни. Чәйнәмәс иде — ни язарга белми. «Мин кибетче булам, — дип сырлый партадашы Ләлә. — Рәхәт эш ул». Арткы партадагы Кави сарык фермасында этисе кебек мөдир булырга тели. «Иртән эшкә килгәндә бөдрә йонлы бәрәннәр күзеңә карап көтеп торалар. Аларга көрпә сибеп чи бәрәңге бирсәң, бернәрсә кирәкми», — дип яза. Шул ук партадан Озын Сабир йә капитан, йә майор булам дип җенләнә. «Уйлап карагыз, каршыңда — бер көтү солдат. Погоннарыңдагы йолдызларны балкытып яннарына килеп басасың. «Смирно!» — дип акырасың. Безнеңчә «Үрә кат!» инде. Тегеләр катып кала», — дип тезә.

Әкрәм авызыннан ручкасын ала. Алак-ялак карана. Ятып калганчы, атып кал дигәндәй, әле теге күршесеннән, әле монысыннан (кайсы күчертә бит!) күчерергә тотына. Тәнәфескә чыкканда укытучыга менә мондый инша тапшыра: *«Мин кибетче булам. Рәхәт эш ул. Фрукты кибетенә эләксәң, кавын белән карбызны сыпыртасың гына. Кешеләргә дә сатасың. Иртән эшкә килгәндә*

*бөдрә йонлы бәрәннәр күзеңә карап көтеп торалар. Аларга көрпә сибеп чи бәрәңге бирсәң, бернәрсә кирәкми. Күп бирәсе түгел түлке. Хәзер азрак биреп, күбрәк алганны мактыйлар. Акча дигәнең янга да калсын. Азрак табыш та булмагач, ничу йөрергә ул бәрәннәр арасында. Сарык фермасында эшләве бик кызык. Погоннарыңдагы йолдызларыңны балкытып яннарына килеп басасың. «Смирно!» — дип акырасың. Барысы да үрә ката. Катмый калганы йолдызыңа кызыгып карап торган була. «Отставить!» — дисең. Тагын үрә катарга кушасың. Барысы да катып бетә. Шуның белән минем инша да бетә».*

## Шәп малаймы?

Малайны ныклап тәрбияләргә исәп әле, Хәбир Кәримович. Әнисенең сүзе генә үтми аңа. Ә мин, үзегез беләсез, тоткан җирдән сындырам. Хатын мескен күпме тукыды үзенә: «Өлкәннәрне хөрмәт ит. Әби-бабайларның хәтерен калдырма», — диде. Ә ул нишләгән? Мөкәрәмәттәнең котын алган. Бичара карчык түр өйдә намаз укып утыра икән. Бу килеп тә кергән, кисмәк капкачын идәнгә тотып та бәргән. Намазын бүлгән бит әбекәйнең. Колагын борам мин ул җүнсез малайның.

— Ишеттем мин аны, Җаббар Сабирович. Ул каһәр суккан капкачны әйтер идем инде. Улыгыз ерак чишмәдән су алып кайткан әбигә. Шул суны кече өйгә Мөкәрәмәттәнең үзенә сиздермичә генә кертеп чыкмакчы булган. Кертүен керткән. Тик борылганда гына өстәл өстендә яткан ошбу кисмәк капкачы улыгызның пәлтә җиңенә эләккән дә дөмбердәп идәнгә очкан. Малайның ни гаебе бар монда?!

— Анысы шулайдыр да, ә менә аның классташ кызларын кыерсытуын ничек аңлатырга?! Хәтта рәнҗеткән бит үзләрен, имансыз малай. Чат Шәймәрдәннең кызы елап ук кайткан, ди.

— Монысын дөрес әйтәсез. Кызларны үпкәләткән шул. Тимурчыларга эш бүлгәндә Мөкәрәмәттәне иң беренче булып ул эләктергән. Башкаларга әби дә калмаган.

— Кеше әйберенә кагылма, дип ни әйткәнебез бар ул сантыйга. Кисәм мин аны кайткач.

— Җүләрләнмәгез, Җаббар Сабирович! Ул балавыз сыккан кызлар Мөкәрәмәттәне былтыр шефка алып карадылар инде. Өйгә утын кертәбез дип әрдәнәсен ишкәннәр дә чыгып качканнар. Ел буена берсенең дә эзе-юлы булмаган. Ә улыгыз ялгыз әбине кыш буена чишмә суыннан өзмәде.

— Шулай да, Хәбир Кәримович, сантый малай ул. Классташларың белән дус бул, әйткәләшеп-төртешеп йөрмә, дип, әнисе белән күпме үгет-нәсихәт тукыдык без аның колагына. Ә ул сүзләребезне аяк астына салып таптаган. Аның белән класстагы малайлар арасына да кара мәче кергән дип ишеттем. Пешерәм мин аны.

— Аның Мөкәрәмәттәгә су китерүен күреп, класстагы башка малайларга да әниләре суга барырга куша башлаганнар. Тегеләрнең шуңа күрә генә ачуы килгән. Ха-ха-ха!.. Сезнең малайны әйтәм... Мөкәрәмәттә белән бигрәк тә дуслар инде алар. Җәй көне мин аңа мылтык биргән идем. Беләсезме? Рәсемгә төшерә торган мылтык. Шуның белән атып, Мөкәрәмәттәне урманда җиләк җыйганда рәсемгә төшергән. Гаҗәп рәсем килеп чыккан.

— Сез ни сөйлисез? Әле тагын Мөкәрәмәттәгә мылтыктан аткан булганмы?.. Моның өченме?.. Моның өчен мин аны үзем хөкем итәчәкмен. Минме? Мин аңа иң югары хөкем карары чыгарачакмын. Бүген үк... Кайтуга!..

— Сез акылыгыздамы? Сезнең малай — барысына да үрнәк. Сезнең малай — иң шәп малай, Җаббар Сабирович. Аннан да шәп малай юк.

— Рәхмәт! Тимим лә. Тырнак белән дә кагылмыйм мин аңа. Сезнең класс җитәкчесе буларак шушы сүзләрегезне генә ишетәсем килгән иде.

## Бәхетле билет

Әкрәм кичә ике сәгать чират торып алды аны. Юкка басып тормаган. Фильмы бик шәп, диләр. Җитмәсә, бәхетле билет та эләкте үзенә. Номеры — 532235. Алдагы өч санның суммасы арттагы өч санның суммасына суйган да каплаган.

Бүген кинога барырга чыккан Әкрәм тукталышта автобус көткәндә дә кесәсен әллә ничә тапкыр капшап карады. Билет төшеп калмаганмы, янәсе.

Ә автобусны озак көтте ул. Кинога алып бара торган «14»ле йөреп тора инде югыйсә. «Икарус»лар, «ЛАЗ»лар пошт итеп килеп туктыйлар, ишекләрен киереп ачалар, үкереп китеп тә баралар. Әкрәм көтә. Кешесе аз, буш урыннары күп булган «14»лене көтә ул. Җене сөйми басып баруны. Этәләр, төртәләр, изәләр. Утырып баруга ни җитә!

Ниһаять, килде ул теләгән автобус. Әкрәм сикереп менде һәм ишек янындагы бер утыргычка барып сеңде. Инде кесәдәге билет вәгъдә иткән бәхетнең тәмам түгәрәкләнүе өчен ике генә теләкнең үтәлесе калды. Автобус тукталышларда озак мышнап тормасын, җәһәт туктап, җәһәт китсен. Болай да кинога соңга калды. Икенче теләк: әби-чәбиләр генә килеп кермәсен, чөнки торып урын бирәсе була.

Их, өйдә генә утырамыни соң ул әби халкы! Берсе икенче тукталышта ук керде әнә. Башта баскычтан алагаем зур биштәре күтәрелде, аның артыннан ах-ух килеп үзе күренде. «Әле ярый, рәхмәт төшкере, арты белән басты. Колак каккан идем бит урыннан, — дип уйлады Әкрәм. — Әбигә урын бир, дип кем дә кем сырт кабартса, акланырга сәбәп бар. Аның аркасына «Әби» дип язылмаган бит. Ярый, чәче ак та булсын ди. Хәзер ике кызның берсе чәчен акка буятып йөри».

Автобус тагын туктады. Пошкырып ишеген ачты. Тагын әби! Керде, «ЛАЗ» кузгалып киткән шәпкә сөртенгән кеше кебек, алга ташланды һәм Әкрәмнең утыргычы кырыена килеп тә сыланды. Малай күзен бер кырыйга чайпалдырып аңа карап куйды. «Урын бирергәме, юкмы? Бирүен бирерсең дә, бәлки әле, бу әби үзен гүпчим дә әбигә чутламыйдыр. Кемнең картаясы килсен! Юк, урын биреп карт кешенең хәтерен калдырырсың, үпкәләтерсең, рәнҗетерсең. Тәүбә, тәүбә!» — Бу юлы Әкрәм үзен әнә шулай тынычландырды.

Бераздан тагын бер әби, майга елышкан мәче кебек, Әкрәм янына килеп бөкрәйде. «У-у-у. Монысы әби дисәң дә әби. Сиксәннең теге ягында булыр». — Әкрәм урыныннан тормакчы булып кыбырсып та караган иде. Шул вакыт күршесе Хафизулла бабай җырлап йөри торган бер җыр исенә төште.

Яшел килеш бигрәк тәмле
Тау кыры борчаклары,
Җитмеш биштә, сиксән биштә
Кызның матур чаклары.

«Мондый җыр булгандамы... Мондый җыр булганда, урын бирмичә утырып барган теләсә кайсы малай үзенә кисәтү ясаган теләсә кемнең авызын каплый ала. Хәер, бу җырны әйтеп бирсәң, әбиләр утырып барудан үзләре үк баш тартачак». Әкрәм утыргычында киерелеп куйды. Ләкин бу вакытта халык төшәргә җыенып ишек янында бөялә башлаган иде. «Нишләп барысы да кузгалды соң әле?» Әкрәм дә урыныннан торды һәм тәрәзәгә күз салды. Шунда гына, ялгыш икенче автобуска утырып, башка якка киткәнен һәм инде кинодан колак какканын аңлап алды.

Халык агымы аны да үзе белән ияртеп ишеккә алып китте.

— Билетың! — Кемдер аның беләгеннән кысып тотты.

«Контролер» дигән уй Әкрәмнең баш миен телеп узды. Ул, гәрчә билет алмаганын белсә дә, кесәләрен актарган булып маташты. Ә анда кинога алган бәхетле билеттан башка билет юк иде.

## «Чук һәм Гек» һәм дә... Ирек

Әдәбият укытучысы Фәһимә апа кышкы каникулда китап укырга кушкан иде. Искәндәр бишне укыган, Алмаз — өчне. Ә Һашим... Ха-ха-ха... Күңел өчен генә булса да ник берне укысын. Укымаган. Мескеннең дә мескене булып, сорау билгесе кебек кәкрәеп тора инде бүген. Ә мин:

— «Чук һәм Гек»ны укыдым, — дидем, Фәһимә апаның күзенә керердәй булып.

Су урынына чөмердем мин ул китапны. Шәп китап! Көзге каникулда да, җәйге каникулда да шуны укыган идем. Былтыр да гел шуны укыдым. Каникул саен шул китапны укыйм!

Фәһимә апа көзге каникулда кемнең нинди китап укыганын ничек хәтерләп торсын. Ә былтыргыны хәтерләми дә хәтерләми инде. Шулай дип уйлаган идем дә... Беркөнне чакырып алмасынмы мине үз янына.

— Хәтерем ялгышмаса, син, Каюмов, «Чук һәм Гек»ны алты тапкыр укыдың бугай инде.

— Биш кенә, — дидем мин. Үземнең тез буыннары калтырый.

— Тик бу китапны син китапханәдән бер тапкыр да алмагансың. Үзеңнеке бар мәллә?

Куркуымнан: «Ә-ә-ә-йе», — дип әйткәнемне сизми дә калдым.

— Ирек, алып кил әле аны мәктәпкә. Шушы әсәр буенча укучылар конференциясе үткәрәбез. Үзең дә катнашачаксың. Чыгыш ясарга әзерлән.

Шулай диде дә Фәһимә апа китеп тә барды. Ә мин җир тишегенә керердәй булып басып торам. Дөресен әйткәндә, күргәнем дә юк минем ул китапны. Моннан бер-ике ел элек телевизордан киносын гына караган идем. Шуның аркасында гына укыган атлы булып йөрдем бит. Инде нишләргә?

## Җәйге кар

Тәк, киегез туннарыгызны. Төшерәм. Тик ишетсен колагыгыз: циркта аю күргәндәй, күзегезне чекерәйтеп, объективка карамагыз. Бер-берегез белән сөйләшкәндәй кыланыгыз. Югыйсә конкурста бүләк дигәнең тү-тү-ү миңа. Сурәт болай килде-китте чыкмаска тиеш. Исеме дә этәч инде менә: «Беренче кар». Бигрәк хикмәт бит, ә? Миеңне кайнатырлык эсседә «Беренче кар»ны «черт» иттерәм. Башыңа төшсә, башмакчы буласың, ди. Чын кар яуганын көтеп утырсаң, бүләкне дә кызыл кар яугач кына алырсың. Конкурс октябрь башында була бит. Шуңа күрә карны июньдә «яудырырга» туры килә инде. Яудырабыз да без аны. Карагыз менә бу тополь мамыкларына. Чын кардан киммени? Кар да кар, болар да кар. Нәкъ шулай очалар, нәкъ шулай бөтереләләр. Былтыр Тәфкил үзенең «Беренче кар» дигән ала-кола фотосы белән дә җиңеп чыкты. Быел асыл бәхет кошын мин каптырам.

Җә, киендегезме? Мәүлетҗан, кулыңдагы мамыкны, тфү... карны ла, Сәүбәннең борынына җибәрергә әзерлән. Ә син, Сәүбән, авызыңа мамык тутыр, ягъни кар ашаган булып кылан. Төшерәм.

Тукта!

Син нәрсә, Сәүбән? Кем инде майка өстеннән тун кия? Якаңны төймәлә хет. Май түгел — эремәссең. Менә шулай. Төшерәм...

Тукта!

Мәүлетҗан! Энем, башыңда — бүре кадәр бүрек. Өстеңдә — кайры тун. Аягыңа ник кимәдең? Чебиләреңә кадәр күренеп тора. Кар өстендә кем ялантәпи йөри? Хәзер үк аягыңа итек киеп чык. Ә син, Сәүбән, бүрегеңне салып, башыңны җилләтә торыр идең. Каравылчы Байтимер бабайның яңгыр суы тулган дегетле мичкәсенә чумган кебек булгансың. Фотоаппараттан «чыпчык очып чыкканчы» гына тирләмичә тора аласыңмы син, юкмы? А-а-а, маладис энекәш, тиз йөрдең. Басыгыз! Төшерәм. Сәүбән, елмай. Авызыңа мамык тулса ни, барыбер елмай.

Тукта!

Мәүлетҗан, беренче кар нинди була? Җепшек була. Аяк асты нишли? Белмәсәң бел: лычҗырдый. Син шул ни арба, ни чана вакытында, аяк сөйрәмәслек пычракта киез итек белән йөрмәкчесең инде, ә? Олтаны яна башласа, нишләрсең? Башың булса, итек өстеннән менә бу галошларны киеп куяр идең, ичмасам. Кидеңме? Төшерәм. Тәк...

Тукта!

Мәүлетҗан, әнә әби судан кайтып килә. Хәзер аны да сезнең янга бастырам. Энем, өйдән әбигә дә берәр пәлтәме, тунмы алып чык әле. Бер аягың — тегендә, икенчесе монда булсын. Ә син, яшьти... Сәүбән, сиңа әйтәм: җилли тор. Әле ярый көне кыздыра, югыйсә ничек киптерер идең тиргә баткан башыңны?

Тизрәк кил, әби, мамык очып бетә ич... Карточкага төшәсең киләме? Шпатель күлмәгеңне киеп?.. Шпатель күлмәктән аннары төшәрсең. Хәзер тун киеп төш әле. Котың очмасын, «чыпчык выжт итеп чыккан» арада төшерәм мин сине. Тунсыз булмый. Юкса конкурста бүләкнең койрыгы да эләкмәячәк миңа. Әнә күрәсеңме, кар ява. Шикләнмә, әби, шикләнмә, һәрхәлдә, фотода кар булып күренәчәк ул. Мәүлетҗан үзеңә әнинең кыйбатлы яңа тунын алып чыккан энә. Әйдә, әби, чум шуңа. Бүрекне — башыңа, көянтәңне — җилкәңә. Булдымы? Төшерәм. Әби, чыраеңны сытма. Ни булды? Тунны көя турый башлаган?.. Тураса соң... Фотода күренми бит ул. Исең киткән икән. Төшерәм.

Тукта!

Болай булмый, малайлар. Әби бөгелә-сыгыла су күтәреп тора. Ә сезнең кул — кесәдә, койрык — сыртта. Гамьсезрәк килеп чыга. Алмашыгыз рольләрне. Мәүлет, Сәүбән, сезнең икегезгә берәр чиләк су. Тимурчылар ди сез. Ә син, әби, аларга кар атып тор. Нәрсә, Сәүбән, авыз эчендә ботка пешерәсең? Туннарны салып ыргытыйк та тимурчылар булып кына төшик?.. Очлы башыңа бүрек элсәң дә, кояш сукты, ахры, сине. Җәй көне тимурчыларның берәр тапкыр күзеңә чалынганы булдымы? Кар яугач кына уяна алар.

Төшер-р...

Тукта!

Әби, синең дә үзеңә су алып кайта торган малайларга кар атып каршы чыгуың мәктәп стенасына сыеп бетми. Иң яхшысы болай черт иттерәм мин сезне: малайлар су ташый, әби кар ашый. Әзерме? Төшерәм, һоп!.. Ни булды соң бу? Фотоаппарат кәҗәләнеп маташа. Пленкасы ычкынганмы шунда... Хәзер, айн момент. Тәк, ачам. Тфү, шайтан! Пленканы яндырдым бит. Соңгысы иде, каһәр. Салыгыз инде туннарыгызны. Очты чыпчык. Янган пленкага ничек төшерәсең ди? Ясаганда сумала төсле кап-кара була бит ул. Хәер, карны төшерсәң дә пленкада нәкъ шулай чыгар иде. Бу киребеткән тасма ак белән караны аера белми ул. Ак — кара, кара ак булып чыга анда. Тотам да шушы пленкадан гына чәпелдәтәм конкурска бер фото. Карның үзен генә төшердем диярмен. Тик менә сез генә, ни тырышып та, сурәтләрегезне күрә алмыйсыз инде. Ә син кайгырма, әби. Мартта да була әле ул конкурс. Анысына «Беренче яңгыр» дигән фото чүким. Кыш көне төшерәм. Гыйнварда. Әнә бер елны Яңа елда чиләкләп койды. Исән-сау торсаң, шпатель күлмәгең белән генә төшәрсең.

## Элмәк

Сәетҗаннан да шәбрәк спортчы булмас иде мәктәптә. Тик... хоккей уйнаганда алканы капкага кертә алмаса, кәшәкәсе кыек булып чыга. Сабан туенда көрәштә сырты белән килеп төшсә, аңа сөлгенең кыскарагы эләккән дип уйлагыз. Чаңгы ярышында финишка килеп җитә алмаса... Хәер, чаңгы дигәннән, бүген дә ярыш әнә. Тагын шул Сәетҗан аркасында призлан колак кагармы инде җиденчеләр? Бу юлы аңа физорг Фәрит үз чаңгысын биреп торды. Синең чаңгың да, таягың да самоходный, үзе бара, этәсе дә юк, шуңа узасың, дигән иде аңа Сәетҗан.

«Старт» дип язылган колга янына беренче булып килеп басты малай. Тик беренче булып китмәде генә. Сигез кешене озатты. Юлны шомарта торсыннар, диде. Шунысы да бар бит: беренче булып китсәң, кемне узарсың? Ә болай тугызынчы булып китә. Алдагы сигез малайны узачак.

Судья кулындагы кызыл флагның һаваны ярып, аска атылуы булды, Сәетҗан сөзәргә ташланган тәкә күк алга ыргылды. Менә бу старт ичмасам! Мәктәп тарихында, алай гына да түгел, районда шулай старт алган чаңгычы булды микән?! Тайфун узып киттемени?! Сәетҗан

боксчы көндәшен дөмбәсләгәндәй селтәнде дә селтәнде. Таякларын алга-артка, уңга-сулга шундый итеп чәчте ки, ярыш карарга килгән малайларның уң яктагы төркемен коймага китереп сылады. Сул яктагы төркемне исә бил тиңеннән кар көртенә кертеп чумдырды. Күзгә кар тузаны сибелде. Чаңгыларның сукмакка шап-шоп бәрелгән тавышы колакны ярырдай булып ишетелә иде. Җан-фәрманга йөгерде Сәетҗан. Болай булса, малаең беренче киләчәк. Приз алачак. Үзәннән күтәрелгәндә самоход туктап калды. Сәетҗан бер турайды, бер кәкрәйде, күзләрен чытырдатып йомды, ул борыны белән генә түгел, авызы белән дә комсызланып сулый иде. Әмма озак мышнарга вакыт юк. Арттан куып җитеп үкчәсенә басарга мөмкиннәр. Шулай булды да. Озак титаклый алмады. Аның артыннан килүче унынчы чаңгычы аның белән тигезләште дә. Уздырмаска дип ничек тырышса да, таякларын уңлы-суллы сипсә дә, булдыра алмады. Аннары унынчыга ияреп барырга тырышып карады. Тик аны моңсу караш белән озатып калудан башка чара юк иде.

Бераздан шулай унберенчене, уникенчене, унөченчене озатты... Егерме бер белән егерме өчкә юл биргәч, Сәетҗан чаңгыларның арты белән юлны кыйный-кыйный кыптырдаганда, тегеләр инде, ак мамык өстеннән очып үткән кошлар кебек кенә, аның алдыннан җилдерәләр иде. Болай булгач, адәм көлкесенә кала түгелме соң ул?! Берәр чарасын табарга кирәк. Тик ничек? Үзе белгән бердәнбер юл кала инде. Йә чаңгыга, йә таякка сылтарга. Ләкин кайсына сылтыйсың бит, икесе дә шәп. Мәктәпнең элекке чемпионы йөргән чаңгылар. Ә бит шәптән дә шикләнергә була. Бу чаңгының, мәсәлән, элмәге ычкынмый дип кем әйтә? Финишка җитәрәк кенә Сәетҗан элмәкне үзе ычкындырып куячак та килеп җиткәндә аягын шундый итеп селтәп җибәрәчәк ки, чаңгының төшеп калганын бөтен кеше күрәчәк. Юл буе шулай азапланып барган икән дип кызганырлар да әле мескенне. Ниһаять, финиш! Тау гына төшәсе бар. Элмәк ычкындырылды, һәм ни булды дисезме? Чаңгы да ычкынды. Малайны тау башында калдырып төште дә китте. Бераздан тауны бер аягы белән шуып, бер аягында тыраклап төшкән Сәетҗан да халык алдына килеп ауды.

— Чаңгың да чаңгың, — диде аңа судья. — Хәтта үзеңнән дә алдарак килде.

Сәетҗан исә бу минутта нәкъ шул чаңгысын рәнҗи-рәнҗи битәрләп маташа иде.

## Кем катырак суга?

Хәмит кура бакчасының коймасы буена өелгән такта өстенә әбисенең иске кара бишмәтен җәйде дә башта корсагын, аннары аркасын кояшта каралтырга булды. Шап-шоп килгән тавыш малайны чалкан яткан хәленнән уң ягына борылырга һәм терсәгенә таянып башын чак гына күтәрергә мәҗбүр итте: «Ә-ә-ә-ә... бабай палас кага икән. Әй, азапланасы гына юк иде лә... Үзем кагар идем әле. Юкса әйттем бит инде аңа: кагармын, дидем. Тик хәзер түгел. Кич белән. Кояш баегач... Ә хәзер кызынып калырга кирәк. Быелгы кебек яңгырлы җәйдә кояшы бик тансык бит. Ничек инде шундый кояшны калдырып, палас кагасың ди. Кояш качар — кагармын. Теге көнне бит кояш та бетте, яңгыр да яварга тотынды. Шуңа күрә палас кагылмый калды. Аннан элегрәк тә шулай булды. Ә бүген кагар идем. Мин каксаммы — болай гына маташмас идем. Бабай бигрәк кызганып суга инде — сауганда тибенмәсен өчен ак маңгайлы кәҗәне иркәләп-сөеп торамыни?! Кизәнеп сугарга кирәк аңа. Шулай иткәндә генә тузаны чыга. Мин булсаммы, ике кулыма ике бәргеч тотар идем дә паласны уңлы-суллы кыйнар идем. Вәйт тузаны калмас иде. Юк, болай итеп тә маташмас идем. Кулыма озын гына бер такта алыр идем һәм, шул такта белән 180 градуслы борылыш ясап, паласка берне китереп орыр идем — тузан болыт булып күтәрелер иде. Хәер, иң шәбе күсәк яки тәпәч белән бәрергә. Йөгереп киләсең дә 360 градуска әйләнеп селтәнәсең — тузан паластан син сукканчы ук куркуыннан чыгып оча. Ә нигә бер сугуда паласның бөтен тузанын очырып чыгара торган машина уйлап чыгармаска? Кнопкага басуың була, ул машина паласка шундый иттереп китереп суга ки, тузан белән бергә паласның кайбер җепләре дә атылып чыга.

Паласка бик каты суга торган, ай-яй да каты суга торган тагын нинди техника уйлап чыгарып була икән? Ә, таптым!..»

Хәмитнең уйлары шушы урында бүленеп калды. Кинәт аның күз аллары караңгыланды, башы авырта башлады. «Әллә инде паласка суга торган әйберләр турында күбрәк уйлап ташладым», — үз-үзенә шулай диде дә, алпан-тилпән атлап, бабасы янына килде ул:

— Бабай, минем баш ник авырта икән?

— Ай, олан, сиңа бит кояш суккан. Ай-яй да каты суккан, — диде бабасы һәм сөялле кулы белән Хәмитнең тузанлы (бик тузанлы!) чәченнән сыпырды.

## Фельетон яза Фәсхетдин

Редакциягә килеп керде ул. Керде дә күзенә үк төшереп кигән бәрхет кепкасын арткарак шудырып җибәрде. Аннары кул аркасы белән кояшта янган маңгаен сыпырып алды.

— Фәсхетдин булам мин. Фамилиям Сәфәргалиев. Фельетоннар язучы.

— Кайларга язасың, кайларда басыласың?

— Үзебезнең класс гәҗитәсе «Тукмак»ка гына язам мин. Классташларымны да фельетон язарга өйрәтәм. Бик күп кешеләрне өйрәттем инде фельетон язарга, һаман өйрәтәм.

— Бик шәп, — минәйтәм, — әйдүк түргә. Берәр фельетоныңны да алып килгәнсеңдер әле.

— Фельетонны иртәгә алып килермен. Бүген Шәвәлидән заказ алырга килдем. Шәвәли кайда соң?

— Командировкада бит әле ул.

— Кая китте?

— Ул бит бүген — котыпта, иртәгә — Кызыл Комда. Бик җәһәт йөри торган кеше бит ул.

— Булмады инде алайса, кемнәр турында фельетон язарга кирәклеген сорамакчы идем.

— Беткәнмени фельетон геройлары булырлык бәндәләр: ялкаулар, җилкуарлар, ялганчылар, мактанчыклар — теләсә кайсын тот та яз.

— Әһә, булды, — диде ул. Маңгаен яңадан кепкасы белән каплады да ишекне киң ачып чыгып та китте.

Иртәгесен: «Менә яздым, — дип килеп керде ул. — Ялкаулар турында. Исеме дә «Ялкаулар капты» дип атала. Шәп исем бит?! Кыска, кычкырып тора. Фельетонның исеме кыска булырга тиеш: «Капты», «Эләкте», «Батты»...

Фельетонны укырга дип иелүем булды, исем китте. Сүзен түгел, хәрефен дә танырлык түгел. Берәр тараканны кара савытына тыгып алып, ак кәгазь өстенә җибәрсәң дә, шулкадәр пычратмас.

— Яңадан күчереп яз әле моны, — дим, — шунсыз укып булмый.

— Ярар, язып килермен, — диде ул. Бәрхет кепка яңадан маңгаена шуып төште.

Өченче килүендә Фәсхетдиннең авызы колагына җиткән иде:

— Тегене күчереп тормадым мин. Тотып аттым мин аны. Яңаны яздым. «Ялкаулар эләкте» дип атала. Тик монысын да күчереп язарга вакыт булмады. Үзем генә укып чыгыйм.

Фәсхетдиннең фельетон дигәне бер әбинең көч-хәл белән урам аша чыгуын күзәтеп торуы һәм бу әбигә бер генә укучы баланың да килеп булышмавы турында иде. «Бу урам малайлары ялкаулар икән, шуңа күрә фельетонга эләктеләр», — дип тәмамлаган ул.

— Син бит монда үзең эләккәнсең, — дидем мин, — бәлки, ул әбине күрүче дә булмагандыр. Ә менә син күрә торып та аңа ярдәм итмәгәнсең.

Фәсхетдин бу юлы бәрхет кепкасын күзенә түгел, колагына шудырды.

Ә беркөнне фельетоннар язучы малаебызның авыз-борыны салынган иде.

— Кем дә булса хәтереңне калдырды мәллә? — дим.

— Хәтер калу гынамы соң...

— Ни булды соң?

— Рәнҗеттеләр.

— Кем? Ничек? — дидем мин, аның хәленә керергә тырышып.

— Классташларым минем турыда «Тукмак»ка фельетон язганнар. Җәй көне мәктәп бакчасына эшкә бармаган идем. Шуны язганнар. Минем өчен Шакир эшләде бит. Үземнең вакыт булмады.

Үзләрен фельетон язарга өйрәткән кеше турында язалар бит. Аш атканга таш аталар. Сезгә яхшылыкны аңламаган шул кешеләр турында язып китерәм әле. «Үзем фельетон язарга өйрәткән классташларымның минем турында фельетон язулары турында фельетон» дип аталачак ул.

Фәсхетдин чыгып киткәч, миндә дә «Үзе фельетон язарга өйрәткән классташларының аның үзе турында фельетон язулары турында фельетон язучы малай турында фельетон» дигән фельетон язарга теләк туды. Яздым. Тик исемен генә үзгәртергә туры килде. Фәсхетдин: «Фельетонның исеме кыска булырга тиеш», — диде бит.

## Марафон

Тирес корты булып беттек инде. Дөньяга бер дә чыккан юк. Әйдәле, Гыйльмиҗамал, бүген ычтадиүнгә барыйк әле. Бәйрәм була, ди, анда, йөгерүчеләр бәйрәме. Олан да бик кыстады. Мин дә йөгерәм, дигән була шайтан малай.

Күрше карчыгы чакыргач ничек каршы киләсең?! Гыйльмиҗамал әби риза булды. Бераздан ике карчык дөньяларын онытып, тирә-якның матурлыгына, яшеллегенә сокланып, спортчыларның җитезлегенә исләре китеп стадионда утыралар иде инде.

— Күз генә тимәсен, исән-сау гына булсыннар! Ай-яй каты чабалар инде, ә, Бибинур тәтә.

— Сөйләмә инде, Гыйльмиҗамал. Аяклары җиргә дә тими.

— Бездән булмаган инде ул болай җөгерүләр. Әти мәрхүм әйтә торган иде, сиңа, кызым, бу аякларың белән атка атланып кына җөрисе инде, ди торган иде. Бигрәк камыт идем шул. Җөгерү миннән булмады инде ул, булмады, Бибинур тәтә.

— Карале теге кечкенә малайны. Сөзәргә килгән тәкә кебек чаба.

— Син аны әйтәсең. Әнә теге бабайга нәрсә калган инде?! Картаймыш көнендә, оялмыйча, сыйракларын күрсәтеп җөгереп җөрмәсә. Атлап җөри алганы өчен Ходайга рәхмәт укып тик утырсын инде шунда.

— Таза җелек икән, ә! Ычтадиүн хәтле ычтадиүнгә йөгерергә килгән бит.

— Тагын җөз ел яшисең дисәләр дә җөгермәс идем мин, Бибинур тәтә. Җөгерергә хәлем дә юк, җегәрем дә юк.

— Уф! Тамак төбем кипте бит әле, Гыйльмиҗамал. Чәй-мазар сатмыйлар микән. Барып килмибезме?

— Минем эчәсем килми, Бибинур. Үзең барып килсәң генә инде.

Дус карчыгының китүе булды — Гыйльмиҗамал урыныннан ут капкандай сикереп тә торды һәм камыт аякларын болгый-болгый баскычтан төшә башлады. Бу ни хәл бу? Бу ни хикмәт? Гыйльмиҗамал әби стадион буйлап йөгерә! Халык акыра, көлә, гөжли. Әбинең аларда эше юк. Чабуын белә ул. Стадионны аркылыга кистереп чыгуы булды — аны марафончылар агымы эләктереп алып китте. Бу агым бичара карчыкны 50–60 метр чамасы этеп алып барды. Аннары әби калыша башлады. Ә инде беренче борылышка җиткәч марафончылар артыннан китмәде — икенче якка каерды.

Бераздан бер мәктәпнең спорт мәйданчыгына килеп керде. Монда әбинең сулышы капты, тыны кысылды. Шулай да туктарга уйламады ул. Хәтта мәйданчык кырыенда бер көйгә генә күшәп яткан ялкау бозауның аркан бавы аша абынмый-сөртенми генә сикерде. Шабыр тиргә баткан һәм тәмам хәлдән тайган Гыйльмиҗамал әби болдырдан көчкә атлап керде.

...Ә өйдә ул стадионга киткәндә сүндермичә онытып калдырган электр самоварының суы кайный-кайный парга әйләнеп бетеп килә иде инде.

## Табак һәм тарак, яки Җиңел пар белән!

Әллә инде бүген мунчаның эссесе кирәгеннән артык куәтле булды, Рахмай башта идәнгә төшереп җибәргән сабынын табалмый интекте. Аны гына тапкан иде, тарагын югалтты.

— Син минем таракны алмадыңмы? — дип сорады ул колагын сөртеп торган Хамматтан.

— Юк, алмадым. Бәлки, Сәлим алгандыр.

— Ни пычагыма ул Сәлимгә? Чәчен кырдырып алдырган бит ул.

— Ник, андыйларга табак кирәкмимени?

— Ниткән табак?

— Син нәрсә сорыйсың соң?

— Тарак сорыйм мин, тарак!..

— Ә мин табак дип ишеткәнмен.

— Колагыңа су тулмагандыр ич. Тулгандыр, мөгаен. Шуңа табак белән таракны аера алмыйсыңдыр. Үзеңә «Табак» дип кушамат тагарга кирәк әле.

— Анысы инде синең эш.

— Нәрсә, такмас дисең мәллә? Тагам. Үзеңне Табак, Табак дип йөртерләр аннары.

— Йөртсәләр соң... — Рахмайның ачуы чыга башлады.

— Бүгеннән башлап — Табак син. Әйе, әйе, Табак! Җиңел пар белән, Табак!

— Җиңел пар белән!..

Шул вакыт алар янына Сәлим килеп чыкты.

— Ник шаулашасыз?

— Син беләсеңме, Хамматның кем икәнен, — диде Рахмай, ашыга-ашыга. — Табак ул хәзер. Әй, онытып торам икән, син минем табакны күрмәдеңме?

— Табакны?

— Тфү, таракны ла. Менә шушы Табак аркасында үзем дә табак дип торам тагын. Табакны, таба... әй, таракны.

— Һич кенә дә күрмәдем бит.

— Табакны... — Рахмай тагын нидер әйтмәкче иде, киенгәндә майкасының бер як җиң уемына башын да, кулын да тыккан булып чыгып, бу минутта ни башын, ни кулын чыгара алмый азаплана иде.

Әллә тарагын югалтканга кәефе төште, әллә «Табак» дигән кушаматка Хамматның бер дә исе китмәвен сизде — Рахмай мунчадан кайтканда сөйләшмәде. Инде кайтып җиткәндә генә аның тавышы яңгырады:

— Табак! Табак мунчада калган. Әни кирәкне бирә бит.

Рахмай кире мунчага йөгерде. Үзенең биек яшел табагын ләүкә өстендә калдырган булган ул. Ә табак эчендә бер башыннан — ике теше, икенче башыннан өч теше төшкән тарагы да ята иде.

## Гөмбә оясында

Соңгы дәрес бетүен белдереп кыңгырау шалтырауга, балалар шау-гөр килеп ишектән чыга башладылар. Шулчак Зәки дусты Рәхимне җиңеннән тартып туктатты. Кеше ишетмәсен дигәндәй пышылдап кына әйтте: «Хәзер үк китәбез, яме. Югыйсә Ильясның да ияргүе бар. Урманга барганда миңа да эндәшерсез, дип бүген дә ике тапкыр әйтте инде. Ни пычагыма ул безгә. Кичә мәсьәләсен дә күчертмәде әле. Аннары тагын шул, урманга күп кеше барып юньләп гөмбә җыеп буламыни...»

Малайлар өйләренә кайтып тиз-тиз генә капкалап алдылар да чиләк әләктереп урманга юл тоттылар. Зәки җиңел сулап куйды. Болай булгач, Ильясны төп башына утырттык дип уйлады ул эчтән генә.

Баруы күңелсез булмасын өчен, малай былтыр гөмбә җыйган чагын сөйли башлады:

— Мин гөмбәнең оясын беләм. Былтыр шуннан берүзем ике чиләк җыеп алып төштем. Валлаһи менә!

— Кайда соң ул?

— Баргач күрерсең. Былтыр, әйтәм бит...
— Ак гөмбә бармы соң анда?..
— Әйтәм бит, дыңгычлап тутырылган ике чиләк ап-ак гөмбә алып кайттым...
Ул арада малайлар урман авызына якынлашып киләләр иде. Ләкин артларыннан кемнеңдер кычкырган тавышы аларны борылып карарга мәҗбүр итте.
— Ильяс! Ильяс йөгерә. Кай арада күреп алган диген син аны! Кирәкле кишер яфрагы. — Зәки бу сүзләрне тешен кысып кына әйтте. — Тәк, болай итәбез. Урманга керүгә сызабыз аның яныннан, йөрсен шунда берүзе аптырап.
Зәки тагын нидер әйтмәкче иде дә, яннарына мышный-мышный Ильяс килеп җитүгә туктап калды.
— Уф! Тәки куып җиттем бит. Урман тавыннан менеп баруыгызны күрдем дә йөгердем генә.
— Бәй, без сиңа әйтергә онытканбыз, — диде Зәки, хәйләкәр елмаеп һәм Ильяска сиздермичә генә сул кулы белән Рәхимнең кабыргасына төртеп алды. Сөйләшкәнне онытма, янәсе.
Урманга кергәч тә Зәки кызып-кызып атлавын дәвам итте. Ул черек төпкә эләгеп чак кына абынмыйча калды. Аның шулай кабалануыннан, ашыгып атлавыннан гөмбәне беренче булып табасы һәм чиләкне беренче булып тутырасы килүе сизелеп тора иде.
Ильяс белән Рәхим, киресенчә, ашыкмадылар.
— Урман көз көне бигрәк тә матур була икән, ә, Рәхим, — диде Ильяс, соклануын яшерә алмыйча.
— Әйе шул!..
Атлаган саен аяк астында коры яфрак өеме кыштырдый. Чаганнарга ут капкан диярсең — алар кызгылт-сары ялкын эчендә балкып утыралар.
— Рәхим, кил әле монда, тизрәк кил.
— Нәрсә бар, Ильяс?
— Менә бу чыршы төбендәге гөмбәне күрәсеңме?
— Юк.
Ильяс кулындагы таягы белән төптән бер уч яфрак тартып чыгаруы булды — анда ак гөрәҗдә елмаеп утыра иде.
— Карале син аны. Менә сиңа фокус!
— Гөмбәнең кайда үскәнен күңел белән тоярга кирәк, Рәхим.
Нәкъ шуны гына көтеп торган диярсең, малайлар янына Зәки килеп туктады. Ул бер гөрәҗдәгә, бер үзенең буш чиләгенә карап торды да Ильяска арты белән борылып Рәхимгә эндәште:
— Ычкындык моннан, әйдә! Мөхетдин аланы өстенә менәбез, былтыр...
— Сабыр ит инде. Монда да очрый бит әле. Менә бит! — дип, Рәхим җиргә иелде.
Зәки, дустының тыңламавына ачуланып, сул кулын гына селекте. «Нәрсәгә ялынып торам соң. Мөхетдин аланы өстенә үзем генә менәм дә алып төшәм бер чиләк гөмбәне. Болар шаккатсын!»
Зәки юкка чыкты.
Тик былтыргы урында ак гөмбәдән җилләр искән. Алай итте, болай итте малай — хет күңел өчен генә булса да бер гөмбә дә тапмады. Ачуланып кепкасын тартып төшерде дә җиргә сузылып ятты. Кинәт шартлап сынган ботак тавышын ишетеп, сискәнеп китте. Алдына караса, ни күрсен — аланның уртасыннан башын аска игән хәлдә поши чаба. Туп-туры Зәкигә таба! Зәки куркуыннан ничек сикереп торганын да сизми калды һәм авылга таба элдертте. Кепкасы да, чиләге дә шунда торып калды. Поши аланның икенче ягына, чыршылар арасына кереп югалса да, малай өчен ул нәкъ үзе артыннан ук чабып килгәндәй тоелды, тоякларының җиргә бәрелгән тавышы Зәкинең колак төбендә генә ишетелгәндәй булды. Шулай йөгерә торгач, Зәки Ильяс белән Рәхимнең каршысына ук килеп чыкты.
— Ни булды, Зәки? Нигә шулай шабыр тиргә баттың? Чиләгең кайда?
— Уф, чиләк кайгысымы соң әле, кепкам да төшеп калды. Чүт поши сөзеп үтермәде. Мөгезенә эләктереп алды дигәндә, чак качып котылдым.
— Зур идеме соң?

— Ике сыер хәтле булгандыр.
— Ә чиләгең тулган идеме соң?
Зәки малайларның чиләкләренә күз төшереп алды да эндәшмәде.
— Әйдә, чиләгең белән кепкаңны барып алып киләбез, — диде Ильяс.
— Юк, юк, — Зәки тәмам кызарды. — Хәзер соң инде. Урманда караңгы тиз төшә бит. Башка вакытта... Этем дә тими аңа.
— Гөмбәсез ничек кайтасың инде?
— Без болай итәбез аны, — Ильяс тотты да чиләген җиргә бушатты, — гөмбәләрне бүләбез. Безгә җитә бит монда.
Рәхим дә үзенекен кушты. Шулай итеп, Зәки гөмбәле булды.
...Малайлар авылга кайтып җиткәндә, кояш офыкка кереп чумган иде инде.
— Иртәгә дә барабыз, яме, Ильяс, — диде Рәхим.
— Иртәгә ял көне дә әле. Иртүк китәбез, син дә барасыңмы, Зәки? Иртәгә Мөхетдин аланы өстенә менәрбез. Кепкаң белән чиләгеңне дә табарбыз. — Ильяс бу сүзләрне Зәкинең күзләренә туп-туры карап әйтте.
Зәки «ярар» димәкче иде — тавышы чыкмады. «Анда гөмбә ю-у-к», — дип кенә пышылдады, һәм тирән итеп бер сулады да сул кулының аркасы белән маңгаеннан агып төшкән тирен сөртте.

## Ә сәгать келт-келт итә...

Соңгы вакытта мәктәпкә һич адәм вакытында килеп булмый, гел соңга калам. Үзем йокыдан сигезенче яртыда ук торам бит инде югыйсә. Тик менә өйдән вакытында чыгып китеп булмый. Йә китапны табалмый интегәм, йә күлмәкнең төймәсе төшкән булып, шуны тагасы була.
Беркөнне дә уянып китсәм — сәгать сигезенче ярты булган. Сикереп тордым да, почмакка кереп биткә бер уч су сиптем дә... Авызга бер кул белән тозлы балык, икенчесе белән кәрәзле бал тутырдым да... Инде аякка киям дә чыгып ычкынам дисәм... ботинканың бавы өзелгән булып чыкты. Тотындым дөбер-дөбер бау эзләргә. Ә сәгать келт тә келт, келт тә келт. Бауны табалмадым, әлбәттә. Сәгатьнең кече теле озынлыгындагы шушы өзелгән иске бауны өченче җиреннән ялгадым һәм ботинкамның ике тишегеннән генә эләктереп бәйләп тә куйдым.
Шул ботинкам аркасында тагын соңга калдым дип барсам... Менә гаҗәп, нәкъ вакытында килгән булып чыктым. И сөендем, и шатландым. Шатланудан да бигрәк аптырадым. Ничек шулай вакытында килдем икән, дим. Ә бит өйдән чыгып киткәндә сәгать сигез тулар-тулмас кына калган иде бит, дим. Кич белән белдем серен. Әти белән әни эшкә китәр алдыннан сәгатьнең олы телен ун минутка алгарак күчереп куйган булганнар икән. Мин соңга калмасын дип инде. Шәп тә иткәннәр соң! Шул ун минут коткарган мине.
Икенче көнне дә төп-төгәл сигезенче яртыда уяндым. Бу юлы торырга ашыкмадым. Сәгатебезнең ун минутка алда булуын беләм бит инде. Нәкъ ун минут рәхәтләнеп аунадым, ичмасам, һәм... һәм соңга калдым. Шунда уянуга торган булсамчы! Җитмәсә, чалбарга аш түгеп тә харап булдым.
Тәк, инде сәгатьнең телен тагын бер биш минутка алгарак күчерми булмый, минәйтәм. Күчердем — дәрескә өлгерә яздым. Тагын ун минутка күчердем. Ул көнне килеп тә кердем — дәрес тә башланды. Юк, тагын күчерергә кирәк әле, минәйтәм.
Вакланып тормадым — тагын егерме минут өстәдем. Хәзер кешеләрнең сәгате сигез тулганда безнең сәгать тугыз тулып килә торган булды. Ләкин моның да файдасы ташка үлчим генә. Ник дисәң, тугызынчы яртыга кадәр йоклый башладым. Нишләргә? Сәгатьне ачтым да озын телен тагын бер әйләнеш зырылдаттым. Һәм... унынчы яртыга кадәр йоклый башладым.
Ә бүген адәм көлкесенә калдым. Класска ут капкандай килеп керүем булды — барысы да шаркылдап көләргә тотынды. «Әй Һашим, кайтыр вакыт җитте бит инде», — диләр. Монысы ни хикмәт тагын?

Әби эше булган икән. Радио сөйли башлауга уянган да залга кереп сәгатьне караган (кирәк бит!). Караса, радиода алтыны суга, безнең сәгать сигезне күрсәтә. Әби аны-моны уйлап тормаган, ике сәгатькә алда йөри торган сәгатемне дөресләгән дә куйган. Миңа да берни әйтмәгән. Их әби, әби!..

## Бүген котылсам...

Бүген мәктәптән кайтам да бернигә карамыйм — дәресләремне әзерләргә утырам», — дигән идем. Булмады. Әни мин ярата торган токмачлы аш пешереп куйган. Җитмәсә, әби дә: «Ашау эшне калдырмый, улым», — дигән булды. Дөрес әйтә. Дәрес әзерләү өчен кичкә кадәр вакыт бар. Ашны чөмердем. Ә аннары, үзегез беләсез, ризыкны тәнгә сеңдерер өчен нишлиләр? Әлбәттә, ял итмичә ярамый. Диванга түндем. Йокыга киткәнмен. Һашим уятты. Хоккей уйнарга соңга калганмын икән бит. Йөгердем генә. Ә дәрес? Һи-һи-и... кичкә кадәр биш тапкыр әзерләргә була әле аны. Каты да уйнадык соң. Каен ярканың башыннан телем итеп кисеп алынган «алка»ны тал ботагыннан ясаган кәшәкәләр белән ярылганчы «кыйнадык». Өйгә караңгы төшкәч кенә кайтылды. Ә хәзер абзагыз бер генә чынаяк чәй эчеп алачак та дәрес әзерләргә тотыначак инде. Юк, мультфильм карагач тотыначак. Мультфильмнан соң кино башланды. Зыян юк, кино карагач та өлгерәм әле. Вакыт бар бит. Тик менә фильм ахырында күзләр әлҗе-мөлҗе килә башлады. Арылган. Юк, бүген иртәрәк ятыйм. Ә дәресләрне иртәгә иртән торып әзерләрмен. Өлгерәм ич әле. Шулай иттем. Иртән иртәрәк уяндым. Уяндым гына. Тормадым. Өй эшен мәктәпкә килгәч Һашимнан гына күчерәсе иттем. Вакыт бар бит әле.

Мин килгәндә, Һашим барысын да мәзәк сөйләп көлдерә иде. Ул сөйләгәндә көлә-көлә эчеңката. Каян сүзен таба, каһәр! Бүген дә үтерде генә инде. Әле тагын сөйлисе иде. Вакыт җитмәде. Дәрес башланды.

Укытучы апа беренче мәсьәләне Һашимнан сорагач, тәнем буйлап җылы-йомшак дулкын йөгерде. Димәк, Һашим сөйләгәндә, мин өйгә бирелгән икенче мәсьәләне чишәм, һичьюгында артта утыручы Дамирдан күчерәм. Вакыт бар бит. Тик мин мәсьәләне укып та өлгермәдем — Һашим үзенекен чишеп бетергән булып чыкты, һәм укытучы апа икенчесенә мине чакырды. Класс алдында багана кебек калкынып торудан башка чара юк иде. Тилмереп укытучының журналга төртелгән каләменә карыйм. Бөтен теләгәнем: «2»ле генә куя күрмәсен. Бүген котылсам, өйгә кайтуга дәрес әзерләргә утырыр идем. Бернигә карамас идем. Аңламады Мөршидә апа — миңа чәпәде «2»лене. Әнә кичә физика укытучысы Кәрим абый аңлады, ичмасам. «Иртәгә, ягъни бүгенгә була инде, әбәзәтельно әзерләнеп киләм», — дигәч, «2»ле куймады. Дөрес анысы, әзерләнеп булмады инде. Әгәр бүген дә куймаса, киләсе дәрескә әзерләнәм дә әзерләнәм инде. Бер тәгам ризык та капмыйча әзерләнәм. Юк, тамак ялгарга кирәк анысы. «Ашау эшне калдырмый», — ди бит әбием...

## Мин ничек клоун булмадым...

Салаватны әйтәм, акылы алтын икән — Чыршы бәйрәмендә миңа клоун булырга куша. Ел буена көлүләре җитмәгәнме?

И ялынды Салават, и ялынды. Биш көн буена ялынды. Минем җавап бер генә: «Юк!»

Кызык иттем. Тәки клоун булмадым. Билал булачак. Ха-ха-ха!.. Булсын әйдә. Аңа килешә ул.

Салаватның гына чырае сытылды. «Истә тотармын!» — дигән булды. Нишләтә ала соң ул мине? Отряд командиры дигәч тә... Куркыта, имеш. Куян тиресен күптән салып ыргыттык инде. Теге вакытта гына ул... О-о-о... ул вакытта, чыннан да, курыктым.

Либәдән зиреклеге буендагы чөгендер басуына чүп утарга барган идек. Класс белән. Бишалты билчәнне егып салдым да баш авырта дигән булып урманга кереп киттем. Ятам шулай бер

каен төбендә — бүре килеп чыкмасынмы! Куркудан бөтен тәнем буйлап ун мең ВАТТ көчәнешле электр тогы йөгереп узды. Яшелле-зәңгәрле тавыш белән кычкырып җибәрүем булды — Салаватлар мине коткарырга йөгереп килделәр. Килделәр дә тәгәри-тәгәри көлделәр — бүре дигәнем умартачы Хәсәнша бабайның эте булып чыкты.

Ярый, хуш, бүген үзләреннән көләчәкмен инде. Нинди тамаша күрсәтерләр икән? Билал ни кыланыр? Әнә Кыш бабай керә. Йолдызлы бияләе белән зәңгәрсу бөдрә сакалын сыпырып җибәрде дә ике кулын өскә күтәрде:

— Исәнмесез, балалар!

— Исәнме, Кыш бабай!

— Хуш киләсең! Әйдүк! — дидем мин дә, хорга кушылып.

— Ничек яшисез, дуслар? Ни хәлләрегез бар? Укулар ничек бара? Сезнең арада, шәт, «2»ле алучылар юктыр?

— Хәтерне калдырасың бит, бабакай. Нишләп бу сорауны миңа карап бирәсең?

Яңа елда «2»легә
Ябык булсын ишекләр.
Журналларны һәр чиректә
Бизәп торсын «5»леләр.

Кыш бабай үзе сөйли, үзе карашын миннән алмый. Ә тавышы... тавышы нәкъ менә Салаватныкы. Оятымнан җир тишегенә керердәй булып басып торам, чөнки монда «2»ле капчыгы мин генә бит. Салават, әй, юк, бабай сөйли дә сөйли:

— «2»лене, дуслар, ыргытыйк чүплеккә!

Акрын гына артка чигенәм. Озын муеным кыскарды, җилкәләрем куырылды. Күзләремне томан каплады. Их, булсын иде бер битлек. Тиз генә Рәхимнең «төлке»сен салдырып алдым да башыма киеп куйдым. Көлтә койрык битлеге тынычландырды бераз. Әмма озакка булмаган икән...

— Хәйлә-мәкерне иске елда калдырыйк, дуслар. — Кыш бабайның шулай диюе булды — хәйләкәр «төлке»не салып Рәхимгә сузганымны сизми дә калдым. Хәйлә дигәндә, мин болай да төлкедән ким түгел анысы, тик менә чөгендер кебек кызарган битемне кеше-кара күрмәсен иде инде. Партадашым Дамирның битлеген сорап торып попугай булдым.

Ә Кыш бабай һаман сөйли:

— Иске елда калдырыйк без ялкаулыкны. Дәресләргә әзерләнеп килмәүчеләр, җавап бирергә баскач, кеше әйткәнне тилмереп көтеп торучылар булмасын Яңа елда.

Дәрестә дә Дамир әйтеп торганны кабатлап интегүләр җитмәгән — бәйрәмдә дә попугай булып йөрим икән бит. Шунда ук попугайдан аюга әйләндем.

— Өлгерлек һәм җитезлек булсын безнең юлдашлар. — Кыш бабай, юк, Салават ла, сүзгә кесәгә керми.

«Ә бу аю, — дип уйлыйм үзем турында, — чаңгы ярышында иң ахырдан килде, ике көннең берендә дәрескә соңга кала. Аю да — аю, мин дә — аю».

— Мә, дустым, касалапыеңны!..

Инде ничек котылырга? Каршымда бүре тора. Юк, аңа якын да килмә. Хәсәнша бабайның этеннән соң «Бүре Шәкүр!» дип йөртәләр мине. Бичара куян кала инде... Аның белән дә булмый. Ул бит куркакның да куркагы...

Юк бит, ичмасам, тылсымлырак битлек. Ә-ә-ә... Клоун бар. Анысы да — Билалда.

Маңгаемнан бөртек-бөртек тир бәреп чыкты, аркам шабыр су булды. Уфылдап чыршы төбенә чүмәштем. Классташлар да сизенде бугай — миңа карап көлә башладылар. Боларына түзәргә дә була. Тик менә Билалның көлүенә ничек чыдарга? Нигә инде клоунның битлеген авызы колагына кадәр ерылган итеп ясыйлар икән?!

## Судья

Марсель түбән оч малайларының капкасына ике туп кертеп, футбол йолдызы Марадонага әверелгән. Шулай дип кенә эндәшәләр үзенә. Ә ул елмайган була. Канәгать булмый ни!.. Дөнья чемпионы исеме белән эндәшсеннәр әле. Анысы минем исем дә нәкъ Марадона инде: Марат — Марадона. Эш түбән очлар капкасына бер-ике туп тондырудан гына тора».

Маратның уйларын очрашуның башлануын белдереп яңгыраган сыбызгы тавышы бүлде.

Булачак Марадона тупны эләктерергә дип сул якка — Гайшәбикә әбиләрнең коймасы буена йөгерде, ә тупны көндәшләр уң якка очырттылар. Уң якка йөгерде — туп сул якка очты. Марат, сөзәргә килгән тәкә күк, Вильданның аяк астына ташланды, ә Вильдан Җаббарга пас бирде. Марат Җаббар янына йөгереп килде — тегесе исә тупны яңадан Вильданга шудырды. Кая ул гол кертү, хет тупка аягын тидереп карасын иде әле. Әһә, тырыша торгач тидерде бит. Бар көченә тибеп тә җибәрде. Тик туп кына ул теләгән якка түгел, Гайшәбикә әбиләр бакчасына очты. Аның каравы аягыннан ычкынып киткән шул туп төсендәге кара-кучкыл ботинкасы капка алдына ук барып төште.

Тәнәфестән соң Марат үзеннән Марадона чыкмаячагына ышанды, ахры, капкага басты. Дасаев булачак ул.

Әнә малай алга иелгән, җилкәләрен җыерып кулларын җәйгән, киеренкелекнең соңгы чигенә җитеп капка саклый. Чирәм өстеннән салмак кына тәгәрәп килгән тупны тотып алды да алга ыргытты. Аннары вәкарь белән генә як-ягына каранып алды. Ул сул якка карап торганда Җаббарның уң яктан китереп тибүе булды — Марат тупның капкага керүен сизми дә калды. Күп тә үтмәде, почмактан Вильдан манчыды. Әле ярый туп Маратның корсагына тиде. Корсак әрнесә әрнеде, аның каравы гол кермәде. Нәкъ Дасаев инде менә... Ә аннары... Аннары туп Марат капкасына яуды гына. Юк, Дасаев белән эш барып чыкмады. Ул баскан капкага туп кертеп, Вильдан — Вальдано, Җаббар — Жосимар, Билалов — Беланов, Зиннур — Зико, Ркаил Элькяер булдылар.

Ниһаять, судьяга әйләнде Марат. Авызында — сыбызгы, кулында — сары карточка.

Уен кызганнан-кыза. Менә түбән очлар атакага ташланды. Туп — Вильданда, юк ла, Вальданода, Вальдано Жосимарга бирде. Жосимар — Белановка. Беланов!.. Удар... Гол!

Әмма Марат голны санамады. «Офсайд!» — диде ул җитди генә һәм яңакларын кабартып сыбызгысына өрде. Бераздан ыргылып Марсель — Марадона килеп чыкты һәм тупны түбән очлар капкасына куа башлады. Бер сакчыны узды, икенчесен дә алдалады. Капкачы белән бергә-бер... Һаваны сыбызгы тавышы ярды. Марат Марадонаны туктатты. «Тупас уйныйсың», — диде ул. Тегесе бәхәсләшмәкче булды. Әмма кырыс судья аның борынына сары карточка китереп төртте. Марадона тагын нидер әйткән иде — Марат аны уеннан бөтенләй мәхрүм итте. «Судья белән бәхәсләшмиләр...» Нишлисең, футбол «йолдызы»на мәйдан кырыена чыгып, чирәм исе иснәп утырудан башка чара калмады. «Чыкмасаң — туп минеке, тотам да өйгә алып кайтып китәм, калырсыз авызыгызны ачып», — диде судья. Күп тә үтмәде, Марадона янына Вальданога чыгып чүмәшергә туры килде. Аннары сары карточка Жосимар белән Зико йөзе алдында да җилфердәде.

Ә туп әле уңга, әле сулга оча. Әнә нинди матур булып тәгәрәп килә ул. Нәкъ судья каршысына йөгерә. Марат түзмәде — аңа тибеп тә җибәрде. Әмма ул озаткан кадерсез туп бу юлы да Гайшәбикә әбинең коймасын яратты. Каен тактасына килеп тә бәрелде һәм пошт итеп туктап та калды. Бакчада бәрәңге чүбе утап йөргән әби сискәнеп буразнага чүгәләде...

Хуҗасы кулына алганда, тупта җан әсәре калмаган иде инде. Очы чыгып торган кадакка эләккән икән, хәерсез. Марат, шул кадакны да бөгеп куймагансың дигән кыяфәттә, кызарган күзләре белән Гайшәбикә әбигә карады. Ә куллары әбинең куркудан каны качкан йөзенә таба сары карточка суза иде.

## Чиртсен генә...

Хәйдәрне йокысыннан әтисе уятты:

— Улым, ишегалдындагы утынны сарайга ташып өяргә кирәк. Чәй эч тә шуңа тотын әле, яме. Бушагач, апаң да булышыр.

«Булышыр» дигән сүз инде Хәйдәргә җитә калды — йокыдан ачылып җитмәгән күзләрен уа-уа апасын эзләргә чыгып китте ул. Хания мунча алдында кер уа иде.

— Ташла бу чүпрәкләреңне. Әти утын ташырга кушты.

— Ташый тор инде үзең, минем кер чайкыйсы, ашка бәрәңге әрчеп саласы бар бит әле. Шуннан соң чыгам.

— Тизрәк бул, тизрәк. Минем сине көтәргә вакытым юк, балыкка барасым бар.

Апасы чишмәгә кер чайкарга төшеп киткәндә, Хәйдәр чолан баскычында утырып калды. Башта утырып, аннары идәнгә кырын ятып көтте ул Ханиянең су буеннан менгәнен. Апасы озак тормады — зәңгәрсу күлмәгенә килешеп торган зәңгәр көянтәсенә ап-ак кер тутырылган чиләкләрен элеп, менеп тә җитте.

— Син әле эшкә тотынмадыңмыни? — диде ул җәйге эсседә чоланның салкынча һавасын сулап рәхәтләнеп яткан Хәйдәргә.

— Сине көтәм.

— Инде ике кулыңа берәр ярка гына алып кертә торсаң да, яртысын ташып бетерер идең.

Шул вакыт Хәйдәрнең башына бер уй килде.

— Апа, тыңла әле, — диде ул, бик мөһим мәсьәләне хәл иткәндәй. — Шәп идея! Утынның яртысын мин ташыйм, ә яртысын — син. Кайчан телисең, шул вакытта ташырсың. Миңа да өлеш тия, сиңа да — бигайбә!

Хәйдәр утын өемен, гаскәрне күзәтүче генералдай, вәкарь белән генә әйләнеп чыкты. «Тәк, — дип уйлады ул, — монда чама белән утыз кочак утын бар. Унбиш кочак — миңа, калганы — апага. Тиз генә ташыйм да выжт — балыкка».

Хәйдәр шулай эшләде дә. Чама чамадан узмый, диләр. Тик Хәйдәрнең апасына чама белән калдырган унбиш кочак утыны утыз кочакка якын булды. Алай да апасы үпкәләмәде, зарланмады, сабыр гына ташыды. Хәйдәр кайткач, аңа да берни сиздермәде.

Ә берничә көннән Хәйдәрнең әтисе ишегалдына тагын әллә никадәр утын ярып өйде. Монысын инде Хәйдәр балыктан кайткач ташырга булды, чөнки Кесмәскә иптәш малайлары белән иртүк төшәргә килешкән иде.

Киткәндә апасын уятты ул:

— Бу юлы утынның яртысын башта син ташыйсың. Мин үземнекен балыктан кайткач кертермен. Түлке кара аны, мин анда чама белән күпме утын барын беләм. Хәйләләп миңа күбрәк калдырырга маташма. Икебезгә дә тигез булсын. — Хәйдәр суалчан тутырылган шырпы кабын кулында сикерткәләп алды да тагын шул сүзләрне кабатлый башлады: — Мин анда күпме утын барын беләм. Хәйләләсәң...

Хәйдәр елга буенда ут йоткандай утырды. «Апа алдар инде мине. Төп башына утыртыр. Юк, алдый алмас. Мин анда күпме утын барын беләм. Күбрәк калдыра икән — үземә тиешлесен генә ташыйм. Калганын яңадан үзе ташыр. Яки бармак тидермим. Өемнең төп-төгәл яртысы калган булса гына ташыйм». Шул вакыт Хәйдәрнең уң якта утырган күршесе, чупырдатып, су өстендә көмеш нурлар уйнатып, чабак тартып чыгарды. Ул инде җиденче балыгын ала. Көн саен балыктан буш кул белән кайтырга күнеккән Хәйдәрнең калкавычы селкенеп тә карамый. Әһә, әнә аныкы да биеп алды. Тәк. Уйната башлады. Хәйдәр урыннан торып ук басты. Аның судан койрыгын болгый-болгый, зәңгәрсу-көмеш тәңкәләрен ялтырата-ялтырата чыгачак балыкны күрергә өметләнгән күзләре тагын да очлана төште. Менә калкавыч юк булды. Хәйдәр кармагын киеренкелекнең соңгы чигенә җитеп тартты. Әмма судан җиме дә калмаган буш кармактан башка берни чыкмады. «Алдады бит, җүнсез. Ярый, эләктерермен әле мин аны. Алай гына алдый алмас! Аңа түгел, апама да алдатмыйм әле. Мин беләм — чама белән утыз алты кочак утын бар анда, унсигезәр кочак туры килә».

Чү, чиртә түгелме соң? Чиртә шул!

«Их, монысы эләксә генә ярар иде. Утынын да ташыр идем. Егет кешегә ние бар унсигез кочак утынның. Балык капса, бер-ике кочак артыграк та кертергә риза. Балык кына капсын!» — Хәйдәр кармак сабын югары күтәрде. Яр өстенә чәнти бармактан да кечерәк ташбаш малае килеп төште. «Монысы да ярый». — Ниһаять, Хәйдәрнең йөзенә аз гына булса да канәгатьләнү билгесе йөгерде. Суалчанга черт иттереп бер төкерде дә, кармакны һавада сызгыртып, янә суга ыргытты һәм күзләрен кылычландырып калкавычка төбәде. «Чиртсен иде. Апа утынны егерме кочак калдырса да ташыр идем. — Калкавыч сикереп куйды. — Егерме биш кочак калса да ташыйм. Бәхәсләшеп тормыйм. — Калкавыч бер чумып та чыкты. — Утыз кочак калса да...» Хәйдәр икенче ташбашны эләктерде.

Ул тагын бераз утырды да, шушы ике талымсыз ташбашка да канәгать булып, өенә утын ташырга йөгерде.

Кайтса, ишегалды ялт иткән иде.

## Чүплек

Бу дөньяда җисем бардан — юк, юктан бар була алмый икән. Шуны беләсезме? Ә менә минем бабай белми. Ишегалдында аунап яткан йомычкаларны себереп түгәргә кушты ул миңа. Себердем дә бөтен чүп-чарны чолан астына этеп кертеп куйдым. Бабайның күзе үткен шул, күреп алган тегене. «Иренгән ике эшләгән, — ди бу миңа. — Чүплек дип белдеңме әллә аны. Мәтри, мин чәй эчеп чыкканчы чолан асты ялт итсен». Һе, кызык! Йомычка да җисем бит. Аны бит юкка чыгарып булмый. Физиканы су урынына эчкән оныгы белән бәхәсләшеп тормасын иде инде. Тик моны бабайга әйттең ни, әйтмәдең ни. Үз туксаны туксан.

Җәй көне урманда печән җыйганда да аптыратты ул мине. Пакусны әле болай, әле тегеләй әйләндертә. Куелыктагы печәнне җыеп алып чыгарырга һәм тагын таратырга куша. Аңлатам үзенә:

— Бабай, — минәйтәм, — бу печәннең барысын да чүмәләгә өясе. Чүмәләгә өйгәч, бөтен печән бергә кушыла. Ә кушылучыларның урыннарын алмаштыру белән сумма үзгәрми. Димәк, печән дә артмый да, кимеми дә бит инде.

Юк, тыңларга да теләмәде.

...Чүпне бәрәңге бакчасындагы ызанга алып чыгып тондырдым. Тондырдым гына, бабай арттан чыгып җиткән. Тәрәзәдән күреп калган икән...

«Ишкәнсең, шайтан малай, — ди, — мин үлән тигез үссен дип ызанны себереп торам, ә син...»

— Бабай, — минәйтәм, — йомычка — җисем. Ул бар. Ул юк була алмый. Физика!

— Акыл сатып торганчы, җыеп ал тизрәк!.. — Үзе уң кулын биленә салып бакча башына менеп китте. Физиканы белмәгән кеше белән бәхәсләшмә икән. Мин бит инде могҗиза ясап, закон үзгәртеп йөри алмыйм.

Ничек котылырга соң бу чүптән? Урамга атсаң — күршеләр күзне ачырмас. Елгага атсаң — штраф!

Ниһаять, таптым җаен. Йомычкаларны шыпырт кына өйгә алып кереп, шкафка китаплар артына тутырдым. Монда аны этем дә күрми. Китапка кагылучы юк бездә. Әле дә тора. Тик әдәбият укытучысы гына каникулда бер китап та укымагансың дип «2»ле чәпәде. Тора хәзер шул кәкре муен көндәлегемне чүпләп: башын бөккән, койрыгын болгаган. Бу дөньяда бернәрсә дә бардан — юк, юктан бар була алмый. Нишләп шушы мәхәббәтсез «2»ле генә юктан бар була ала икән?!

## Теш сызласа нишләргә?

Сезнең тешегез сызлап азапланганыгыз бармы? Мин үзем дошманыма да теләмәс идем. Беркөнне әче таңнан бораударга тотынды. Тишегенә тутырмаган әйбер калмады. Туктамый гына бит. Башта өйдә үрле-кырлы сикердем, аннары ишегалдына чыгып сикердем. Аптырагач күрше Шәяхмәт абыйның капка төбендә калдырган мотоциклына барып атландым. Карыйм — хуҗа ачкычын да алмаган. «Урал»ның баш түбәсенә берне кундыруым булды, ачкыч черт итеп оясына керде дә утырды. Инде кабызып карамый буламы соң?! Типтем, берне, икене, өчне... Кабынды бит, бер көйгә генә текелди башлады. Шул вакыт капкадан Шәяхмәт абый килеп чыкты. Чыкты да минем колакны борды. Кызарды, кызды, әрнеде колак. Ә теш? Тфү, тфү... Теш басылды. Менә кызык: димәк, теш сызласа, колакны гына борырга кирәк икән.

Хәер, моны доктор абыйлар күптән беләдер. Әнә беркөнне эти дә врачка биленнән зарланып барган булган. Врач үзен йөзтүбән яткырган да табанына резина чүкеч белән суккан. Эскәмиягә утыртып тез астына да бер-икене кундырган. Ә биленә тимәгән дә. Шуннан ни булган дисезме — биле язылып киткән бит этинең. Менә шулай авырткан җирне авыртмаган җирне авырттырып дәвалый ул врачлар. Үзегез уйлап карагыз әле, салкын тиеп башыгыз авырта, борыныгыздан ага башласа, уколны кая кадыйлар соң? Әйе шул, бер авыртмаган һәм баш белән дә, борын белән дә бернинди уртаклыгы булмаган җиргә бит.

Әнә партадашым Сәлим дә сөйләп тора әле: «Беркөнне тешем сызлап врачка барган идем, — ди (ул да интегә инде шул теш белән), — врач сызлый торганын да актарды, сызламый торганын да актарды», — ди. Беләсезме, тамчы да сызламаган тешен тишкәләп бетергән. Аның каравы сызлый торганы сызламый башлаган.

Уф, бүген тагын сызларга тотынды минем теш. Уңга-сулга борам колакны. Икесен берьюлы борып карыйм. Файдасы юк. Дөрес, бик каты борып булмый анысы. Ни дисәң дә, үз колагың бит. Киттем докторга. Калганын сөйләп тә торасы килми. Начар докторга эләктем мин. Берни белми. Мөгаен, мәктәптә укыганда минем кебек «2»ле белән «3»ледән башы чыкмагандыр. Беләсезме, аның дәһшәтле кәнәфиенә барып утыруым булды — тешем сызламый башлады. «Ялгыш килгәнмен. Сызламый минем теш», — дип әйтеп карыйм. Юмалый-юмалый авызны ачтырды бит, үзсүзле. Кыскасы, колакны да бормады, аякка да сукмады, Сәлимнеке кебек башка тешкә дә тимәде. Бармак белән кагылсаң да әрнергә торган тешемне келәшчә белән каерып алды. Җитмәсә тагы, башта шул ук тешкә — әрнүе болай да җитмәгәнме — укол кадап маташты бит әле.

## «Эһ-эһ...»

Бу сөйләшү Беренче сентябрь көнне Әкрәм белән аның дүрт яшьлек энесе Мөхәрләм арасында булды

Ишетсен колагың, мин сине мәктәпкә тамаша карарга алып килмәдем. Абыең кубызына биергә алып килдем. Өченче көн әнә бөтенесе мәктәпкә җыелган. Бер мин «тозлаганмын» җыелышны. Режимга иялэнгән организм бит. Унсыз уянырга өйрәнмәгән. Бүген ник килмәгәнемне сорарлар, беренче көнне үк йоклап калдым дияргә тел бармый. Син коткарырга тиеш бердәнбер абыеңны.

— Ничек итеп?

— Мин «эһ» дип сигнал бирәм, син бертуктамый йөткерә башлыйсың. Мин җәлләгән булырмын үзеңне. «Авырыйсың бит!» — диярмен. Кара аны, авызыңнан ләм-мим бер сүз чыгармыйсың. Имеш, син өченче көн бик каты авырып киткәнсең. Тамагың беткән. «А» да чыкмый, «Б» да чыкмый. Әти-әни — эштә. Абзаң мәктәпкә китсә, сиңа анда үзеңә генә нихәл итмәк кирәк. Мине алдакчы дип ничә тапкыр эттән алып эткә салмасыннар, синең «эһ-эһ» килүеңне күргәч ышаначаклар. Шылдымы?

— Сылды!..

— Сылса, шалт Мөхәммәтҗан килә. Эһ-эһ...

— Эһ-эһ-эһ-эһ-эһ...

— Ай, энекәш, каты авырыйсың син, ай-яй каты авырыйсың.

— Эһ-эһ-эһ-эһ...
— Ишетте микән инде? Чү! Староста Наилә үтеп бара. Эһ!..
— Эһ-эһ-эһ...
— Котыра-котыра авырыйсың, энем. Нишләтергә инде сине? Безне күрмәде бугай, каһәр. Класс җитәкчесе килә.
— Эһ-эһ-эһ...
— Рабига Мифтаховна, каты авырый энекәш, котыра-котыра авырый, җүләрләнә. Тамагыннан бер сүз чыкмый.
— Мин җүләл түел.
— Җүләр син!
— Җүләл түел. Син үзең җүләл. Миңа «эһ-эһ» итәргә куштың.
— Эһ-эһ... Их! Их!

## Шпион

Телевизор дигәндә дөньясын оныта Кирам. Шпионнар турында фильм да күрсәтсәләр, экранны йотардай булып утыра. «Әнә кичә куып та карадылар соң берсен. Тик тота гына алмадылар. Зыян юк. Бүген тоталар аны. Беренче сериясендә чиртсә, икенчесендә кабачак ул ташбаш». Кирам уйларыннан бүленеп югары оч Хупҗамал әбиләргә йөгерде. Ветераннар турында альбом төзи алар. Кирамга да эш таптылар. «Альбомның өч бите синеке. Рәхәтләнеп тутыр. Хупҗамал әби янына барсаң, роман язарлык истәлекләр сөйли ала ул сиңа», — диделәр.
— Хуҗал әби! Хуҗал әби! Чык әле монда. Тизрәк бул, тизрәк.
Тәрәзәгә бәргән тавышка Хупҗамал әби сискәнеп китте.
— Һай, Ходаем, ни бар?
— Синең орденың бармы, Хуҗал әби?
— Ниткән үрдин?..
— Эшләгән өчен орден бирмәделәрмени?
— Соң инде... үрдин дип эшләмәдек инде. Атым үлде, үгез җиктем. Ул мескенемнең аягы сынды. Урман чыгардым. Әйдәле, олан, өйгә кер әле. Тышта торып...
— Юк, юк, әби. Вакыт юк. Кинога өлгерәсем бар. Телевизордан була. Во фильм! Шпионнар турында. Пух-пах-бах атышалар. — Кирам сумкасыннан таушалып беткән кәгазь тартып чыгарды да аңа: «Ат үлде, үгезнең аягы сынды, урманны үзе генә чыкты», — дип язып куйды. Кәгазьне дыңгычлап кесәсенә тутырды һәм, саубуллашырга да онытып, өенә йөгерде.
Тәк, хәзер дәрескә әзерләнәчәк ул. Шунсыз үтүт аңа телевизор. Әтисе белән әнисе якын да китермиләр. Затлы кәнәфидә аякларын бөкләп утырган Кирам математиканы исенә төшерде. Мәсьәлә!.. Каты чикләвек, каһәр! Тешең үтми икән — тотынма. Тарихтан исә мәктәпкә килгәч тә укып була. Татар теленнән язма эшне Харистан күчерәчәк. Һи-и-и!.. Булды бу. Әзер ул дәрескә. Сумканы ачып та торасы юк. Кирам зур канәгатьләнү белән телевизорның «вкл» дигән төймәсенә төртте.
Шул вакыт ишектә әнисе пәйда булды:
— Дәресең?.. Дәресең ни хәлдә?..
— Әзерләдем, әни. Бар да тәртиптә.
Ул арада әтисе дә кайтып керде:
— Өй эшен эшләдеңме?
— Эшләмәгән кая. Эшләп сумкага тутырып куйдым. Хет бүген үк кит мәктәпкә.
Кирам оста котылды. Хәзер рәхәтләнеп шпион куачак. Әтисенең сумкасына кереп тормасын белә ул.
«Ур-ра! Башланды фильм. Тавышланмагыз. Әнә майор. Шәп кеше ул. Шул эләктерер дә әле теге хәерсезне». Кыңгырау тавышы яңгырады. Кирам аны телевизорда дип тора — бактың исә, өйләрендә чыңлый икән. Ишекне әтисе ачты. Ә анда Хупҗамал әби басып тора иде.

— Исән-саулар гына торасызмы? Синең улың иде бугай, сабактан кайтышлый үрдин сорап кергән иде. Шунда букчасын онытып чыгып киткән. Эзләп интеккәндер инде, бичаракай. Сабагына да әзерләнә алмагандыр.

...Телевизор сүндерелде. Шпион да, шпион куучылар да экранның уртасына җыелып бер ноктага әверелделәр һәм юкка чыктылар. Экранда чәчләре үрә торган Кирамның шәүләсе генә калды.

## Тауга төшкән йолдыз

Нинди генә хикмәтләр юк бу дөньяда! Көн саен бер могҗиза. Кораб хәтле корабны йота торган өчпочмаклы сулар, тауларда кыләп сарып йөргән алагаем зур, йөнтәс кар кешеләре, күз карашы белән ут кабыза ала торган адәмнәр. Кашпировский, Чумаклар... Ә менә «тегеләр» турында әйткән дә юк инде. Килеп-китеп торалар. Кем сөйләде соң әле, кайдадыр машинист поездны туктата алмый икән. Тормозлары санламый, ди. Сәгатенә өч йөз белән чаба состав. Караса — тәлинкә очып бара. Шул тәлинкәдәгеләр куа икән товарнякны. Бервакыт кайдадыр тау башындагы яшь каен төбенә төшеп утырган булганнар. Алардан соң әлеге ялгыз каен бер төн эчендә колач җитмәслек юан булып үскән, имеш. Хак булса, түбән очның Шырт Хәйдәр дә: «Сорна тавы өстендә НЛО күрдем», — дип әйтә, ди.

Их, танышасы, бер утырып сөйләшәсе иде шул кунаклар белән! Бәлки, аларның минем кебек өченчедә укый торган малайлары, кызлары бардыр. Бәлки, ул кыз сары чәчле, зәңгәр күзле, почык борынлыдыр. Аның борыны өстендә чама белән генә төртеп куелган бер-ике сипкеле дә булса...

— Әйдә, сызыклы уйныйбызмы, Руслан?

Куркып киттем. Күрше кызы Диләә икән. Күзен-башын акайтып миңа төбәлгән. Шундый татлы уйларга чумып утырганда бүлдермәсә. Уйнамаган кая, малай башым белән кызлар янында сызыклы уйнап йөрисе генә калды. Уенга мавыгып оча торган тәлинкәне дә күрми калуың бар.

— Уйныйсым килми.

— Алайса, Сорна тавына меник.

— Үзең генә менсәнә. Минем анда югалткан әйберем юк.

Диләә үпкәләп китеп барды. Үпкәләсен. Ә минем күз — күктә. Күк зәп-зәңгәр. Озын-сузан булып яткан аксыл-зәңгәрсу каурый болытлар кояшта аркаларын җылыталар.

Ул көн шулай узды. Җир йөзенә беркем дә килмәде, һавадан берни дә төшмәде, берни дә иңмәде.

Кичен янә капка төбен саклыйм. Хәер, нишләп капка төбен... күкне саклыйм. Койма өстеннән ташып чыккан сирень тәлгәшләре исе яңа сөрелгән җир исе белән аралашып борын яфракларын кытыклый. Тау башында гаскәр кебек авылга якынлашып килә торган кара-кучкыл урман бу мәлдә серле дә, шомлы да, әкиятле дә. Отыры күк-җиһан да үзенең бихисап йолдызларын кабызып ут алды.

Шул рәвешчә шактый гына утыргач, урман өстендә тычкан уты кадәр генә бер якты ноктаның төнне ярып Сорна тавына таба баруын шәйләп алдым. Бара бит мин сиңайтим, чын-чынлап бара. Мизгел эчендә күз кысып куйгандай сүнеп тә ала, беравык яктырыбрак та китә. Эзе дә калмый, тавышы да юк. «Тегеләр!» дигән уй баш миенең бөтен күзәнәкләрендә берьюлы чирткәндәй була. Киләләр! Шул вакыт бөтен авылга кычкырмакчы идем. Тик күңелнең бер почмагында бөреләнеп өлгергән аз гына шикләнү хисе әлегә тыеп тора. Кычкырырсың да, бу тере ут алар булып чыкмаса? Юк, шулардыр инде. Тәгаен шулар гына. Кем йөрсен тагын урман өстендә кара төнне кисеп. Киләләр! Йолдызлар иленнән, сипкелләре почык борыннарына карандаш очы белән генә төртелгән, чәчләре кояшның алтынсу нурларына манылган кызлар иленнән. Беркөнне кешеләрнең басу өстендә һавада якты шар эленеп торуын күрүләре турында әти Мәскәү гәзитеннән дә укыган иде. Менә шул шарчык бүген безнең урман өстендә.

Их, хәзер урманда булып аларны агач төбеннән күзәтеп торсаң икән! Үземнең уйлардан үзем калтыранып куям. Юләр! Бу караңгыда карурманда калсаң. Кичә көндез чәчәк җыярга ничек йөрәксенеп барылгандыр. Әле монда капка төбендә шүрләтә.

Чү! Очып барган утлы тәлинкә кинәт эреде. Күз алдында төн йотты үзен. Кая китте, хикмәти Хода? Нишләде? Ихтимал, кунаклар Сорна тавына төшәсе иттеләр булса кирәк. Димәк, күзгә-башка чалынмый, шыпырт кына утырмакчылар. Шуңа күрә утны сүндермәделәрме икән?

Күпме генә көтеп утырсам да, күк түрендә йөзеп барган әлеге йолдыз кабат кабынмады.

— Йокларга керәсеңме син, юкмы? — Әни өченче тапкыр эндәшә инде.

Юрган астына чумгач та уемда гел шул якты нокта булды. Их, тизрәк таң атсын иде. Сорна тавына чабар идем. Үзләре булмаса, эзләре булыр.

Иртәгесен сикереп тордым да тәрәзәдән Сорнага карадым. Ни күрим, тау битенең яшел келәмендә бер кара-кучкыл нокта пәйда булган. Чәй дә эчеп тормадым. Сәпиткә атландым да чаптым. Тыкрыктан турыга бәрдерәм. Педальләргә бар көчемә басам. Тфү, шайтан, мин аны абайламый калдым: юлда зур гына бер таш ята икән.

«Кәҗә»мнең көпчәге шуңа менеп тә китте, мин читән буендагы кычытканнарга килеп тә кадалдым. Кычыткан өтәләве — пүчтәк. Тик менә терсәк каный. Терсәгә дә — чүп, су буеннан Диләменеп килә, каһәр.

— Кай төшеңне авырттырдың?

— Авырттырмадым.

— Беләгең каный бит. Яргансың син аны.

— Әй, бетә лә ул.

— Әйдә, бәйләп куябыз. Мин бәйли беләм. — Дилә кесәсеннән ап-ак кулъяулык чыгарды.

Мин аны бәйләтеп тормый идем инде. Күршем, пычрак эләксә, шешәр дип, шөбһә салды. Дилә бәйли, үзе сорый:

— Мәтәлә-кадала кая чаба идең соң?

— Сорна тавына.

— Нәрсәгә?

Дөресен әйтеп булмый бит инде. Көләр тагын.

— Болай гына.

— Минем дә шуннан кайтып килеш.

— Ә син нигә мендең? — Үзем эчтән генә: «Димәк, «тегеләр»нең төшкәнен бу да ишеткән», — дип уйлап куйдым.

— Ә мин әти янына мендем. Чәчү чәчә алар анда.

Беркатлы булып күренсәм күренермен, шулай да сорамый түзә алмадым:

— Син күргәнсеңдер ич, Дилә, тау битендәге әнә теге кара-кучкыл әйбер нәрсә ул?

— Теге түгәрәк мичкәне әйтәсеңме? Майныкы ул. Әтиләр тракторга май ала аннан.

Алай! Шулай да төнәген урман өстеннән йөзеп барган йолдыз нәрсә булды икән? Мин аны беләчәкмен. Барыбер беләчәкмен!

— Менә бәйләп тә бетердем.

Диләнең якты зур күзләрендә — мөлдерәмә нур. Шунда ни күрим, күршемнең күзләре зәңгәр икән бит. Чәчләреннән алтын су ага. Ә почык борыны өстендә, менә хикмәти Хода, бер-ике бөртек кояшлы сипкел елмая.

## Хәйлә

*(Скетч)*

Егет. Нихәл, энекәш?

Малай. Беркөе генә.

Егет. Кайтышмы, барышмы?

Малай. Кайтам.
Егет. Кайсы авылга?
Малай. Төлкелегә.
Егет. Алай икән. Димәк, шул авылда укыйсың да?
Малай. Шунда инде. Кайда булсын?!
Егет. Укулар барамы соң?
Малай. Бармый кая барсын.
Егет. Спорт белән дә шөгыльләнәсең булса кирәк...
Малай. Футболны гына яратам.
Егет. Ә гимнастиканы?..
Малай. Кит моннан, җенем сөйми. Физкультура дәресендә дә иң артка басам да чүгәләп тик торам. Укытучы күрми.
Егет. Бәлки, йөгерәсеңдер?
Малай. Кросста икенче урынны алдым. Хәйлә белән. Старттан бераз киткәч артышлыкка кердем дә яттым. Бер ярты сәгать чамасы вакыт үткәч, безнекеләр әлсерәп, телләрен асылындырып кайтып киләләр. Мин куак төбеннән сиздермичә генә чыктым да финишка җитәрәк бөтенесен диярлек узып киттем. Физкультура укытучысын да, классташларны да кызык иттем. Кәкре каенга терәттем. Ха-ха-ха. Чаңгы ярышында да шулай итәргә исәп әле. Юк, анысына башка хәйлә табам.
Егет. Нинди хәйлә? Әйт әле. Бәлки, минем энекәшкә дә файдасы тияр. Хәйләсез дөнья файдасыз, диләр бит.
Малай. Чаңгы ярышындамы?.. Катнашып та тормыйм. Пунктка барам да, билем авырта, дим. Бераз «ах-ух» килсәң, ыңгырашсаң, справка бирә алар.
Егет. Бирмәсәләр...
Малай. Һи-и-и, исем китте. Аякка чаңгыларны эләм дә китәм. Ул вакытта куак төбе кала инде.
Егет. Кыш көне куак төбенә качып та котыла алмассың...
Малай. Борчылмыйм. Корыган чыршыга кадәр барам да кайту юлына кистереп чыгам. Шулай итсәм, мин үтәсе өч чакрым бер чакрымга да тулмаячак. Әй, быел ярышлар булмас та әле. Эшләр хутта безнең. Физкультура укытучысы шәһәргә күчеп китте. ПТУда укыта, ди. Җә, кайтып та җитәбез бугай инде. Сез, абый, үзегез безнең авылга кунаккамы соң? Әллә берәр йомыш беләнме?
Егет. Эшкә кайтам.
Малай. Шабашкагадыр инде.
Егет. Районнан җибәрделәр. Сезнең мәктәпкә укытучы итеп. Физкультура укытучысы! Аңладыңмы?!

## Җырлый торган сәгать

«Пазик»ның ишекне пошт итеп ачып җи- бәрүе булды — янына су кебек бөялгән укучылар төркеме автобус эченә агып керә башлады. Беренче булып мәтәлә-кадала Әкрәм килеп керде. Керде дә буш утыргычка ташланды. Урынның шәбен — уртадагысын, тәрәзә буендагысын эләктерде. Үзенә дә эләктерде, күрше утыргычка да шап итеп кулын куйды. Монысы — Василга. Әкрәм боргаланды-сыргаланды, бер торды, бер утырды, әмма дусты һаман кереп җитә алмый иде әле. Ул арада буш урынга һөҗүм башланды. Әкрәм күкрәген киереп җикеренде-әтәчләнде: «Василга бу урын. Берегез дә утырмый. Тор! Юкса якаңнан өстерәп торгызам». Хет кулында бияләе, башында бүреге булсын иде. Шуларны гына салып куяр иде. Килмәде шул. Көн җылы дип, яланбаш, яланкул элдерде. Абыйсының җырлый торган сәгатен алып торган иде. Аптырагач, утыргычка шуны салып куйды. Сәгать кадәр сәгать өстенә килеп утырырга берәүнең дә башына тай типмәгән. Классташларын кызыктырып алырга да җай чыкты бит әле менә. Ул арада ишек төбендә Васил да күренде.

— Уз әйдә! Мин сиңа урын алып калдым.
— Кирәкмәс. Басып барам. Кызларны утырт.
— Юләрләнмә. Кил, утыр!
— Юк, утырмыйм.
— Утыр, дим мин сиңа. Колга буең белән калкынып барырсыңмыни?!
Әкрәм кыстаса кыстар икән, тәки Васил халыкны ерып кереп утырырга мәҗбүр булды.
Автобус кузгалды. Басып торучылар чыр килеп артка ауды. Әкрәмнәр янында басып барган Ләйсән бигрәк әче кычкырды. Аягына басканнар бичараның. Васил Ләйсәнгә урын бирмәкче булган иде — Әкрәм кабыргасына төртте:
— Кыбырсыма! Тик кенә утыр!
Юл чатында автобус кызыл утка туктады. Халык алга авышты.
— Уф! Үләм. Сытасыз бит инде! — Ләйсәннең әрнүле тавышы тагын яңгырады.
Васил түзмәде. Ялт торды да Ләйсәнгә урын бирде.
Тиздән «пазик» шәһәрне чыгып нарат урманына килеп керде. Бүген сигезенчеләрне язгы урман, урыны-урыны белән ак юрганын ертып тибеп чыккан күл, саф һава көтә. Алар — экскурсиядә.
Автобус хуҗасы укучыларны «Нарат» дип язылган мәһабәт урман өе янында бушатты. Үзе тагын кешеләр төяп шәһәргә кайтып китте.
Урман сукмагыннан барганда Васил сәгатенә карыйсы итте һәм шунда аның пыяласы төшеп калуын искәреп алды. Әтисе биргән бу иске сәгатьнең пыяласы бер тапкыр төшеп калган иде инде. Сәгать төзәтүчегә барган иде — «ә» дигәнче куеп бирде. Тагын куеп бирер әле. Зыян юк. Шулай да сәгать пыяласын югалтуы турында Әкрәмгә әйтте. Янәшәдә горур гына сызгырып барган Әкрәмнең колаклары тырпайды, күзләре очланды.
— Автобуста төшеп калгандыр әле, — диде ул, тавышын бөереннән чыгарып.
— Ихтимал.
— Шул кирәк сиңа. Басып барырга кем кушкан иде. Кешегә урын биргән була бит ул. Җүләр! Каян килгән джентльмен. Үзеңә урын эләккән икән, шуңа сөенеп алдыңа кара да бар инде. Алдыңа кара да атыңны куала, ди торган иде минем бабай. Бервакытта да кеше эшенә тыгылма. Үзеңнекен генә бел. Бетмәс анда Ләйсәннәр-мәйсәннәр.
— Классташ кыз басып торганда утырып бару килешми бит инде.
— Килешми, имеш. Ярый, торып урын бирдең ди. Шуннан сиңа ни файда соң? Зыяны булды әнә. Сәгатеңнең пыяласын югалттың. Басып барганда төшереп калдыргансыңдыр инде син аны. Тәгаен генә... Утырып барган булсаң, төшереп калдырмас идең.
Шул мәлдә Әкрәм үзе дә абыйсы биреп торган сәгатен исенә төшерде һәм ялт кына җиңен тартып беләгенә карады. Караса — сәгате юк! Уң кулында да юк, сул кулында да юк. Эче жу итте. Корт күче чаккан кешедәй ашык-пошык, каударлана-каударлана кесәләрен капшап чыкты. Юк! Абыйсы быел гына Африкадан сәяхәттән алып кайткан җырчы сәгать автобуста калган иде.

## Бияләй

Нишләп усал икән бу Сөмбел? Хәер, усалга охшамаган да үзе. Шагыйрь әйтмешли: «Үзе усал, үзе сөйкемле». Тик әллә нигә бер генә елмая. Анда да ирен чите белән генә. Дәрәҗәсен белә, каһәр. Усал булу үзенә килешә дә тагын. Шулай да елмайганда матуррак инде. Күзләреннән очкыннар сибелә. Чия кебек түгәрәк калын иреннәре сизелер-сизелмәс югары төшә. Битендә пәйда булган чокырлар бөтен йөзен балкытып торган нур ноктасына әвереләләр.
Тик миңа Озын Муен Гаптеригә генә елмая ул. Аныкы төсле камыл кебек тырпаеп торган киребеткән чәч миндә дә бар югыйсә. Авыз гына зуррак минем, шайтан алгыры. Чамасын белми елмайганда да колакка җитә. Бөтен эшне шул харап итә. Су капкандай йөрергә тырышам тырышуын. Тик файдасын ташка үлчим.

Гаптеринең үзен дә әйтер идем инде, чәчәк тирәсендә безелдәп очып йөргән бал корты сыман, гел Сөмбел янында бөтерелә. Чана шуганда да аның белән шаяра. Бүген дә Сөмбелне тау итәгендә көтеп торды да тегенең чанасын төшкән шәпкә почмагыннан эләктереп борып җибәргән булды. Тимер чана табаны астыннан мул гына кар комы сибеп әйләнде һәм тагын юлын дәвам иттерде. Ә Сөмбел елмая, балкый.

Икенче төшкәндә матур кызны тау астында мин каршы алдым. Бу юлы миңа елмаячак ул. Әнә выжылдап төшеп тә килә. Чанасын зырылдатып борып җибәрүем булды — Сөмбел багана төбендәге көрткә чумды. Мин елмаю көтеп аңа төбәлдем. «Катышлы», — диде ул, әрнүле тавыш белән һәм каш астыннан гына сөзеп карап куйды. Чамасызрак кыландым. Аскы иренемне тешләгән хәлдә басып калудан башка чара юк иде.

Бераздан карыйм: Гаптери тагын Сөмбел янында чуала. Карале син аны, бер уч кар алды да тегеңә аткан булды. Ә Сөмбел елмаеп кына калмады, көлеп тә җибәрде. Үзе дә нәфис бармаклары очына элеп кар сипте. Тәнем кымырҗып куйды. Сизмәстән бер йомарлам кар алдым һәм аны тирләгән учымда кыса-кыса тыгызладым. Бәлки, миңа бу юлы елмаер Сөмбел.

— Һоп! Ай!..

Карым чәп итеп аның күзенә килеп тиде. Ике кулы белән күзен каплап җиргә иелде ул. Бу шаяруым да тозсызрак килеп чыкты, ахрысы. Шулай да Сөмбелнең елмаюына өмет өзелмәгән иде әле. Әмма башын күтәреп тә күзеннән кулын алмавын күргәч, бөтен өмет-хыялларым шул бер йомарлам кар кебек чәлпәрәмә килде.

— Ни ачуың бар миндә? — Сөмбел каш өстенә кунып калган карларны бармак очы белән генә сыпырып төшерде дә карашы белән мине чәнчеп алды.

— Ялгыш кына, — дидем мин. Шунда күз төбенең кызарып чыкканын күреп алдым һәм башымны аска идем. Юк, моннан соң аның белән шаяраммы соң. Шаяра белми шаярганнан шайтан тайган, ди. Минем кебек чабата авызга хан сарае бүләк итсәң дә елмаймый инде ул. Шаяру түгел, борылып та карамыйм. Әкрәмчик, синең белән дуслашасым килә, дисен — карамыйм. Әкрәмчик, акыллым, матурым, дисен — карамыйм.

Таудан җилдәй төшеп киләм. Ул чанасын өстерәп менеп бара. Аның турыннан үткәндә башны юри икенче якка бордым. Ул төшеп, мин менеп килгәндә дә шулай иттем. Муен гына чыдасын. Уңга-сулга борам башны.

Бермәлне тау башында үзе эндәшмәсенме:

— Әкрәм!

Җавап бирмәдем.

— Әкрәм! Әкрәм, дим...

Тагын ишетмәгәнгә салыштым. Башта чанамны бер ун-егерме метр чамасы мәтәлә-кадала этеп бардым да тизлек алган шәпкә өстенә сузылып яттым. Кар диңгезендә чуртан кебек йөзәм. Агач чанам ак дулкыннар өстеннән тирбәлә-тирбәлә алга чаба. Битемне тау җиле иркәли. Үзем Сөмбел турында гына уйлыйм: «Ни әйтергә теләде икән бая? Тагын эндәшерме? Миңа нигә кылтаерга иде инде, Әкрәм диюгә борылырга иде. Бәлки, ул миңа бик матур сүз әйтергә теләгәндер. Бәлки, үзенең дә минем белән дуслашасы киләдер. Их, юләр дә инде мин. Байкот, имеш. Бүтән эндәшмәсә нишләргә? Бая ни әйтергә теләгән идең, дип каршына килеп басаргамы? Мөгаен, шулай итәргәдер. Юк! Үзеңне-үзең тоттыру була бу. Егетләрчә түгел. Нишләргә соң? Менә гаеш, үзең кыланганга үзең үкен инде хәзер».

Тау итәгендә чанамның бавын бер чишеп, бер бәйләгән булып утырам. Юри шулай эшлим. Тегенең төшкәнен көтәм.

Төште.

— Колагыңа мамык тутырмагансыңдыр бит. Эндәшәм — ишетмисең. — Аның тавышыннан баш әйләнеп китте. Тау сыртындагы кара-кучкыл урман, карга төренеп утырган өйләр кулга-кул тотышып биилармени. Хәзер Сөмбел миңа шундый сүз әйтәчәк, аны ишетергә күптән зар-интизар булып йөрим, ул миңа бик тансык. Матур кыз исә көттерә. Кесәләрен актарган була. Сизеп торам, юри газаплый. — Мә, ал, ташлап йөрмә!

Карыйм... кулында минем сыңар бияләй.

Әйлән-бәйлән өзелде. Гүя карлы урман түгәрәктән чыгып өстемә ауды, авыл өйләре асты өскә килеп өелде. Шушы мәлдә, шушы хәлдә бияләй кирәкме миңа?! Зәмһәрир суыкларда да яланкул йөрергә ризамын. Ә Сөмбел сөендердем дип уйлагандыр әле. Юк, аның миңа төшеп калган бияләйне тапканы өчен генә эндәшүе кирәкми иде. Авызымның Сөмбел табып биргән бияләй кадәр зур булуына тагын ачуым килеп чанама утырдым. Эш югында эш тапкан булып, итек кунычына тулган карны кагам. Ашыкмый гына, җайлап кагам. Сөмбел исә һаман каршымда басып тора.

— Әдәпле булсаң, рәхмәт әйтер идең, — диде ул, үпкәләгән сыман.

Мин аңа күтәрелеп караган мәлдә, үзенең дә кулыннан бияләе төшеп китте. Иелеп алырга өлгерә алмады, куян мамыгыннан бәйләнгән ак йомшак «йомгак»ны мин эләктердем һәм аңа суздым.

— Рәхмәт! — мин әйтәм.

Ул да:

— Рәхмәт! — ди.

Берьюлы яңгыраган ике «рәхмәт»тән икебез дә көлеп җибәрдек. Ул көлә, мин көләм. Кинәт Сөмбел туктап калды.

— Көлүеңне күптән күргән юк иде. Гел ачулы йөргән көнең. Нинди чебен булып тешләгәнмендер, мине күргәч бигрәк турсаясың. Ә елмаю килешә үзеңә.

Менә сиңа мә! Турсаеп йөрү түгел инде ул. Авыз кечерәк күренсен дип тырышу. Елмаю килешә сиңа, ди бит. Чынмы икән? Баярак көлеп җибәрүемне сизми дә калган идем. Хәзер юри елмаям. Ә Сөмбел... Сөмбел елмаюыма елмаю белән җавап бирде.

Бу вакытта без чана шуа торган ак тауга мамыклы җылы кар ява иде.

## Мәсьәлә

Бүген математиканы соңгы дәрескә күчергәннәр! — Шушы яңалыкны ишеткән Айратның башында бер идея туды: бишенче дәрестән качарга! Өйдә чишеп килмәгән мәсьәлә өчен баш ватмаска. Тик менә ничек качарга? «Сумканы кеше-кара күрмәгәндә тәрәзәдән ыргыттың ди. Залдан ике кулыңны селтәп чыктың ди. Юк, сумканы алыр өчен тәрәзә турысына киләсе бар. Шунда берәр озын теллесенең күзенә чалынсаң... Хәер, сумканы култык астына кыстырып чыксаң да, тәнәфестәге ыгы-зыгыда да кем сизеп торсын! Ярый, баскыч төбенә кадәр чыгарсың. Тик аннары ничек таярга? Болын ягына элдерсәң, мәктәп бакчасы аша үтәргә кирәк. Анда хезмәт укытучысының йөрүе ихтимал. «Дәресләр бетмәде бит әле...» — дип бәйләнә башласа... Иң яхшысы, мәктәпнең ат абзары артыннан Хисаметдин бабайларның бакчасына төшәргә, бакчаны кистереп тыкрыкка чыгарга, тыкрыктан — коры елгага, коры елгадан — Гали тавына, Гали тавыннан — аргы якка, аргы яктан — иске тегермән буасына, буадан — күпергә, күпердән — Гыйльманнар чатына, һәм менә шул Гыйльманнар чатыннан класс җитәкчесе Суфия апа килеп чыкса... Юк, ышанычлы вариант түгел бу. Иң яхшысы — туп-туры Карлыган сазына таю. Аннан тау гына менәсең дә ындыр артлатып кына кайтасың. Кайтасың, пычагым... Директорның каршына сукыр черки кебек килеп чыгарсың. Иң шәбе — урманга ычкыну. Менә анда оҗмах! Анда мәсьәлә чиштерүче дә, «2»ле куючы да юк. Анда икс белән игрик та, плюс белән минус та юк. Анда — манзара, яфрак түшәге, гөмбә... Берәр сәгать сызгырып тик йөр шунда. Тик менә син урманга барып керерсең, кайсы да булса бер класс шунда экскурсиядә йөри булыр. Һе, йөри бирсен. Карурманда да үзеңне тоттырып торгач, нинди разведчик син. Кыр — күз, урман — колак, дисәләр дә, икеләнеп тормаска, Ибраһим каенлыгына бәрдерергә. Тик авылны ничек чыгарга? Мәктәптән — иске утын сарае почмагына, аннан — тополь төбенә, топольдән — Кирамнарның гараж артына, гараждан — мунча түбәсенә, түбәдән — ызанга, ызаннан — бакча башына, бакча башыннан — су буена, су буеннан — зиреклеккә. Юк, зиреклектә Суфия апаның ире аркандагы бозавын эчерергә килгән булыр да, каптың булыр. Иң шәбе...» Тагын кырыкмаса-кырык вариант уйлагандыр Айрат. Тәнәфесләргә дә чыкмады хәтта.

«Иң шәбе... Урманга китәр өчен мәктәп бакчасыннан су буена шуышырга. По пластунски...»

— Хәнипов, тактага!

Айрат математика укытучысының тавышын ишетеп имәнеп китте. Торды. Чыкты. Кулларының, тез буыннарының калтыравын бернинди көч белән дә җиңәрлек түгел иде. Күңеле алдан сизгән бит: өйгә бирелгән мәсьәләне нәкъ аннан сорый укытучы. Тик нишләп алдан керде соң әле ул? Айрат укытучының өстәл өстендә яткан сәгатенә карап алды һәм гаҗәпкә калды. Класста соңгы дәрес — бишенче дәрес бара икән бит ләбаса! Мәсьәләне ул, әлбәттә, чишә алмады. Ә менә өйгә кайсы юлдан кайту мәсьәләсе чишелгән иде инде.

## Төп башына утыртты

Фәрт Фәсәхович ата-аналар җыелышыннан кайтканда борынын чөеп, күкрәген киереп атларга тырышты. Мондый вәкарьлекнең сәбәбе шул иде: башка балаларның тетмәсен теткәндә, аның улын мәсьәләгә үткен дип мактадылар. Математиканы су урынына эчә, инша язганда да сүзгә күршегә керми икән.

— Дилбегәне кысып тотарга кирәк аны. Югыйсә бала-чага тәртәгә тибәргә күп сорамый ул. — Фәрт Фәсәхович бу сүзләрне дә, дәрәҗәле, көр тавыш чыгарырга тырышып булса кирәк, тамак төбе белән әйтте. — Минем малай атасы нык торганга әйбәт укый. Ә сезнекеләр — пүчтәк, чөнки кулда тота белмисез. — Тел төбендә әнә шундый төрттерү ятканы хәлбуки һәркемгә аңлашыла иде. Фәсәхович сүзен дәвам иттерде: — Ишеткәнсездер, улым укыган класстан бер малай — кем икәнен хәзергә белмиләр — киногa баргач, клуб тәрәзәсен ваткан. Ата-анасы ни караган диген. Күрмәгәнен күрсәтер идем мин аңа. Кикриген тиз шиңдерер идем.

Кулын йодрыклаган Фәсәхович башка әтиләргә карап куйды. Ир заты, дәшми-нитми, үзалдына карап атлый бирә иде.

Шул вакыт, Корбыйлар тыкрыгыннан атыла-бәрелә, Фәсәховичның мактаулы улы Фәрит килеп чыкты:

— Әти, әти, мине ниме... математикадан шәп, диделәрме?

— Пычагым да шәп димәделәр. Ха-ха-ха... — Фәрт Фәсәхович, улына сиздерми генә, «фильтр» кыстырган иреннәрен бер якка кыйшайтып, башкаларга күз кысып куйды. Шаярта, янәсе.

— Нишләп?! Мәсьәләне «эһ» тә итми чишәм мин.

— Булмас. Чишсәң, әйтми калмаслар иде. Тешең үтмидер...

— Минем тешме?! Беркөнне математика укытучысы класста линейкасын онытып калдырган. Шуны теш белән чытырдатып сындырыйм да — үтмәс була димени!.. Бәй, аның бүген мактамавы да шул линейка өчендер әле. Берәрсе әләкләгәндер. Өч тиенлек «йомычка» өчен ачу сакламаса! Юктыр, башка нәрсә өчендер... Шулай беркөнне аның класска кереп барышы, ә минем чатыр чабып чыгып барыш иде. Дыңк... Авария булды. Күземнән утлар чыкты. Аныкыннан чыккандырмы, юктырмы! Артыма борылып карамадым. Шуңа хәтере калгандыр әле. Хәер, аның өчен генә дә булмас. Хикмәт монда, мөгаен, клуб тәрәзәсендә. Беркөнне, кинога баргач, чәлпәрәмә китергән идем мин аны. Шуны җиткергәннәрдер. Ире завклуб бит!

Ата-аналар җыелышыннан кайтучылар, әле Фәриткә, әле аның әтисенә карап, сүзсез генә елмаешып алдылар. Фәрт Фәсәховичның йөзе күмердәй кара янды, ә күзләре: «Төп башына утырттың бит мине, юньсез малай!» — дигән кебек иде.

## Тәҗрибә

Сез бүгенге теманың бик әһәмиятле икәнен беләсезме, юкмы? Бик әһәмиятле ул бүгенге тема. Шундый әһәмиятле ки, бүгенге теманы белми торып, алдагыларын, башыңны ташка бәрсәң дә,

өйрәнеп булмый. Бу әһәмиятле теманы өйрәнү өчен дәреснең минутын гына түгел, секундын да әрәм итәргә ярамый. Әгәр сез аны бүген физика дәресендә белеп калмасагыз... Юк, аннары сез аны тарих дәресендә дә, математикада да өйрәнә алмыйсыз. Моны әдәбият та өйрәтми, моны геометрия дә өйрәтми, моны география дә өйрәтми, моны зоология дә өйрәтми, моны... Моны сез мәңге өйрәнә алмаячаксыз. Бу әһәмиятле тема сезнең башыгызга сеңеп калсын өчен, тәҗрибә ясарбыз. Ишетәсезме? Тәҗрибә!

Хәмзин, син нишләп тыңлап утырмыйсың? Тыңласаң, әйт әле, мин ни дидем? Тәҗрибә ясыйбыз дигәнче нәрсә дидем? Әһәмиятле генә түгел, бик әһәмиятле, дидем. Йоклап утырмаска кирәк.

Тәҗрибә ясаганчы, болай дип язып куегыз, укучылар: «Җисемне...»

Әлмиев, син нигә дәфтәреңә карап тыңлыйсың? Миңа карап тыңла, язганда да миңа кара! Син нәрсә? Серкәң су күтәрмәсә дә, күрсәтермен мин сиңа!..

Тәк, башладык. Җисемне... Теге яки бу җисемне...

Ах бу Әлтәфовны... Ручкасын авызына кабып утыра бит. Сабый. Суыра торган кәнфит мәллә ул сиңа?

Җисемне, җисемне җылытканда...

Ә сез, тәти кызлар, ник көлеп куйдыгыз? Кәмит күрсәтмиләрдер ич? Кемнән көләсез сез, ә?

Җисемне җылытканда, кыздыр...

Хәзер мин сезне кыздырам. Әлмиев белән Сибгатов, басыгыз. Кем кушты сезгә артка борылып карарга? Кызларның көлгәнен күргәнегез юк мәллә? Алар стена ярыгыннан да көлә. Дәрес вакытында нинди боргалану-сыргалану ди ул? Читлектәге тиен кебек утырасыз. Тагын бер тапкыр күрсәм — икегезне дә выжт класстан! Нигә күзегезнең агы белән карыйсыз? Ышанмыйсызмы? Ике дә уйламыйча куып чыгарам. Утырыгыз.

Җисемне җылытканда, кыздырганда, молекулаларның, ягъни...

Сезнең укыйсыгыз килми мәллә? Берегезне дә чылбыр белән өстерәп китермиләр. Укыйсыгыз килмәсә, ихтыярыгыз. Вәссәлам.

Җисемне кыздырганда, молекулаларның, ягъни атомнарның да хәрәкәт...

Нишләп кыбырсыйсыз, ә? Нинди бетмәгән мәгънәсез хәрәкәт бу? Теңкәгә тия умарта күче кебек гөжләвегез.

Җисемне кыздырганда, молекулаларның хәрәкәт тизлеге арта.

Тукыйсың-тукыйсың, ә сез аның саен күбрәк боргаланасыз.

Тизлеге арта, дип яздыгызмы? Аларның уртача кинетик энергиясе дә...

Лаеш шулпасы ашатыр идем мин сезгә. Югыйсә көчегезне кая куярга белмисез. Вәйт гөжелдәр идегез аннары. Керфегегез дә селкенмәс иде.

Энергиясе дә арта. Аларның тәртибе бозыла...

Әлмиев, бас! Нинди тәртипсезлек бу? Мин бөртекләп сөйләп торам — син, эшем кырган кешедәй, сәгатькә карыйсың. Кыздыру җитмәгән, күрәсең. Менә сиңа мә — звонок! Сезнең чытлыкланып утыруыгыз аркасында тәҗрибә ясарга өлгермәдек. Анысын киләсе дәрестә ясарбыз.

Инде кабатлап әйтәм: «Җисемне...»

Ах сезне!.. Тәнәфестә дә сару кайнатасыз бит, ә. Әйе, әйе, сезгә әйтәм. Сезне... күпме кыздырсаң, молекулаларның кинетик энергиясе шулкадәр арта, тәртип бозыла.

## Шүрәле

*(Хикәя-табышмак)*

Самат белән әнисе икесе генә яшиләр. Әнисе район үзәгенә йөреп эшли. Иртән-иртүк китә, кич соң гына кайта. Самат өченче сыйныфта укый. Укуы төштән соң. Әнисе аңа: «Кечкенәдән эшкә өйрәнеп үсәргә кирәк», — дип тукып тора. Менә бүген дә кәҗә белән сарыкка печән

салырга кушып китте. Әнисе киткәч, малай рәхәтләнеп йокы симертте. Уянды. Ни саран кышкы кояш инде, ул да өйне нурга күмгән. «Әйдә, Самат, уйнарга», — дип әйтүедер инде, тәгаен. Тик менә дәрескә әзерләнәсе бар. Әй, качмас өйгә бирелгән эш. Самат урамга сызды. Кәҗә белән сарыкка да печән салып мәшәкатьләнмәде. «Ачтан үлмәсләр әле. Эшкә исә үскәч тә өйрәнергә була. Ул кәҗә белән сарыгын әйтер идем инде. Ничу ашатып яткырырга аларны! Чыгарасы да җибәрәсе. Үз көннәрен үзләре күрсеннәр. Беткәнмени ферма тирәсендә ат чанасыннан коелып калган печән, сенаж-менаж, силос-милос. Йөрсеннәр шунда чемченеп». Малайның башында менә шундый уйлар кайнады.

Самат дусты Фәритләргә барып компьютерда уйнады. Аннары өенә кайтып, китап-дәфтәрләрен алды да мәктәпкә чыгып чапты. Ач кәҗә аны, абзар тәрәзәсеннән башын тыгып, моңсу гына озатып калды.

Малай мәктәптән кайтканда авыл ут алган иде инде. Малай курка-курка атлады. Тынлык. Җир ак юрганын ябынып йоклый әле. Тизрәк яз җитсен, кошлар кайтсын иде. Җир уяныр иде. Саматларның өе авылның иң читендә булып, кайтып җитәрәк зиреклекне үтәсе бар. Малай ул төштән бигрәк тә шүрли. Агачлар, ботак-сатаклар арасыннан Шүрәле килеп чыгар кебек. Их, нишләп кояш төнлә дә балкымый икән?! Ай куып җибәрәдер аны. Ай һәм Кояш. Алар гел тарткалашып, ызгышып яшиләрдер кебек тоела Саматка.

Малай зиреклекне исән-имин генә үтте. Кайтып җитеп, капка келәсенә үрелгән иде, ишегалдында кар шыгырдаган тавыш аны сагаерга мәҗбүр итте. Кем булыр? Әнисе эштән соң кайта. Өйдә ут юк. Шулай да йөрәксенеп капканы ачты. Ачса... Абау!.. Самат капканы кире япты да урам буйлап чабып китте. Ишегалдында күргәнен ул һаман әле башына сыйдыра алмый иде. Нәрсә булыр ул? Ике аягына баскан да тәрәзәгә сузылган. Өй эчен күзәтә. Ак төстә. Бөтен тәне чат җон гына. Билендә җиргә кадәр асылынган шома капчык. Маңгаенда мөгезе дә бар иде бугай. Шүрәле шушы түгелме соң инде?! Саматларның өендә ни калган аңа?

Шүрәлене күрергә ярты авыл җыелды. Тик аның көн буена ач яткач, абзар тишегеннән шуышып чыгып, өй тәрәзәсенә печән өмет итеп сузылган бичара кәҗә булуы бик тиз ачыкланды. Капчыгы исә буш җилене икән. Эшкә иренгән Самат оятыннан, хурлыгыннан кәҗә шуышып чыккан шул тишеккә кереп качардай булды.

*Сорау: Язучы, бу хикәяне язганда, Габдулла Тукайның 2 әкиятен, 8 шигырен күздә тоткан. Алар ничек атала? Хикәя герое Самат аларның кайсысын укыган, кайсысын укымаган?*

*Җавап: Язучы, бу хикәя-табышмагын язганда, Габдулла Тукайның «Шүрәле», «Кәҗә белән Сарык» әкиятләрен, «Эш», «Ай һәм кояш», «Сабыйга», «Эш беткәч, уйнарга ярый», «Кызыклы шәкерт», «Эшкә өндәү», «Җир йокысы», «Гали белән Кәҗә» шигырьләрен күздә тоткан. Самат әкиятләрне укыган.*

## Җыр «меню»сы

*(Уены-чыны бергә)*

Икмәк булса, җыр да була», — дигән иде кадерлебез вә хөрмәтлебез, мөхтәрәмебез вә гыйzzәтлебез Леонид Ильич Брежнев.

Икмәк бар. Аллага шөкер. Ипи турында җыр гына юк. Һәрхәлдә, яңа җыр юк.

Ит турында да юк. Күкәй турында да юк. Сөт турында да юк.

Сөт турында бер җыр бар иде анысы:

Җәйләүләрдә көтү куды Гөлмәрьям...

Тик бу җыр язылганга 37 ел икән бит инде. Әйтерсең лә 37 ел сыерсыз яшибез.

Бәрәңге турында да җыр бар иде.

Йодрык кадәрле,

Йомры гәүдәле...

Мондый җыр да бар иде:

Үз илемдә газиз миңа
Бәрәңге бакчасы да...

Колорадо корты бакчаны басып алганчы, җыр бар иде. Бакчаны басты жук. Жуктан соң җыр да жук.

Җыр «меню»сына күз салсаң, балан турында бар. Миләш турында бар. Аларны күп ашап булмый бит. Изжога булырга мөмкин.

Тагын җиләк күп әле безнең җырларда. Җиләк! Тик хәзер анысын җыярга иренәбез.

Уч тутырып кура җиләк
Кемнәр ашатыр өзеп...

Сез беләсезме, японнар кулланган ризыкның 97 проценты балыктан гына тора икән. Балыкта фосфор күп, ә фосфор башны эшләтә. Менә шуңа күрә акыллы ул японнар.

Ә бездә балык күпме?

Бардым күлгә, салдым кармак,
Безгә балык эләкми шул...

Ярый әле Ходай Тәгалә безгә — татарларга — балыгын әллә ни бирмәсә дә, акыл белән талант биргән. Балык ашамасак та булдырабыз бит. Әгәр дә бу татарга японнар ашаган кадәр балык ашатсаңмы?..

Тагын бер күркәм сыйфатыбыз бар — сабырлык.

Әнә чиртә, дия-дия,
Менә каба, дия-дия
И утыра балыкчы.
Су буенда балыкчы...

Түзә, сабыр гына утыра. Утырсын. Сабырлык булса, балыгы да булыр.

Ходай сабырлык бирсен!

Ходай яраткан җырларыбыздан, яраткан ризыкларыбыздан аермасын-өзмәсен.

## Эчтәлек

**Җаннарны чайкыйсы бар…** *(повестьлар)*

Әбиемә — әфлисун
Карга карагы
Җиденче палата

**Балачакның күге биегрәк** *(хикәяләр)*

Матуркай
Соңгы йөреш
Кыйгак
Ачуланма инде, Илһам!..
Киек Каз Юлы

*Юмористик хикәяләр*

Ашыгудан ни файда ?
Әкрәм законы
Бер җәйдә… алтмыш рәхмәт
Инша
Шәп малаймы?
Бәхетле билет
«Чук һәм Гек» һәм дә… Ирек
Җәйге кар
Элмәк
Кем катырак суга?
Фельетон яза Фәсхетдин
Марафон
Табак һәм тарак, яки Җиңел пар белән!
Гөмбә оясында
Ә сәгать келт-келт итә…
Бүген котылсам…
Мин ничек клоун булмадым…
Судья
Чиртсен генә…
Чүплек
Теш сызласа нишләргә?
«Эһ-эһ…»
Шпион
Тауга төшкән йолдыз
Хәйлә
Жырлый торган сәгать
Бияләй
Мәсьәлә
Төп башына утыртты
Тәҗрибә
Шүрәле
Җыр «меню»сы

Литературно-художественное издание

**Нуриев** Вакиф Вакилович

# Седьмая палата

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Нуриев** Вакыйф Вәкил улы

# Җиденче палата

Мөхәррире *А.М.Җамалиев*
Рәссамы *Д.Л.Нәүрузова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Р.Н.Шакирова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 24.10.2007. Форматы $75x90^{1}/_{32}$. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 11,25. Шартлы буяу-оттиск 11,56.
Нәшер-хисап табагы 8,93 Тиражы 2000 д. Заказ С-1344.

Татарстан китап нәшрияты ДУП.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.